# Туган телдә сөйләшәбез



Методик кулланма

3 – 4 яшь

# Туган телдә сөйләшәбез

Методик кулланма

Казан
«Фолиант»
2013

УДК 373.3/4:811.512.145*00
ББК 74.102:81.2 Тат
Т81

Авторлар:
*Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ.*

Рецензентлар:
*Гаффарова Сәбилә Муллануровна,*
Казан педагогика көллиятенең директор урынбасары;

*Кадырова Рузалия Әхәтовна,*
Казан шәһәренең 415нче балалар бакчасы мөдире;

*Закирова Кафия Вәлиевна,*
Казан шәһәренең 415нче балалар бакчасы методисты

Т81 **Туган телдә сөйләшәбез.** Методик кулланма / Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. – Казан: Фолиант, 2013.- 224 б.

Методик кулланмада икенче кече яшьтәгеләр төркеменә йөрүче балаларның сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм хәзерге технологияләре бирелгән. Кулланмада өч-дүрт яшьлек балаларның сөйләм үсеше һәм федераль дәүләт таләпләреннән чыгып, аларның сөйләмен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре ачыклана. Эшчәнлек оештыру конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә басылган «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Әлеге кулланма танып белү, коммуникация, матур әдәбият уку белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балаларның белем бирү өлкәләре эчтәлеген ни дәрәҗәдә үзләштерүләрен ачыклау максатыннан диагностик методикалар бирелә. Методик кулланма мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә, урта, югары һөнәри белем алучы студентларга, мәктәпкәчә белем бирү сферасында эшләгән мөгаллимнәргә, эти-әниләргә тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-905576-20-1

© Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ., 2013
© Фолиант, оригинал-макет, 2013

# Аңлатма язуы

Әлеге кулланма – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча төзелгән «Туган телдә сөйләшәбез» дип аталган методик комплектның икенче өлеше. Өйрәтү-методик комплект методик кулланманы, аудиоязмалар җыентыгын, күрсәтмә материалларны үз эченә ала. Бу комплект 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелә. Комплектның төп максаты - балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Сез кулга алган кулланма балалар бакчасында *икенче кече яшьтәге* балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә методик кулланма буларак тәкъдим ителә. Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Методик кулланмада федераль дәүләт таләпләре буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомумкабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып эшләнде. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик якланганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә.

Принципларның тагын берсе – үстерешле белем бирү принцибы, ягъни белем бирү нәтиҗәсендә белемнәр үзләштерелеп, күнекмәләр генә формалаштырылып калмый, ә тоемлау, аңга алу, хәтер, игътибар, сөйләм, фикерләү белән бәйләнешле барлык танып белү процесслары да, шулай ук ихтыяр һәм эмоцияләр дә үстерелә - бала шәхесенең төрле яклы үсеше алып барыла.

Ахыргы елларда үстерешле белем бирү мәсьәләләре балаларның төрле төр эшчәнлеген интеграцияләү белән тыгыз бәйләнештә карала. Бу бигрәк тә оештырылган төп эшчәнлек төрләренең танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү) белем бирү өлкәләренә хас. Белем бирүне «якындагы үсеш зонасына» ориентлаштырып алып барганда гына ул үстерешле нәтиҗә бирә (Л.С. Выготский). Бу очракта, кагыйдә буларак, бала белемнәрне өлкәннәрнең аз гына ярдәме нигезендә үзләштерә. Тәрбияче «якындагы үсеш зонасының» баланың яше белән генә түгел, ә шәхси үзенчәлекләре белән дә бәйле булуын истә тотарга тиеш. Белем бирү барышында баланың фикерләвенә зур игътибар бирү сорала.

Эшчәнлек төрләрендә сөйләмдә *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында *сүзлек өстендә эш* зур урын ала. Сүзлек өстендә эш - бәйләнешле сөйләм нигезе. Эшчәнлек конспектлары сүзлек өстендә эшнең өч бурычын чишә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.



*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксика ягын, сүз ясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышын, ишетеп аңга алу, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын – диалогик һәм монологик сөйләмен үстерүне күздә тота. Диалогик сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны *матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* – сөйләм үсешенең әһәмиятле чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру процессында без түбәндәге бурычларны чишәргә тырыштык:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итү, беренчел күзаллаулар формалаштыру.

2. Әдәби сөйләм үстерү.

3. Сөйләм сәнгатенә якынайту, шул исәптән эстетик зәвык, әдәби әсәрне аңга алуларын үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә, белем бирүнең төрле алымнары, чаралары кулланыла. Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.)

хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын раслыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда, балалар, эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы күләмле итеп язылды. Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда, тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомумкабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм



үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.

Икенче кече яшьтәге балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик принципка нигезләнә. План ел дәверендә «Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!», «Көз», «Мин һәм минем гаиләм», «Минем йортым, минем шәһәрем», «Яңа ел бәйрәме», «Кыш», «Ватанны саклаучылар көне», «Сигезенче март», «Халык җәүһәрләре», «Яз», «Җәй» кебек темалар үзләштерүне күздә тота.

Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләмен үстерүдә тәрбиячеләргә ныклы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз. Әлеге методик кулланма милли балалар бакчасында эшләүче педагогларга, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку-укыту йортларында белем алучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.

# Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлеше буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре

## ТАНЫП БЕЛҮ ӨЛКӘСЕ

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | Кояш, чык! | 1) җәй турында күзаллауларга нигез салу, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен; күз алдына китерә, хыяллана белүләрен; вак моториканы, рәсем ясау күнекмәсен, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1) агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү;<br>2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш, уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Манара | 1) балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү.<br>2) предметның төсен, формасын, зурлыгын атый белүләренә ирешү;<br>3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| 11.09.-30.09. | Көз | Куян үстергән кишер һәм помидор | 1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 1) балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турындагы күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) яшелчәләрне (кыяр, шалкан) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белергә өйрәтүне дәвам итү; игътибар, аңга алу, диалогик сөйләм, сенсорик сәләтләрен үстерү;<br>3) сорауларга җавап бирү теләге тудыру; табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Сары, кызыл яфраклар | 1) балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү; көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү;<br>3) балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.10.-15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Кунак каршылыйбыз | 1) савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылышы турында белемнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү;<br>3) балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү. |
| 16.10.-04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | Мин – «КамАЗ» оныгы. | 1) балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган «КамАЗ» машинасы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү;<br>2) аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү; «КамАЗ» машиналары белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) туган шәһәр, «КамАЗ» эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15.11.-31.12. | Яңа ел бәйрәме | Тылсымлы шкатулка.<br>. | 1) балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк тәрбияләү;<br>2) балаларны чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләргә өйрәтү, диалогик сөйләмнәрен үстерү, сорауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерергә өйрәтә башлау;<br>3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. |
| | | Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз | 1) балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, тикшеренүләр барышында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазларның артикуляциясен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын формалаштыру;<br>3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру; җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.01.-31.01. | Кыш | «Чанада шуабыз» рәсемен карау | 1) балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлегендәге аңларга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) диалогик сөйләмнәрен; күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә-образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү. |
| | | Җимлек янында.<br>. | 1) кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту;<br>2) аваз иярткемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын үстерү;<br>3) кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү. |
| 01.02.-23.02.. | Ватанны саклаучылар көне | Ватанны саклаучылар көне | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үстерү;<br>3) балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 24.02.-08.03.. | Сигезенче Март | Минем әнием | 1) әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) балаларда пөхтәлек, әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү. |
| 09.03.-31.03. | Халык җәүһәрләре | Тере һәм уенчык кошларны карау | 1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчык кош – дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү;<br>3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 01.04.-20.04. | Яз | Урамда яз | 1) балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау барышында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү;<br>3) язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту. |
| 02.05.-31.05. | Җәй | «Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре» рәсемен карау | 1) балаларны тәрбияче ярдәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга, аның турында сөйләргә өйрәтү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, дуслык турында күзаллауларын үстерү;<br>3) тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү; хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту; хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләр тәрбияләү. |

## *Беренче бүлек.* САУ БУЛ, ҖӘЙ! ИСӘНМЕ, БАЛАЛАР БАКЧАСЫ!

### Тема. КОЯШ, ЧЫК!

**Бурычлар:**

1) җәй турындагы күзаллауларын киңәйтү, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү;

2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен, күзаллауларын, вак моторикаларын, рәсем ясау күнекмәләрен, иҗади сәләтләрен үстерү;

3) балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** А 4 форматындагы ак кәгазь битләре, (аларга диаметры 8-9 см булган сары түгәрәкләр ясалган), һәр бала өчен сары, тәрбияче өчен зәңгәр, кызыл төстәге фломастерлар, «Иртәнге нур» (С. Садыйкова көе, З. Вәли сүз.) җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче, баланың күзенә туры карап, кулларын баланың кул учларына туры китереп: «Исәнме, Марат! (Алсу, Рамил, Лилия, Кәрим һ.б.)» – дип, һәр бала белән исәнләшеп чыга. Бала башын селки яки «Исәнмесез!» – ди.

**Тәрбияче**. Балалар, мин сезгә табышмак әйтәм, сез җавап табарга тырышыгыз:

Һәркемнән иртә тора,
Җылы нурларын сибә.

Ул нәрсә? (*Кояш*). Дөрес, балалар, ул кояш. Кояш кайчан ныграк җылыта: кыш көнеме, әллә җәй көнеме? (*Җәй көне*). Кояш кайчан чыга, кичме, әллә иртәнме? (*Иртән*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Дөрес, балалар, кояш иртән чыга, ә кичен



югала. Иртән олы кешеләр һәм балалар нәрсә эшлиләр? (*Йокыдан торалар, юыналар, тешләрен чистарталар, киенәләр, иртәнге аш ашыйлар. Зурлар эшкә, ә балалар мәктәпкә, балалар бакчасына китәләр*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кояшның файдасы бармы? (*Бар*). Балалар, кояш нәрсә белән файдалы? Кояшны без ни өчен яратабыз? (*Яктырта, җылыта, кояшта җәй айларында кызынырга була.*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Булдырдыгыз, балалар! Бик яхшы. Менә кояш никадәр файда китерә, күпме эш эшли. Шуңа күрә кояшка рәхмәт әйтергә кирәк. Әйдәгез, кояшка таба борылып басып, кулларны югары күтәреп: «Рәхмәт сиңа, кояшкай!»- дип әйтик.

Тәрбияче балаларга сары түгәрәк ясалган кәгазь бите күрсәтә.

– Балалар, бу нәрсә? (*Түгәрәк*). Түгәрәк нинди төстә? (*Сары*). Сары түгәрәк нәрсәгә охшаган? (*Балаларның җаваплары*). Дөрес, сары түгәрәк кояшка охшаган. Тагын да ныграк чын кояшка охшасын өчен, аңа нәрсә җитми? (*Нурлар*). Балалар, кояш әле йоклый, шуңа күрә нурлары юк. Урамда җәй бит, кояш йоклап ятмасын, әйдәгез, кояшны уятабыз. Игътибар белән карап торыгыз.

Тәрбияче һәрбер балага кәгазь битләре һәм сары фломастерлар таратып чыга. Балаларга фломастерлар белән кояшның нурларын ясарга булыша.

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер һәрберегез кояшка нурлар ясарсыз. (Балалар төрле юнәлештәге кыска һәм озын туры сызыклар сызып, кояш нурлары ясыйлар). Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез, уйнап алыйк.

Кояш чык, чык, чык!
Синең җылың бик тансык.
Чыксаң без сөенербез,
Майлы ботка бирербез.

Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Тәти кашык саф алтын,
Кирәкми безгә салкын!

Балалар тәрбияче белән бергә кабатлыйлар.

– Балалар, кояш һәрвакыт безгә шулай җылысын биреп торсын! Хәзер һәрбегезнең кояшына мин күзләр, борын, елмайган авыз ясыйм. Алсуның кояшы елмайсын! Маратның да кояшы елмайсын! Менә шулай! Барыгызның да кояшы елмаеп, көлеп тора. Балалар, әйдәгез, шул елмаеп, көлеп торган кояш турында матур сүзләр әйтегез әле. Кояш шатлансын. Нинди соң ул кояш? (*Түгәрәк, якты, җылы, нурлы, алтын, сары, матур, һ.б.*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

Күңелле кояш
Нурларын сибә.
– Биегез әле,
Балалар! – дия.

Тәрбияче С. Садыйкова көе, З. Вәли сүзләренә «Иртәнге нур» җырының аудиоязмасын куя. Балалар бииләр.

Булдырдыгыз, балалар! Бик яхшы. Хәзер инде кояш янына урамга җыеныгыз!

## Тема. ЙОМШАККАЙ ӘЗЕРЛӘГӘН СЮРПРИЗ

**Бурычлар:**

1) агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү;



2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү.

3) уенчыкларга карата сакчыл караш һәм уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү.

**Җиһазлар:** тартма, уенчык песи (Йомшаккай), карау өчен пирамида, зур матрешка һәм һәр балага җитәрлек матрешкалар.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балаларны чишенү бүлмәсеннән уен бүлмәсенә алып керә. Тәрбияче өстәлендә тартма тора. Аны күреп, тәрбияче гаҗәпләнә.

**Тәрбияче.** Бу нинди тартма? Аны кем алып килде икән? Менә монда открытка ята. Кем җибәргән икән ул открытканы? Хәзер белербез. (Укый). «Бу тартманы җибәрүче мин – сезнең дустыгыз Йомшаккай. Ул сезгә күңелле сюрприз булсын.»

– Балалар, Йомшаккай үзе кайда икән соң? Менә нинди шаян песи! Открытка җибәргән, ә үзе качкан. Балалар, тартмада нәрсә бар икән, карыйк әле. Җайлы итеп урыннарыгызга утырыгыз. (Тәрбияче тартманы ача). Йомшаккай безгә уенчыклар җибәргән! (Балаларга уенчыкларны алырга тәкъдим итә). Булат, син нәрсә алдың? *(Пирамида).* Балалар, Булат тартмадан нәрсә алды? (*Пирамида*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар).

**Тәрбияче.** Бу пирамида. Пирамиданың таякчыгы һәм бөҗралары бар. Таякчыкка кызыл, сары, яшел, зәңгәр бөҗраларны кидерәләр. Башта зур бөҗраны, соңыннан кечерәк, тагын кечерәк, ахыргы бөҗра - иң кечкенәсе. Менә нинди матур пирамида.

Балалар пирамидканы карыйлар, аның бөҗраларын салдыралар, төсен һәм зурлыгын атыйлар. Пирамиданы җыялар, җыйганда да төсен, зурлыгын әйтәләр, агачтан ясалган булуын билгелиләр.

– Балалар, пирамиданы тотып карагыз әле: пирамида йомшакмы, катымы? (*Каты*). Әйе, балалар, пирамида каты, ул агачтан ясалган. Пирамида нәрсәдән ясалган? (*Агачтан)*. Әйе, бу - агач пирамида. Бергәләп кабатлагыз әле: агач пирамида. Балалар, пирамида белән өстәлгә шакып карыйк әле. Ишетәсезме, нинди тавыш килә: шык-шык итә. (Күмәк кабатлаулар). Пирамида идәнгә төшеп китсә дә, ватылмый (Тәрбияче пирамиданы идәнгә төшереп карый). Пирамида ватылдымы? (*Ватылмады*). Дөрес, ватылмады, чөнки ул нык. Бергәләп кабатлагыз әле: нык. (Күмәк кабатлаулар). Әйе, пирамида агачтан ясалган, шуңа күрә ул каты һәм нык. (Тәрбияче кулын тартмага тыга). Тартмада тагын нәрсәдер яшеренгән бугай? (Матрешка ала). Бу нәрсә? *(Матрешка).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар).

**Тәрбияче.** Бу матрёшка. Матрёшка бик матур итеп киенгән. Нәрсәләр кигән соң ул? Сарафан кигән. Нәрсә кигән? (*Сарафан*). Бергәләп кабатлагыз әле: сарафан. Башына нәрсә бәйләгән? Яулык бәйләгән. Нәрсә бәйләгән? Бергәләп кабатлагыз әле: яулык.

- Балалар, матрёшканы тотып карагыз әле: матрёшка йомшакмы, катымы? (Каты). Әйе, балалар, матрёшка каты, ул агачтан ясалган. Матрёшка нәрсәдән ясалган? (*Агачтан*). Әйе, бу - агач матрёшка. Бергәләп кабатлагыз әле: бу – агач матрёшка. Балалар, матрёшканы өстәлдә биетеп алыйк әле. Сез кул чабыгыз. Ишетәсезме, матрёшка тып-тып басып биегән тавыш ишетелә. Тып-тып итә. (Күмәк кабатлаулар). Сезгә дә матрёшкалар бирим әле, биетеп карагыз. (Тәрбияче һәр балага матрёшкалар өләшә). Хәзер матрёшкагызны учларыгызга алып, кысып карагыз әле. Менә нинди нык матрёшка! Нинди матрёшка? (*Нык*). Бергәләп кабатлагыз әле: нык. Әйе, матрёшка агачтан ясалган, шуңа күрә ул каты һәм нык. Әйдәгез әле, матрешкалар турында җыр җырлыйк.



Без – матрешкалар, матур курчаклар.
Менә шундый, менә шундый
Чип-чиста куллар.
Без матрешкалар, матур курчаклар.
Менә шундый, менә шундый
Кызыл иреннәр.
Без – матрешкалар, матур курчаклар.
Тып-тып итеп биибез, без
Шат күңеллеләр.

Балалар җыр тексты буенча хәрәкәтләр ясыйлар: кулларын терсәктән бөгеп, алмаш-тилмәш бармаклары белән битләренә, иреннәренә тигезәләр. Кулларын билләренә куеп, аякларын тыпырдаталар.

**Тәрбияче.** Менә булдырдыгыз. (Балалар кул чабалар).

Тәрбияче балаларны урындыкларга утырта, үзе тартмага иелә, тыңлый.

– Әй – әй – әй, нәрсә бу? Ә – ә, бу син, шаянкай, тартмадан чык. Балалар, шаян песи тартмадан чыкмый. Әйдәгез, бергәләп чакырыйк үзен: тартмадан чык.

Тәрбияче тартмадан Йомшаккайны ала.

**Песи.** Исәнмесез, балалар! Сез мине онытмадыгызмы? Мин сезне көтә-көтә арып беттем. Уенчыклар да сезне сагындылар. Балалар бакчасын, сезне (Маратны, Алсуны...) мин бик сагындым. Беренче сюрприз сезгә ошадымы? Әйдәгез, хәзер уйнап алабыз. Уен «Нәрсә югалды?» дип атала. Карагыз әле, өстәлдә пирамида, матрешка тора. Күзләрегезне йомыгыз. Нәрсә юкка чыкты? (Балалар югалган уенчыкны атыйлар). Булдырдыгыз, балалар. Хәзер уенчыкларны үз урыннарына куегыз.

Тәрбияче балаларга уенчыкларны бирә, балалар аларны киштәгә куялар.

**Тәрбияче.** Балалар, Йомшаккайга сез ошадыгыз. Ул миңа: «Балалар үсеп килгәннәр, житез, шаян, акыллы, булганнар», – ди. Әйдәгез, Йомшаккай белән саубуллашыйк: Сау бул, Йомшаккай!

### Тема. МАНАРА

**Бурычлар:**

1) балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү;

2) предметның төсен, формасын, зурлыгын атый белүләренә ирешү;

3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Уенчык песи, тартма белән төрле зурлыктагы *(зур, кечерәк, кечкенә),* төрле төстәге *(кызыл, яшел, зәңгәр)* шакмаклар. Н. Гайсин сүзләре, Н. Зарипова музыкасына «Балалар бакчасында» җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче**. Балалар, безгә кунакка Йомшаккай килгән.

**Песи.** Исәнмесез, балалар. *(Исәнме, Йомшаккай).*

**Тәрбияче.** Йомшаккай үзе белән бер тартма алып килгән. Нәрсә бар икән тартмада? Балалар, ачып карамыйча, тартмада нәрсә бар икәнен әйтеп буламы? *(Юк).* (Тәрбияче тартманы ача, тартмадан төрле төстәге һәм төрле зурлыктагы шакмакларны ала, өстәлгә куя). Балалар, бу нәрсәләр? *(Шакмаклар).* Шакмак нинди төстә? *(Зәңгәр).* Балалар, шакмак зурлыгы буенча нинди? *(Зур).* Әйе, бу - зәңгәр зур шакмак. (Тәрбияче икенче шакмакны ала). Бу нәрсә? *(Шакмак).* Шакмак нинди төстә? *(Яшел).* Балалар, карагыз әле, кайсы шакмак зуррак, кайсы шакмак кечерәк? (Тәрбияче зәңгәр һәм яшел шакмакларны



күрсәтә). Әйе, зәңгәр шакмак зуррак. Яшел шакмак кечерәк. Әйе, бу - яшел кечерәк шакмак. Балалар, бу шакмак нинди төстә? *(Кызыл).* Кызыл шакмак зурлыгы буенча кечкенәме, зурмы? *(Кечкенә).* Әйе, бу - кызыл кечкенә шакмак. Хәзер шакмаклардан манара төзим. Башта аска зәңгәр зур шакмакны куям, аннан яшел кечерәк шакмакны зәңгәр зур шакмак өстенә куям, иң өскә кызыл кечкенә шакмакны куям. Балалар, карагыз әле, бу - манара. Бу нәрсә? (*Манара*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Йомшаккай сезгә дә төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге шакмаклар алып килгән. Хәзер сез шакмаклардан шундый манара төзерсез.

Тәрбияче Йомшаккай белән балаларга шакмаклар тарата, балалар манара төзиләр; тәрбияче үрнәкне күрсәтеп һәм эш алымнарын искә төшереп, балаларга ярдәм итә.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, манаралар әзер. Сез аны нәрсәләрдән төзедегез? *(Шакмаклардан).* Манара төзү өчен ничә шакмак алдык? *(Күп).* Зурлыгы буенча манара нинди шакмаклардан тора? (Тәрбияче корылмага күрсәтә). Әйе, зур шакмак, кечерәк шакмак, кечкенә шакмак. (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Шакмаклар нинди төстә? *(Яшел, зәңгәр, кызыл).* Әйе, балалар, манара зәңгәр зур шакмактан, яшел кечерәк шакмактан, кызыл кечкенә шакмактан тора. Булдырдыгыз! Балалар, Йомшаккайның шакмаклары күп иде. Ул аларны келәмгә бушатты. Әйдәгез, Йомшаккайга булышыйк, шакмакларны җыеп, тартмага салыйк. (Балалар шакмакларны җыеп тартмага салалар). Әмир, син тартмага нәрсә салдың? *(Шакмак).* Шакмак нинди төстә? *(Кызыл).* Шакмак нинди зурлыкта? *(Кечкенә).* Булдырдыгыз, балалар. Тартманы уен почмагына куйыйк. Сез шакмаклар белән тагын да уйнарсыз. Балалар бакчасында уенчыклар бик күп: курчаклар, машиналар, туплар һ.б. Алар сезне көтәләр, сезнең белән уйнарга телиләр.

Балалар бакчасында сезне апалар да көтеп алалар. Хәзер «Балалар бакчасында» дигән җырны җырларбыз. (Аудиоязма куела).

Чиста кием кидереп,
Мине көн саен иртән
Эшкә барышлый әни,
Эшкә барышлый әни
Ямьле бакчага илтә.
Әни белән барабыз
Юл буенча сөйләшеп,
Каршы ала апабыз,
Каршы ала апабыз,
Ягымлы исәнләшеп,
Ягымлы исәнләшеп.
Ямьле безнең бакчада,
Анда бик күп балалар,
Алар да минем кебек,
Алар да минем кебек,
Сөенешеп баралар,
Сөенешеп баралар.

## *Икенче бүлек.* КӨЗ

### Тема. КУЯН ҮСТЕРГӘН КИШЕР ҺӘМ ПОМИДОР

**Бурычлар:**

1) табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турында белемнәрен баету;

2) яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарларын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;

3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә



уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык куян, балалар санынча кишер, помидор, «тылсымлы тартма».

#### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балалар белән исәнләшә.

**Тәрбияче.** Балалар, уң кулыгызны күрсәтегез! Уң кулыгызга карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Уң кул бармаклары чиратлап, сул кул бармаклары белән исәнләшәләр:

Саумы, кояш!
Саумы, һава!
Саумы, иртә!
Саумы, йомшак җил!
Саумы, Туган ил!

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер елның кайсы вакыты? (*Көз*). Көз кайсы ел вакытыннан соң килә? (*Җәйдән соң килә*). Әйе, балалар, көз җәйдән соң килә. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Көз – елның бик матур вакыты. Көз кешеләргә мул уңыш бирә. Уңышны бакчада үстерәләр. Бакчада көз нинди нәрсәләр өлгерә? (*Яшелчәләр, җиләк-җимешләр*). Бергәләп кабатлагыз: «Бакчада җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгерә». Булдырдыгыз, балалар! Бүген бездә кунак бар. Нинди кунак икән? Табышмакка җавап тапсагыз, бик тиз белерсез.

Йөртә ул озын колак,
Үзе гаҗәеп куркак.
Уйланма инде озак,
Нәрсә ул? Йә, уйлап бак. (Куян).

– Нәрсә ул, балалар? *(Куян).* Дөрес, куян-озынколак. Әйдәгез, куян-озынколак белән исәнләшәбез! (*Исәнме, куян-озынколак!*).

**Куян.** Исәнмесез, балалар!

**Тәрбияче.** Балалар, куян-озынколак үзе белән «тылсымлы тартма» алып килгән. Карагыз әле, нинди матур тартма! (Күрсәтә). Аның эчендә нәрсә икән? Әйдәгез, тартманы селкетеп карыйк әле! (Тәрбияче тартманы селкетеп карый). Ишетәсезме, тавыш килә, димәк, тартма эчендә нәрсәдер бар. Балалар, куян-озынколак нәрсә әйтергә тели икән безгә?

Тәрбияче куянны үзенә якын китерә. Куянны утырта, тартманы өстәлгә куя.

**Тәрбияче.** Балалар, куян бик оста яшелчә үстерүче икән. Яз көне җирне казыган, тырмалаган, түтәлләр ясаган һәм анда төрле яшелчә орлыклары чәчкән. Җәй буе су сипкән, чүпләрен утаган. Куян бик тырышып эшләгән, чөнки ул үзе яшелчәләр ашарга бик ярата. Балалар, куян нинди яшелчәләр ярата? (*Кишер, кәбестә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Куян үзе үстергән яшелчәләрне тартмага салган һәм сезгә күрсәтергә алып килгән. Табышмакка җавап тапсагыз, нәрсә икәнен белерсез:

Җир астында алтын казык,

Алдык без аны казып.

– Кем белә, бу нәрсә? (*Кишер*). Әмир (*Алсу, Гүзәл һ.б.*), бу нәрсә? Әйе, бу - кишер. (Кишер күрсәтә). Кишер кайда үскән? (*Кишер яшелчә бакчасында үскән*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кишер яшелчә бакчасында кайда үскән? (*Кишер түтәлдә үскән*). Бергәләп кабатлагыз әле: кишер яшелчә бакчасында түтәлдә үскән. Балалар, яшелчәләр утырткан түтәлне таптарга, яшелчәләргә зыян салырга ярамый. Куян, балаларның һәрберсе берәр кишер алса, ярыймы? Алыгыз, балалар, алыгыз. Кишер нинди төстә? (*Кызыл*). Әйе, кишер кызыл. Балалар, кишерне тотып карагыз әле. Менә шулай. (Тәрбияче үзе күрсәтә). Ул шомамы? (*Шома*). Ә хәзер бармакларыгыз белән басып карагыз. Ул йомшакмы яки катымы? (*Каты*). Дөрес, балалар, кишер үзе шома, үзе каты. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: кишер шома һәм каты. Балалар, куян кишерне ашарга тәкъдим итә. Кишер ашагач, балалар тиз үсә икән. Кишердән нәрсәләр ясыйлар? (*Сок, салат ясыйлар, пирог пешерәләр, ашка салалар, кәбестә тозлаганда салалар, пылау пешергәндә турыйлар һ.б.*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

– Куян-озынколак, синең «тылсымлы тартмаңда» тагын нәрсәдер бар бугай. Күрсәт әле.

**Куян.** Күрсәтәм, күрсәтәм! Башта яшелчә турында табышмак әйтәм:

Итләч, йомры, яшелен
Өзеп алдым, яшердем;
Гаҗәпләндем бераздан,
Кояшсыз да кызарган. (Помидор).

– Кем әйтә ала, бу нәрсә икән? Әйе, помидор. (Куян помидор күрсәтә). Помидор нинди төстә? (*Кызыл*). Әйе, помидор кызыл. Помидор нинди формада? (*Шар формасында)*. Әйдәгез, кулларыгыз белән шар ясап күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр).

Балалар үзләре күрсәтә алмаса, тәрбияче кул бармаклары ярдәмендә шар формасын күрсәтергә ярдәм итә.

– Балалар, помидор шарга охшаган. Ә тагын нәрсәгә охшаган? (*Түгәрәккә охшаган*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Куянкай, һәрбер бала берәр помидор алса, ярыймы? Алыгыз, балалар, алыгыз. (Һәрбер бала берәр помидор ала). Хәзер, помидор сытылмаслык итеп, бармакларыгыз белән басып карагыз әле. Менә шулай. Помидор катымы яки йомшакмы? (*Йомшак*). Помидорны кулыгыз белән тотып, сыйпап карагыз әле. Помидор шомамы? (*Шома).* Балалар, куянга әйтеп күрсәтегез әле, помидор нинди? (*Помидор кызыл, түгәрәк, йомшак, шома*). Помидор кайда үсә? (*Помидор*

*яшелчә бакчасында түтәлдә үсә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Помидордан нәрсәләр ясыйлар? (*Салат, сок ясыйлар, тозлыйлар, яшелчәләрдән аш пешергәндә салалар*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, яшелчәләрне һәрвакыт юып ашарга кирәк. Ә хәзер мин сезне кишер белән сыйлыйм. Ашап карагыз әле, кишернең тәме нинди? (*Баллы, тәмле*). Кишер кетер-кетер киләме? Әйе, кишер кетер-кетер килә. Ә хәзер помидор белән сыйланыгыз. Балалар, помидор нинди? (*Кызыл, шома, йомшак*). (Балаларны активлаштыру). Помидорның исе бармы, иснәп карагыз әле? Помидор хуш ислеме? (*Помидор хуш исле*). Барыгызның да помидор ашап караганы бармы? Помидор тәмлеме? (*Тәмле*). Әйе, помидор бик тәмле. Булдырдыгыз, балалар!

### Тема. КУЯН ҮСТЕРГӘН КЫЯР ҺӘМ ШАЛКАН.

**Бурычлар:**

1) балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту;

2) яшелчәләрне (кыяр, шалкан) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белергә өйрәтүне дәвам итү; игътибарларын, аңга алуларын; диалогик сөйләм, сенсорик сәләтләрен үстерү;

3) сорауларга җавап бирү теләге тудыру; табигать белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык куян, балалар санынча кыяр, шалкан; «тылсымлы тартма».

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балалар белән исәнләшә.

– Балалар, бүген бездә кунак бар. Кем килгән икән безгә? Табышмакка җавап тапсагыз, бик тиз белерсез.



Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак (Куян).

– Нәрсә ул, балалар? *(Куян).* Дөрес, куян-озынколак. Әйдәгез, куян-озынколак белән исәнләшәбез! (*Исәнме, куян-озынколак!*).

**Куян.** Исәнмесез, балалар!

**Тәрбияче.** Балалар, куян-озынколак үзе белән тагын «тылсымлы тартма» алып килгән. Карагыз әле, нинди матур тартма! (Күрсәтә). Аның эчендә нәрсә бар икән? Әйдәгез, тартманы селкетеп карыйк әле! (Тәрбияче тартманы селкетеп карый). Ишетәсезме, тавыш килә, димәк, тартма эчендә нәрсәдер бар. Балалар, куян-озынколак нәрсә әйтә безгә?

Тәрбияче куянны колагы янына китерә.
Куянны утырта, тартманы өстәлгә куя.

**Тәрбияче.** Балалар, куянның бик оста яшелчә үстерүче икәнен сез беләсез инде. Яз көне җирне казыган, тырмалаган, түтәлләр ясаган һәм анда төрле яшелчә орлыклары чәчкән. Җәй буе су сипкән, чүпләрен утаган.

– Куян, синең тартмада нәрсә бар? Балалар, куян тагын табышмак әйтергә тели.

Кечкенә генә йорт,
Эче тулы корт. (Кыяр).

– Кем белә, бу нәрсә? (*Кыяр*). (Куян кыяр алып күрсәтә). Куянкай, безнең балалар моның кыяр икәнен барысы да яхшы беләләр. Балалар, кыяр нинди төстә? (*Яшел*). Әйе, кыяр яшел. Балалар, кыярга бармакларыгыз белән басып карагыз әле, ул йомшакмы яки катымы? (*Каты)*. Кыяр нинди: кытыршымы, шомамы? (*Шома*). Кыярның кытыршысы да була. Менә бу кыяр (күрсәтә) кытыршы. Килегез әле, кытыршы кыярны тотып карагыз әле. (Тәрбияче кулындагы кыярны балалар тотып карыйлар). Балалар, димәк кыяр шома гына түгел, кытыршы да була. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: кытыршы. (Индивидуаль

һәм күмәк кабатлау). Балалар, кыярдан нәрсәләр ясыйлар? (*Салат ясыйлар, тозлыйлар, яшелчәдән аш пешергәндә салалар*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, киселгән кыяр белән кул, бит тиресен чистартырга була. (Тәрбияче, кыярны кискәләп, вазага сала). Әйдәгез, кулларыгызны чистартып алыгыз әле. Менә шулай.

Тәрбияче күрсәтә. Балалар кул аркаларын, бармакларын киселгән кыяр телеме белән сыпыралар.

– Балалар, кыярның исе бармы? Иснәп карагыз әле! (*Кыяр хуш исле*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кыярны ашаганда нинди тавыш барлыкка килә? (*Кетер-кетер*). Куян, синең тартмада тагын нәрсәдер бар бугай әле? Әйдә, әйтеп кара әле табышмагыңны. Нәрсә икән ул?

**Куян.** Балалар, бу яшелчәне бабай чәчеп үстергән. Ул бик зур булып үскән. Бабай тартып чыгарырга теләгән - тартып чыгара алмаган. Бабай әбине, әби кызны чакырган. Алай да тартып чыгара алмаганнар. Кыз нәрсәне чакырган? (*Этне*). Ә эт нәрсәне чакырган? (*Песине*). Песи нәрсәне чакырган? (*Тычканны*). Шулай итеп, нәрсәне тартып чыгарганнар? (*Шалканны*). Менә ул шалкан! (Тәрбияче шалканны тартмадан алып күрсәтә). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: шалкан. Булдырдыгыз! Шалкан нинди төстә? (*Сары*). Әйе, шалкан сары. Балалар, шалканны тотып карагыз әле. (Тәрбияче үзе күрсәтә). Ул шомамы? (*Шома*). (Балаларны активлаштыру). Ә хәзер бармакларыгыз белән басып карагыз. Ул йомшакмы яки катымы? (*Каты*). Дөрес, шалкан үзе шома, үзе каты. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйбыз: шалкан шома һәм каты. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлау). Шалкан нинди формада? (*Түгәрәк*). Дөрес, балалар, аны йомры дип тә әйтергә була. Шалкан нинди? (*Шалкан йомры*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, шалканның нәрсәсе



бар? (Тамырына күрсәтә). (*Койрык*). Әйе, балалар, шалкан койрыксыман тамырлы. Койрыклы булгач, ул нәрсәгә охшаган соң? (*Тычканга*). Шалкан койрыклы, ләкин тычкан түгел. Сорауларга матур һәм дөрес итеп җавап бирдегез. Сез куянга да бик ошадыгыз. Әйдәгез, балалар, күчтәнәчләре өчен куян-озынколакка рәхмәт әйтик. «Яшелчәләрне ашарга кирәк, аларда витаминнар күп. Витаминнар ашагач, сез тагын да акыллырак булып үсәрсез, авырмассыз», – ди куян. Балалар, яшелчәләрне һәрвакыт юып ашарга кирәк. Кулларыгызны юып, шалкан ашарга утырыгыз. Тәмле булсын!

## Тема. САРЫ, КЫЗЫЛ ЯФРАКЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү;

3) көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү; балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** көзге һәм кышкы пейзажлар сурәтләнгән рәсемнәр, яшел төскә буялган ватман (келәм); һәр балага җитәрлек сары яки кызыл төстәге яфраклар, пумалалар, җилем, салфеткалар; «Яфрак бәйрәме» (Р.Еникеева көе, Л.Лерон сүз.) җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балалар белән исәнләшә.

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә матур көн телим. Безгә бүген хатлар килде. Менә бер хат, менә тагын бер хат. (Тәрбияче хатларны күрсәтә). Кем җибәрде икән бу хатларны? Әйдәгез, ачып карыйк әле. (Тәрбияче беренче конвертны ача, конверт эченнән кар бөртекләре ала). Бу нәрсә? (*Кар бөртекләре*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, бу кар бөртекләрен безгә кыш җибәргән. Кабатлыйк әле, кар бөртекләрен кайсы ел вакыты җибәргән? (*Кыш*). (Тәрбияче: «Кар бөртекләрен җәй җибәргәнме, кыш җибәргәнме?» – дип тә сорарга мөмкин).

Тәрбияче кышкы пейзаж сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә.

**Тәрбияче.** Балалар, менә бу рәсемнәргә карагыз әле. Биредә елның кайсы вакыты сурәтләнгән? (*Кыш*). Кыш нинди буяулар, төсләр ярата? (*Ак, ачык зәңгәр, караңгы зәңгәр һ.б.*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кыш нинди? (*Ак, матур, салкын, карлы, буранлы*). Сез кышны яратасызмы? Ни өчен? (*Кыш көне саф һава, кар күп, рәхәтләнеп чанада шуарга була. Кыш көне Яңа ел бәйрәме була, Кыш бабай килә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Булдырдыгыз, балалар! Икенче конвертта нәрсә бар икән соң?

Тәрбияче икенче конвертны ача, аның эченнән сары яфраклар ала.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? (*Сары яфраклар*). Бу хатны безгә көз җибәргән. Конверт эчендә сары яфраклар гына түгел, тагын нәрсәдер бар. Менә нәрсәләр бар!

Тәрбияче көзге пейзаж белән рәсемнәр күрсәтә.



**Тәрбияче.** Балалар, бу рәсемнәрдә елның кайсы вакыты сурәтләнгән? (*Көз*). Көз нинди буяулар, төсләр ярата? (*Сары, кызыл, яшел*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Дөрес, балалар, көз сары, кызыл, яшел төсләр ярата, шуңа күрә көзнең киеме дә чуар. Көзнең киеме нинди? (*Чуар*). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: чуар. Балалар, көз сезне бик ярата, шуңадыр, күрәсең, ул сезгә шушы рәсемнәрне, үзенең фотосурәтләрен бүләк итеп җибәргән. Ә сез көзне яратасызмы? Ни өчен? (*Көз көне тәмле-тәмле җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгерә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, сез ничек уйлыйсыз, көз кыштан соң киләме, әллә кыштан алда киләме? Балалар, көз һәрвакыт кыш алдыннан килә. Көз төрле төстәге яфраклар бүләк итә, ә кыш йомшак ак кар яудыра. Балалар, әйдәгез, бергәләп сүзләр белән уйнап алыйк. Кыш көне кар җирдә шыгыр-шыгыр килә. Кабатлагыз: шыгыр-шыгыр. Көз көне яфраклар җирдә кыштыр-кыштыр, шыштыр-шыштыр килә. Кабатлагыз: кыштыр-кыштыр, шыштыр-шыштыр. Булдырдыгыз, балалар! Кыш тавышларын да, көз тавышларын да истә калдырдыгыз! Табигать тавышлары бик матур, алар колакка ял бирә.

– Балалар, карагыз әле, нинди матур келәм. (Келәмгә сары яфраклар ясалган). Ничек уйлыйсыз, бу келәмдә елның кайсы вакыты сурәтләнгән? (*Көз*). Каян белдегез? (Балаларның җаваплары). Хәзер без дә сезнең белән шундый көзге келәм ясарбыз. Менә бу подноста яфраклар бар. Ничә яфрак бар? (*Күп*). Подноста нинди төстәге яфраклар бар? (*Сары, кызыл, яшел*). Балалар, көз көне сары, кызыл, яшел яфраклар җиргә коелалар. (Тәрбияче идәнгә яфраклар коя). Хәзер һәрберегез берәр яфрак алыгыз. Сездә ничә яфрак бар? (*Бер*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, яфракларыгызны күрсәтегез әле. Алар нинди? (*Сары, кызыл, матур*). Хәзер үз яфракларыгызны очыртыгыз һәм тотып алыгыз! Яфраклар авырмы, әллә җиңелме? (*Җиңел*). (Кабатлаулар). Балалар, сезгә көзге яфраклар ошыймы?

*Аудиоязмада «Яфрак бәйрәме» (Р.Еникеева көе, Л.Лерон сүз.) җыры яңгырый*. Алдан ук ватманнан келәм әзерләп куела. Балалар келәмгә яфраклар ябыштыралар. Тәрбияче ябыштыру кагыйдәләрен искә төшерә: пумала белән юка гына итеп җилем буяп, буялган ягы белән яфракны ябыштырырга һәм салфетка белән басып торырга.

**Тәрбияче.** Хәзер сары, кызыл яфракларны менә бу яшел келәмгә ябыштырабыз. Келәм матур килеп чыксын өчен, яфракларны бар җиренә дә ябыштырыгыз. Булдырдыгыз, балалар! Менә нинди матур келәм килеп чыкты! Дөрес, чиста, пөхтә итеп эшләдегез! Шуның өчен көздән сезгә бүләк – һәрберегезгә берәр яфрак! (Тәрбияче балаларга яфраклар өләшә).

## *Өченче бүлек.* МИН ҺӘМ МИНЕМ ГАИЛӘМ

### Тема. КУНАК КАРШЫЛЫЙБЫЗ

**Бурычлар:**

1) савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылышы турында белемнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; балаларны әңгәмәгә тарту;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү;

3) балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кыз һәм малай курчаклар, чәй өстәле, ашъяулык, тартмада савыт-сабалар: чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек, чәй кашыклары, сай тәлинкәләр, шикәр савыты, чәй савыты, конфет савыты, салфетка савыты; чәй, конфетлар, салфеткалар.



**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, сез кунакка барырга яратасызмы? Сез кемгә кунакка барырга яратасыз? (Активлаштыру). Ни өчен? (*Әбием тәмле әйберләр пешерә. Алсуның матур уенчыклары күп. Марат белән уйнарга яратам.*). Сезгә кунаклар киләме? (*Килә*). Кемнәр килә? Безгә дә бүген кунаклар килгән. Каршылыйк әле кунакны! (Тәрбияче кыз курчак алып керә). Балалар, кунакны ничек каршылыйлар? Әйе, кунакларга: «Исәнмесез! Без сез килүгә бик шат. Рәхим итегез! Түрдән узыгыз!» – диләр. (Тәрбияче курчакны урындыкка утырта).

– Балалар, курчак белән танышыгыз әле. Танышу өчен үзебезнең исемне әйтеп чыгарга кирәк. (Тәрбияче үрнәк бирә). Мин – Алсу Ринатовна. (Курчакка мөрәҗәгать итә) Синең исемең ничек?

**Курчак.** Минем исемем Мәрьям.

**Тәрбияче.** Бик яхшы! Балалар, курчакның исеме бик матур икән. Әйдәгез, кабатлыйк әле: Мәрьям. Гүзәл (Әмир, Марат, Әминә...), син дә Мәрьям белән таныш әле! (*Минем исемем – Гүзәл (Әмир, Марат, Әминә...).*

– Мәрьям кунак көтә. Аның янына Йосыф килергә тиеш. Балалар, кунаклар килгәч, нәрсә эшлиләр? (*Кунакларны чәй белән сыйлыйлар*). Мәрьям белән Йосыф та бергәләп чәй эчәргә җыеналар. Аның өчен нәрсә эшләргә кирәк? (*Өстәл әзерләргә кирәк*). Әйдәгез, Мәрьямгә өстәл әзерләргә булышыйк әле. Чәйне менә бу өстәлдә әзерлик. (Чәй өстәле алдан ук әзерләп куела). Балалар, бу нәрсә? (*Өстәл*). Ә менә бу нәрсә? (*Ашъяулык*). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: ашъяулык. Ашъяулыкны өстәлгә җәяләр. Чәй өстәле әзерләгәндә, нәрсәләр куярга кирәк? (Балаларның җаваплары). Әйе, чәй эчү өчен савыт-саба кирәк.

Тәрбияче тартмадан савыт-сабалар ала,
ә балалар аларның исемен атыйлар.

– Бу нәрсә? (*Чынаяк*). Ә бу нәрсә? (*Чәй тәлинкәсе*). Чынаякны менә шулай чәй тәлинкәсенә куялар. Ә бу нәрсә? (*Чәйнек*). Ә менә болар нәрсәләр? (*Чәй кашыклары*). Чәй кашыклары белән нәрсә эшлиләр? (*Чәйгә шикәр салып болгаталар. Чәй кашыклары белән кайнатма, бал, торт ашыйлар*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Ә бу нәрсәләр? (*Тәлинкәләр*). Бу сай тәлинкәләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: сай тәлинкәләр. Нәрсә өчен кирәк икән бу сай тәлинкәләр? Әйе, балалар, сай тәлинкәләр бәлеш, печенье, торт, вафли салыр өчен кирәк. Балалар, шикәр комын нәрсәгә салалар? (*Шикәр савытына*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Ә бу нәрсә икән? (Тәрбияче чәй савытына күрсәтә. Аның эчендә чәй барлыгын ачыклыйлар). Балалар, чәй һәрвакыт хуш исле булсын өчен, аны капкачлы савытка салалар. Чәй савыты капкачын ачыйк әле. Менә ул чәй. Ул нинди төстә? (*Кара*). Ә чәй тагын нинди төстә була? (*Яшел, кызыл*). Дөрес, балалар, яшел төстәге үлән чәе дә бар. Ә тагын җиләк-җимештән ясалган кызыл төстәге чәйләр дә була. Балалар, бармакларыгыз белән чәйне тотып карагыз әле. (Тәрбияче зуррак тәлинкәгә чәй сала, балалар аны тотып карыйлар). Чәй уалып тора, уала. (Тәрбияче бармаклары белән чәйнең уалганын күрсәтә). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: чәй уалып тора, уала. Чәйдән нинди ис килә? (*Чәй хуш исле*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Чәй бөртекләре эре дә, вак та булырга мөмкин. (Тәрбияче эре һәм вак чәй бөртекләре күрсәтә). Балалар, монда конфетлар да бар. Конфетларны нәрсәгә салабыз? (*Конфет савытына*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әйе, конфет савытына, менә ул. Сез конфет яратасызмы? (Балаларның җаваплары). Балалар, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек, чәй кашыклары, сай тәлинкәләр, шикәр савыты, конфет савыты бер сүз белән ничек атала? (*Савыт-саба*). Дөрес, балалар, савыт-саба. Бергәләп кабатлыйк: савыт-саба. Балалар, савыт-саба белән сак эш итәргә кирәк: төшеп китсә, бәрелсә, ватылырга мөмкин, чөнки алар пыяладан, керамикадан ясалган. Алып килергә кирәк булса, кулга бер генә савыт тотарга кирәк. Балалар, чәй эчкәндә өстәлгә салфеткалар куялар. Салфеткалар өчен дә аерым савыт бар. (Салфетка савытындагы салфеткаларга күрсәтә). Салфетка ни өчен кирәк? (*Авызны, кулны сөртү өчен*).

– Балалар, без чәй өстәле әзерләп бетердек. Менә Йосыф та килеп җитте.

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Тәрбияче балаларга малай курчакны алып керә.

**Йосыф:** Мәрьям, син өйдәме? Исәнме!

Тәрбияче үзе сорый яки берәр баладан сората.

Йосыф өйгә керә һәм урындыкка утыра.

**Тәрбияче.** Йосыф нәрсәгә утыра? *(Урындыкка*). Мәрьям белән Йосыф чәй эчәргә утыралар. Аларга нәрсә дип әйтергә кирәк? (*Чәйләрегез тәмле булсын*!) Бергәләп кабатлыйк: «Чәйләрегез тәмле булсын!» Балалар, булдырдыгыз! Мәрьямгә бик матур итеп өстәл әзерләргә булыштыгыз! Хәзер инде сез өйдә әниләрегезгә дә чәй өстәле әзерләргә ярдәм итә аласыз. Балалар, Мәрьям белән Йосыфның чәйләре бигрәк кайнар! Әйдәгез, аларның чәйләрен өреп суытыйк әле. (Балалар һаваны өрү хәрәкәте ясыйлар. Күнегү 7 тапкыр кабатлана).

– Мәрьям белән Йосыф тәмләп чәй эчкәннәр һәм өстәлне җыештырырга керешкәннәр. Әйдәгез, аларга булышыйк! (Балалар савыт-сабаларны җыештырырга булышалар). Марат, син кайсы савытны алып куйдың? (Балалар савыт-сабаларны алып куялар, аларның исемен атыйлар). Әйдәгез, Йосыфның Мәрьямдә кунакта булуы турында сөйлик әле.

– Мәрьямгә ... (*Йосыф кунакка килде*). Балалар чәй ... (*эчтеләр*). Чәй ... (*кайнар, баллы*). Мәрьям белән Йосыф чәй эчтеләр һәм уенчыклар белән ... (*уйнадылар*). Балалар, Мәрьям

белән Йосыф турында кем сөйләргә тели? (Тәрбияче 2-3 баладан сөйләтә).

– Балалар, Йосыфка китәргә кирәк. Әйдәгез, аны озатыйк. Кунаклар киткәндә, аларга нинди сүзләр әйтәләр? (Активлаштыру). Дөрес, балалар, аларга: «Сау булыгыз! Тагын килегез!»-диләр. Булдырдыгыз, бик яхшы. Әйдәгез, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыгыз әле. Башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып: «Без бик тәрбияле балалар!» – дип әйтегез.

## *Дүртенче бүлек.* МИНЕМ ЙОРТЫМ, МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ

### Тема. МИН – «КАМАЗ» ОНЫГЫ.

**Бурычлар:**

1) балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган «КамАЗ» машинасы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү;

2) аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү; «КамАЗ» машиналары белән кызыксынуларын үстерү;

3) туган шәһәр, «КамАЗ»эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** мольберт, шәһәр күренеше сурәтләнгән рәсем, «КамАЗ» машинасы, йөк машиналары.

**Эшчәнлек барышы.**

Балалар алдында шәһәр сурәтләнгән рәсем.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле бу рәсемгә. Рәсемдә сез нәрсәләр күрәсез? *(Йортлар, урам, автобус, кешеләр, КамАЗ машинасы).* Бу рәсемдә безнең шәһәр сурәтләнгән. Безнең



шәһәрнең исеме Яр Чаллы дип атала. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Без Яр Чаллы шәһәрендә яшибез. Яр Чаллы – матур шәһәр. Анда биек йортлар, киң урамнар, парк-скверлар күп. (Машина тавышы ишетелә). Балалар, тыңлагыз әле, нәрсә тавышы ишетелә? *(Машина).* (Тәрбияче «КамАЗ» машинасы ала һәм балаларга күрсәтә). Балалар, бу нинди машина? *(«КамАЗ» машинасы).* «КамАЗ» машинасын Яр Чаллы шәһәрендә заводта ясыйлар. «КамАЗ» заводын сезнең әби-бабаларыгыз төзегән. Алар бик тырышып эшләгәннәр. Сезне «КамАЗ» оныклары дип әйтергә була. (Активлаштыру). Булатның, Әминәнең әтиләре, Айратның, Камилнең бабасы да «КамАЗ» заводында эшлиләр. Алар «КамАЗ машиналары ясап чыгаралар. «КамАЗ» – йөк машинасы, ул йөк ташый. Әйдәгез, машинаны карыйк әле. Бу нәрсә? (Тәрбияче кабинага күрсәтә). Кабина. Бу нәрсә? *(Кузов).* Балалар, машинаның тагын нәрсәләре бар? *(Тәгәрмәчләре*). Айрат (Әмир, Булат), машинаның тәгәрмәчләрен күрсәт әле. Син машинаның нәрсәсен күрсәттең? Балалар, машинаны кем йөртә? *(Шофер).* Шофер кабинада руль артында утыра һәм машинаны йөртә. Юлда кешеләр очраса, шофер сигнал бирә. Машина сигнал биргәндә, нинди тавыш чыгара? *(Пи – пи – пи).* Машина йөргән җирдә уйнарга ярамый. Ни өчен? Әйдәгез, без сезнең белән шоферлар булып уйнап алыйк әле!

Тәгәрмәчкә тын өрәм
*(балалар насос белән тәгәрмәчкә һава тутыру хәрәкәте ясыйлар)*
Һәм моторны кабызам.
*(терсәктән бөгелгән кулларны алгы якка әйләндерәләр)*
Машинама утырам
*(руль тоткан, боргалаган хәрәкәтне күрсәтәләр*)
Һәм еракларга китәм.
*(сигнал тавышын кабатлыйлар: Пи – пи – пи!)*

Уен берничә тапкыр кабатлана

– Булдырдыгыз, балалар. Сез бик яхшы шоферлар булдыгыз. Хәзер йөк машиналары белән уйнагыз.

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ

### Тема. ТЫЛСЫМЛЫ ШКАТУЛКА.

**Бурычлар:**

1) балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк уяту;

2) балаларны чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын атарга өйрәтү; диалогик сөйләмнәрен үстерү, сорауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерергә өйрәтә башлау;

3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру.

**Җиһазлар:** шкатулка; төрле төстәге, төрле зурлыктагы, төрле формадагы чыршы уенчыклары, балалар санынча кәгазьдән киселгән кар бөртекләре, савытка салынган кар, «Чыршыкай-матуркай» җыры (В. Вәлиева сүзләре һәм көе) аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче кулына матур итеп бизәлгән шкатулка ала.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? (Серле тавыш белән). Әйе, бу шкатулка. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Бу гади шкатулка түгел, ул тылсымлы шкатулка. (Тәрбияче шкатулканы акрын гына селкетә). Анда нәрсәдер бар! Ачып карамыйча, анда нәрсә бар икәнен әйтеп буламы? *(Юк).* Дөрес, шкатулка эчендә



нәрсә бар икәнен белү өчен, аны ачып карарга кирәк. Алсу, кил әле, ач шкатулканы. Балалар, Алсу нишли? Әйе, Алсу шкатулканы ача. Алсу, син нәрсә алдың? *(Уенчык).* Балалар, бу сез уйный торган уенчык түгел, бу чыршы уенчыгы. Алсу, син алган чыршы уенчыгы ничек атала? *(Шар).* Алсу, шарны кара әле, ул формасы буенча нинди? *(Түгәрәк).* Балалар, шарны тотып карагыз әле, ул нинди: кытыршымы, әллә шомамы? (Тәрбияче балалар янына килә, балалар шарны тотып карыйлар). *(Шома).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Шар нинди төстә? *(Шар кызыл*). (Тәрбияче җебеннән тотып, шарны әйләндерә). Балалар, карагыз әле, шар ялтырый. Шар чыршыны бизәү өчен генә кулланыла. Төшеп китсә, ул ватыла. Шуңа күрә аны чыршыга элгәндә, бик сак булырга кирәк.

Тәрбияче балалар белән тагын ике шар карыйлар, алар төрле төстә, төрле зурлыкта, шома һәм кытыршы.

**Тәрбияче.** Балалар, без караган шарлар - чыршы уенчыклары. Алар түгәрәк формада, төрле зурлыкта, төрле төстә: кызыл, зәңгәр, сары, яшел. Шарлар барысы да шома. Шарлар белән чыршыны бизиләр. Тиздән Яңа ел бәйрәме җитәчәк, без чыршыны шундый шарлар белән бизәрбез. Чыршыбыз матур, купшы булыр, ялтырап торыр. Хәзер аларны, ватылмасын өчен, шкатулкага салып куйыйк. (Балалар, берәм-берәм килеп, уенчыкларны шкатулкага салалар). Булдырдыгыз! Әйдәгез, чыршы турында җыр тыңлыйбыз һәм биибез.

***Тәрбияче аудиоязмада В. Вәлиева сүзләре һәм көенә «Чыршыкай-матуркай» җырын куя. Балалар бииләр.***

## Тема. КУЯН БЕЛӘН ТИЕННЕ ЧЫРШЫ БӘЙРӘМЕНӘ ЧАКЫРАБЫЗ

**Бурычлар:**

1) балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү; тикшеренүләр барышында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазлар артикуляциясен ныгыту;

2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын формалаштыру;

3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру; кыргый җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** боздан ясалган муенса, тәлинкә, кәрзин, йомшак куян һәм тиен уенчыклары; чыршы, нарат агачлары макеты, кишер, чикләвек (муляжлар булса да ярый).

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, тиздән нинди бәйрәм якынлаша? (*Яңа ел бәйрәме. Чыршы бәйрәме*). Дөрес, балалар, Яңа ел бәйрәмен һәр кеше көтеп ала. Бар җирдә Яңа ел чыршылары бизәлә. Урман җәнлекләре дә бу бәйрәмне яраталар, балаларга кунакка киләләр, бергәләп уйныйлар, күңел ачалар. Мин бүген эшкә килгәндә ак карда куян эзләре күрдем һәм шул эзләр янында менә бу муенсаны таптым.

Тәрбияче тәлинкә күрсәтә,
тәлинкәдә боздан ясалган төймәләрдән муенса ята.

**Тәрбияче.** Балалар, муенса нәрсәдән ясалган, тотып карагыз әле? *(Боздан)*. Боздан ясалган муенса нинди: салкынмы (юешме, шомамы)? *(Салкын, юеш, шома)*. Балалар, бу төймәләрне кем төшереп калдырды икән? Сез ничек уйлыйсыз? *(Куян төшереп калдырган. Тиен төшереп калдырган. Аю төшереп калдырган.)*.



Әйдәгез, муенсаның хуҗасын эзләргә урманга барыйк. Төймә муенсаны менә бу кәрзингә салабыз. (Тәрбияче төймәләрне тәлинкәсе белән кәрзингә куя). «Кар көртләрен» ерып, аякларны күтәреп атлап барыгыз. Менә шулай. (Тәрбияче күрсәтә). Урманга килеп җиттек. Балалар, карагыз әле, куак төбендә нәрсәдер бар. Якынрак килеп карагыз. Нәрсә бу? (Тәрбияче куак төбендә утыручы куянга күрсәтә). Әйе, бу куркак куян. Куркудан куянның койрыгы калтырый. Менә шулай. (Тәрбияче телен чыгарып уңга, сулга хәрәкәтләр ясый). Әйдәгез, сез дә телләрегезне чыгарып, уңга-сулга хәрәкәтләр ясап алыгыз. Булдырдыгыз! Куян, кил әле монда. (Тәрбияче куянны кулына ала). Исәнме, куянкай! Балалар, куян белән исәнләшегез. Куянның ашыйсы килгән, аны сыйларга кирәк. Куян нәрсә ярата? *(Кишер, кәбестә)*. Дөрес, балалар, куян яшелчәләр ярата. Куян, син муенса югалтмадыңмы? (Куян карый да, кача). Балалар, куян җавап бирмәде, качты. (Тел шартлата). Әйдәгез, без дә сезнең белән куянның качканын аңлатып, тел шартлатып алыйк. Балалар, куянны сыйлый алмый калдык. Яңа ел күчтәнәче итеп, чыршы төбендә кишер калдырыйк, ул үзе сыйланыр.

– Балалар, кар көртләрен ера-ера, аякларны югары күтәреп, алга таба китәбез. Карагыз әле, агач ботагында матур тун кигән тагын бер җәнлек утыра. Нәрсә икән бу? (Тәрбияче балаларның игътибарын агач ботагында утырган тиенгә юнәлтә) *(Тиен)*. Исәнме, тиен! (Тәрбияче тел шартлата). Балалар, тиен сезнең белән шулай исәнләшә. Сез дә аның белән исәнләшегез: менә шулай тел шартлатыгыз. (Активлаштыру). Балалар, тиен нәрсә ярата? *(Гөмбә, чикләвек)*. Тиен кайда яши? *(Өендә)*. Тиеннең өе кайда була? (*Агач куышында*). Бергәләп кабатлагыз әле. Ул өендә үзе әзерләгән азыкны саклый. Тиен җәен чикләвек, чыршы, нарат күркәләре җыя, гөмбә киптерә. Ә кышын шулар белән туклана. Балалар, тиеннең кәефе юк, ул күңелсезләнгән. Тиен, нәрсә булды сиңа? (Тәрбияче тиенне тыңлый). Тиен боздан ясалган муенсасын югалткан икән. Тиен, без аны таптык, мә муенсаңны. (Тәрбияче

кәрзин эчен карый). Балалар, кәрзин эчендәге тәлинкәдә муенса юк. (Тәрбияче сулы тәлинкәне кәрзин эченнән ала). Тәлинкәгә карагыз әле, боздан ясалган матур муенса кая киткән икән? (Активлаштыру). Дөрес, балалар, бүлмәдә җылы иде, шуңа күрә боз муенса эрегән. Муенса нишләгән? *(Эрегән)*. (Активлаштыру). Балалар, тиеннең кәефен ничек күтәрергә соң? Тиен, борчылма, без сиңа боздан ясалган түгел, ә чын муенса бүләк итәбез. Киеп куй әле. Яңа ел күчтәнәче итеп, чикләвек бирәбез. (Тәрбияче тел шартлата). Балалар, ишетәсезме, тиен безгә рәхмәт әйтә. Тиеннең кәефе күтәрелде. Тиен белән куянны Яңа ел бәйрәменә чакырыйк: «Тиен, куян белән Яңа ел бәйрәменә кунакка килегез». Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк.

- Балалар, сезгә кышкы урманда ошадымы? Урманда нинди җәнлекләр күрдегез? Куян, тиен – кыргый хайваннар. Булдырдыгыз! Үзегезне мактап, кул чабыгыз!

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ

### Тема. «ЧАНАДА ШУАБЫЗ» РӘСЕМЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлеген аңларга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;

2) диалогик сөйләмнәрен, күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә-образлы фикерләүләрен үстерү;

3) кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү.

**Җиһазлар:** «Чанада шуабыз» рәсеме, ак гуашь, зәңгәр фонлы кәгазьләр, кышкы киемнән Алсу курчак.

**Эшчәнлек барышы**.

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, тыңлагыз:

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган,



Уйный җил, буран,
Бу кайчак, туган?
*Г. Тукай*

– Кем әйтә, табышмакта сүз елның кайсы вакыты турында бара? (Балаларның җаваплары). Әйе, кыш. Кышын җирне кар каплый, буран, җил уйный. Балалар чанада шуалар. Сез чанада шуарга яратасызмы? Мин сезгә чана шуучы балалар турында рәсем күрсәтәм. (Тәрбияче рәсемнең сурәтле ягын балаларга ача, карарга мөмкинлек бирә). Балалар, карагыз әле, рәсемдә кем сурәтләнгән? *(Балалар)*. Балаларга исем бирик. Бу малайның (кызның) исеме ничек? *(Әмир, Мәрьям, Кәмилә, Нияз)*. Ә бу – тәрбияче Рәхимә апа. Ул балаларны урамга алып чыккан. Балалар ничек киенгән? *(Җылы)*. Ни өчен балалар җылы итеп киенгәннәр? Әйе, урамда салкын. Әмиргә карагыз әле, ул капюшонлы зәңгәр куртка кигән. Әмирнең бүреге һәм бияләйләре җылы, йомшак йоннан бәйләнгән. Аягына кигән итекләре дә җылы. Әмиргә урамда салкын түгел. Мәрьям өстенә нәрсә кигән? (Балаларның җаваплары). Мәрьямнең курткасы нинди төстә? Әйе, Мәрьямнең курткасы яшел, куртканың капюшоны бар. Карагыз әле, Мәрьямнең башлыгы, бияләйләре турында нәрсә әйтергә була? Бергәләп кабатлыйк: Мәрьямнең башлыгы һәм бияләйләре йомшак һәм җылы. Мәрьям нәрсәгә утырган? Әйе, ул чанага утырган. Ниязга нәрсә булган? *(Егылган)*. Нияз нишләп егылган? *(Ул чанага утырып өлгермәгән)*. Тыңлагыз әле мине:

– Кышын балалар чанада шуарга яраталар. Рәхимә апа балаларны урамга алып чыкты. Балалар үзләре белән чана алдылар. Алар җылы киенгән: капюшонлы курткалар, йомшак, җылы бүрекләр һәм бияләйләр кигәннәр. Итекләре дә бик җылы. Балалар туңмыйлар. Мәрьям чанага утырды. Нияз да чанага утырырга теләде. «Әмир, көтеп тор, Нияз әле чанага утырмады», – диде

Рәхимә апа. Әмир чананың бавын кинәт кенә тартты да, Нияз егылды. Менә шундый күңелсез хәл килеп чыкты. Әмир үзенең хатасын аңлаган, ул Нияздан гафу үтенгән. Нияз да аңа үпкәләмәгән. Аннары балалар бергәләп чана шуганнар. Аларга бик күңелле булган. (Тәрбияче сөйләгәнен рәсем буенча күрсәтеп бара).

– Балалар, хәзер сезгә Марат кыш турында бер матур шигырь сөйләп күрсәтер.

Тәрбияче шигырь сөйләүче баланы алдан әзерли,
бала шигырьне яттан сөйли:

Салкын саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.
*Ә. Бикчәнтәева*

**Тәрбияче.** Балалар, Маратка кул чабыгыз. Ул кыш, кар бөртекләре турындагы шигырьне бик матур итеп сөйләде. Без хәзер сезнең белән кышкы урамга уйнарга чыгабыз.

## Тема. ҖИМЛЕК ЯНЫНДА.

**Бурычлар:**

1) кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту;

2) аваз иярткемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету; игътибарларын үстерү;



3) күзәтүчәнлек, кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Җимлек янында» рәсеме, җимлектә – чыпчыклар; сары гуашь, кәгазь (ватман), кәгазьдән ясалган кошлар (һәр балага җитәрлек), пумалалар.

### Эшчәнлек барышы.

**Тәрбияче.** Балалар, минем яныма килегез. (Тәрбияче балаларны тәрәзә янына чакыра). Хәзер тышта елның кайсы вакыты? *(Кыш).* Кышын кошларга азык табуы бик авыр. Без аларга җимлек куйдык. Аларны тукландырып торабыз. Искә төшерегез әле, җимлеккә нинди кошлар килә? *(Чыпчыклар, күгәрченнәр, песнәкләр, ала каргалар).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). (Тәрбияче рәсем күрсәтә). Карагыз әле бу рәсемне. Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән? *(Кошлар).* Бу кошлар ничек аталалар? *(Чыпчыклар).* Тыңлагыз әле, чыпчык турында мин сезгә бер шигырь укыйм:

Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык.
Миңа кычкыра:
– Чык әле, – ди, – чык.
Алдый ул, беләм,
Гел шулай итә.
Йөгереп чыксам,
Оча да китә.
*Фәнис Яруллин*

– Ничә чыпчык бар? (*Күп*). Чыпчыкның нәрсәләре бар? Дамир, рәсем янына кил, чыпчыкның гәүдәсен, башын, томшыгын, канатларын, койрыгын, тәпиләрен күрсәт. Балалар, Дамир күрсәтә, ә сез аның нәрсә күрсәткәнен әйтеп барыгыз.

Бала чыпчыкның башын, гәүдәсен, томшыгын, канатларын, койрыгын, тәпиләрен күрсәтә һәм балалар белән бергә атый.

– Балалар, чыпчык ала каргага караганда зурмы, кечкенәме? *(Кечкенә)*. Чыпчыклар нишлиләр? *(Җим чүплиләр).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Җимлек янында чыпчык үзен ничек тота? *(Ул кыю, җитез, өлгер, җимне тиз генә ала да, очып китә).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Чыпчыклар җим чүплиләр һәм нәрсә диләр? *(Чырык-чырык).* Әйдәгез, чыпчыклар булып чыркылдап алыгыз әле. *(Чырык-чырык).* Чыпчык чыркылдый. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «чыпчык чыркылдый». (Кабатлау).

– Балалар, әйдәгез, «Без – кошлар» уенын уйнап алыйк. Без һавада тыныч, салмак хәрәкәтләр ясап очабыз. (Балалар салмак, дулкынсыман хәрәкәтләр ясап, кулларын ян-яктан баш өстенә күтәрәләр һәм шундый ук хәрәкәтләр белән учларын аска каратып төшерәләр). Кошлар әкрен генә бер урында да торалар, әйләнгәләп тә алалар (ирекле тыныч бию башкаралар), кояш нурларында коеналар. Безгә җиңел, күңелле, рәхәт. Ә хәзер кошлар җиргә төшәләр.

– Балалар, хәзер урыннарыгызга утырыгыз.

Тәрбияче чыпчык тавышлары язылган аудиоязма куя.

– Ишетәсезме, чыпчыклар чыркылдаша. Каян килә икән бу тавыш?

Тәрбияче балаларның игътибарын тәрәзә төбендәге кәгазьдән ясалган кошларга һәм бакчада агач ботагында утырган кошларга юнәлтә.

– Балалар, кошлар ачыкканар. Әйдәгез, аларга ярдәм итик, ярма бөртекләре ясыйк.

(Тәрбияче пумаланың очы белән нокталар ясап күрсәтә. Балалар сары буяу белән ярма бөртекләре ясыйлар). Хәзер, әйдәгез, кошларны ярма бөртекләре белән сыйлыйк. Булдырдыгыз! Кошлар сыйландылар. Үзегезне мактап, кул чабыгыз! Хәзер без саф һавага чыгабыз. Анда кошларны ипи валчыклары, ярма, көнбагыш белән сыйларбыз.



## *Җиденче бүлек.* ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

### Тема. ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

**Бурычлар:**

1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үстерү;

3) балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** төркемгә йөрүче балаларның әтиләренең фотосурәтләре (хәзерге вакытта һәм армиядә хезмәт иткәндә төшкән фотосурәтләре булса, тагын да яхшырак).

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче балалар белән исәнләшә.

**Тәрбияче.** Кадерле балалар, барыгызга да матур көн телим! Уң кулыгызны күрсәтегез! Уң кулыгызга карагыз! Сул кулыгызны күрсәтегез! Уң кул бармаклары чиратлап сул кул бармаклары белән исәнләшәләр (башта чәнти бармаклар, аннары атсыз, аннары урта, аннары имән, соңыннан баш бармаклар):

Саумы, кояш!
Саумы, һава!
Саумы, иртә!
Саумы, йомшак җил!
Саумы, Туган ил!

**Тәрбияче.** Балалар, ни өчен безнең бүлмәбез шундый матур итеп бизәлгән икән? Бәлки, бүген тагын Яңа ел бәйрәме килгәндер? Ничек уйлыйсыз? (*Бүген әтиләр бәйрәме*). Дөрес, бүген әтиләр бәйрәме. Әтиләр бәйрәме булгач, әйдәгез, әтиләр турында сөйләшик. Сез әтиләрегезне яратасызмы? Ни өчен яратасыз? *(Ул көчле, тырыш, акыллы, мине ярата).*

– Балалар, сез әтиләрегезнең фотоларын алып килдегез. Шул фотога карап, әтиегез турында сөйләгез әле.

Балалар, фотога карап, үз әтиләре турында сөйлиләр.

**Айрат.** Бу минем әтием. Аның исеме – Азат. Әтием бик көчле. Без аның белән футбол уйныйбыз. Мин аны бик яратам.

**Азалия.** Бу минем әтием. Аның исеме – Алмаз. Әтием офицер. Ул армиядә хезмәт итә. Әтием Ватанны саклый.

**Илмир.** Бу минем әтием – Илдар. Әтиемнең машинасы бар. Мине машинага утыртып йөртә. Ул мине ярата. Мин дә әтиемне яратам.

Балалар сөйләгәнне диктофонга яздырырга яки альбомга язып куярга мөмкин.

**Тәрбияче.** Балалар, сез әтиләрегез турында бик матур итеп сөйләдегез. Чынлап та, сезнең әтиләрегез көчле, кыю, сезне яраталар икән, сәламәт булсыннар! Балалар, сез дә әтиләрегез кебек көчле буласыгыз киләме? Алай булгач, әйдәгез, «Каратист» күнегүен эшләп алыйк.

Балалар түгәрәк ясап басалар. Түгәрәк уртасына кыршау куелган. Бер бала кыршау уртасына баса – «каратист» була. Куллары, аяклары белән кискен хәрәкәтләр ясый. Калган балалар аның артыннан кабатлый.

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар. «Каратист» күнегүе сезне көчлерәк, кыюрак итәр. Армиядә хезмәт итү өчен егетләргә сәламәт, көчле булырга кирәк. Балалар, менә хәзер әтиләрегезнең армиядә хезмәт иткәндә төшкән фотоларын карыйк.



Альбом алдан ук балалар алып килгән фотолардан төзелә.

**Тәрбияче.** Балалар, бу фотоларда әтиләрегез хәрби киемнән. Нинди киемнән? *(Хәрби киемнән).* Ни өчен әтиләрегез бу фотоларда хәрби кием киеп төшкәннәр? *(Алар солдатта булганнар. Алар армиядә булганнар).* Нәрсә соң ул армия? *(Армиядә солдатлар хезмәт итә. Алар Туган илне саклыйлар).* Солдатлар нинди булырга тиеш? *(Көчле, кыю, батыр, сәламәт).* (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Бик дөрес, балалар. Менә бүген бәйрәм – Ватанны саклаучылар көне. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк: Ватанны саклаучылар көне. Ватанны саклаучылар көнен әтиләр, бабайлар, малайлар көне, ир-егетләр көне дип тә йөртәләр. Ватан сүзе, башкача әйткәндә, туган ил, туган җир була. Безнең малайлар да, үсеп җиткәч, армиядә хезмәт итәрләр, Ватанны саклаучылар булырлар. Бәйрәм көнне бабайларга, әтиләргә, абыйларга, малайларга бүләкләр бирәләр. Безнең төркемдә дә малайлар бар. Малайлар, барыгыз да басыгыз әле. Сезне чын күңелдән Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз. Сәламәт, кыю, батыр, көчле булып үсегез! Без сезгә кечкенә генә бүләкләр әзерләдек, менә алар.

Кызлар алдан әзерләгән бүләкләр тапшыралар.

**Тәрбияче.** Балалар, барыгыз да кулга-кул тотынып, түгәрәккә басыгыз, кулларыгызның җылысын бер-берегезгә бүләк итегез. Бер-берегезгә карап елмаегыз, сәламәтлек теләгез! Булдырдыгыз, балалар! Мин сездән бик канәгать! Рәхмәт сезгә!

## *Сигезенче бүлек.* СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ
### Тема. МИНЕМ ӘНИЕМ

**Бурычлар:**

1) әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;

3) балаларда әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «тылсымлы сандык», һәр балага бирәр сары һәм бишәр кызыл түгәрәк, «Әниләр бәйрәме» (Гариф Гомәр сүз., М.Бикбова көе) җырының аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

***Аудиоязмада «Әниләр бәйрәме» (Гариф Гомәр сүз., М.Бикбова көе) җыры яңгырый.***

**Тәрбияче.** Балалар, җырда кем турында җырлана? (*Әниләр турында*). Дөрес, балалар, җыр безнең яраткан әниләребезгә багышланган. Балалар, без бүген сезнең белән әниләр турында сөйләшәбез. Сезнең һәрберегезнең әнисе бар. Һәрберегез өчен сезнең әниегез иң яхшысы, иң кадерлесе, иң яратканы. Әниегез ягымлы итеп эндәшкәндә, елмаеп караганда, сезгә рәхәт буламы? (Балаларның җаваплары). Әни елмайганда, безгә бик рәхәт була. Шуңа күрә әниләрне борчымаска кирәк, алар һәрвакыт елмаеп торсыннар, матур булсыннар. Әниләр турында күп матур сүзләр әйтергә була. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Минем әнием матур, ягымлы, сөйкемле, йомшак куллы, эшчән». (Тәрбияче һәр сыйфатны аерым әйтә, балалар аның артыннан



кабатлыйлар). Менә без әниләргә күпме матур сүзләр әйттек. Булдырдыгыз! Әниегез сезгә нинди ягымлы сүзләр әйтә? (*Кызым, улым, акыллым, матурым, кояшым, җимешем, бәбкәм һ.б.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әниләрне яратыгыз, сүзләрен тыңлагыз, аларга ярдәм итегез. Кайчакта әниләрнең кәефләре булмый. Кайчан әниләр күңелсезләнә, кәефләре булмый? (*Балалар авырса, әниләр борчыла. Балалар әниләренең сүзен тыңламаса, әниләрнең кәефе бозыла.*) Дөрес, балалар.

– Сезнең әниегезнең исеме ничек? (Тәрбияче һәрбер баладан сорап чыга). Әниләрегезнең исемнәре бигрәк матур! Балалар, әниләрегез сезне нәрсәләр эшләргә өйрәтте? (*Йөрергә, сикерергә, кашык белән ашарга, киенергә, чәч тарарга, биергә, җырларга, шигырь сөйләргә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Менә күрәсезме, әниләрегез сезне нинди күп һөнәрләргә өйрәткән!

Тәрбияче балаларга «тылсымлы сандык» күрсәтә.

**Тәрбияче.** Балалар, бүген мин сезгә «тылсымлы сандык» алып килдем. Менә нинди матур сандык! Бергәләп кабатлыйк әле: сандык. Сандык эченә әйберләр салып куярга була. Балалар, бу гади генә сандык түгел, ә тылсымлы сандык. Бүген без сезнең белән бу «тылсымлы сандыкка» әниләр өчен иң матур сүзләрне «салып» куярбыз. Мин сандыкның капкачын ачам, сез әйткән сүзләр сандык эченә керә башларлар.

Балалар матур сүзләр әйтәләр. Тәрбияче балаларга өстәмә сораулар биреп, ярдәм итә.

**Тәрбияче.** Балалар, әниегез сезне кочаклап үбә, башыгыздан сыйпый, ягымлы итеп карый. Бергәләп кабатлыйк әле: ягымлы. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, әниегез сезне ничек итеп кочаклый, күрсәтегез әле. (Балалар үз-үзләрен кочаклыйлар).

– Менә «тылсымлы сандыкка» әниләр турында күпме матур сүзләр салдык! Булдырдыгыз, балалар! Бу матур сүзләр югалмасыннар, онытылмасыннар өчен, сандыкның капкачын ябып куябыз. Бәйрәм көнендә сандыкны ачарбыз һәм андагы матур сүзләрне әниләргә бүләк итәрбез. Мин сездән бик канәгать. Әниләребез исәнсау, матур, ягымлы, шат күңелле, бәхетле булсыннар!

Аудиоязмада «Әниләр бәйрәме» (Гариф Гомәр сүз., М.Бикбова көе) җыры яңгырый.

## *Тугызынчы бүлек.* ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Тема: ТЕРЕ ҺӘМ УЕНЧЫК КОШЛАРНЫ КАРАУ

**Бурычлар:**

1) тере һәм уенчык кошларны чагыштыру, уенчык кош - дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту;

2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү , сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү;

3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** читлектәге тере кош, уенчык кош (дымка уенчыгы), кошка ярма һәм су салу өчен савыт.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, безгә кунакка бер кош килгән. Кош белән исәнләшик әле. Исәнме, кош! Балалар, бу нәрсә? (*Читлек*). (Кабатлаулар). Кош нәрсә эчендә яши? (*Читлек эчендә*). Кош нәрсә эшли? (*Утыра, сикерә, безгә карап тора, башын боргалый*). Кошка сикерергә берәр кеше булышамы? (*Беркем дә булышмый, ул үзе сикерә*). Дөрес, безнең кош - тере кош, ул җанлы. Ул үзе сикерә. Исегезгә төшерегез әле, безнең кош тагын нәрсә эшли?



(*Су эчә, ярма бөртекләре чүпли*). Әйдәгез, тикшереп карыйк. Алсу, менә бу тәлинкәгә ярма бөртекләре сал да, читлек эченә куй әле! Булдырдың, Алсу! Балалар, кош нишли? (*Ярма бөртекләре чүпли*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Марат, син кошка су эчерт. Әйдә, су савытына чиста су сал! Балалар, кош нишли? (Су эчә). Балалар, кош турында кем кайгырта? (*Без үзебез*). Дөрес, балалар, сез үзегез кош турында кайгыртасыз. Ничек кайгыртасыз? (*Ашатабыз, суын алмаштырабыз, читлеген чистартабыз*). Без кошка, яратып-кечерәйтеп, нәрсә дип дәшәрбез икән? Уйлап карагыз әле, балалар. (*Кошчык, кошкай*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Әйе, кошчык, кошкай дип дәшәрбез.

– Балалар, әйдәгез, »Без – кошлар» уенын уйнап алыйк. «Без һавада тыныч, салмак хәрәкәтләр ясап очабыз, кояш нурларында коенабыз. (Ирекле тыныч бию башкаралар). Безгә җиңел, күңелле, рәхәт.» Ә хәзер кошлар җиргә төшәләр. Балалар, хәзер урыннарыгызга утырыгыз.

– Безгә тагын бер кош кунакка килгән. (Тәрбияче уенчык кош күрсәтә). Кош белән исәнләшик әле. Исәнме, кош! Карагыз әле, нинди матур кош! Бу кош тереме икән, ничек уйлыйсыз? (Балаларның җаваплары). Кошка ярма бөртекләре сибеп карыйк әле. Энҗе, сыйла әле кошны ярма бөртекләре белән. Балалар, кош ярманы чүплиме? (*Юк*). Ни өчен чүпләми? Су биреп карыйк әле. Кил әле, Әмир, булыш әле миңа! Ни өчен кош су эчми? Кош хәрәкәтләр ясыймы? Ни өчен хәрәкәтләнми икән соң? Нинди кош соң бу? (*Уенчык кош*). Карагыз әле, бу кош нинди матур итеп бизәлгән. Нинди төсләр күрәсез? (*Яшел, сары, кызыл, зәңгәр*). Уенчык кошны нинди бизәкләр белән бизәгәннәр? (*Түгәрәкләр, сызыклар, боҗралар*). Балалар, бу уенчык кошны оста (мастер) ясаган. Уенчык кошны кем ясаган? (*Оста, мастер*). Уенчык кош балчыктан ясалган. Уенчык кош нәрсәдән ясалган? (*Балчыктан*). Бу уенчык кош дымка уенчыгы дип атала. Ничек атала? (*Дымка уенчыгы*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Ничек уйлыйсыз, уенчык кош белән нәрсә

эшләп була? (*Кулга алырга, ашатып, су эчертеп уйнарга, матурлык өчен бүлмәгә куярга була*).

– Балалар, тере кош нәрсә эшли? (*Сикерә, оча, йөгерә, ашый, су эчә, җырлый*). Тере кош турында кайгыртырга кирәк. Ә уенчык кош белән нәрсә эшлиләр соң? (*Уйныйлар*). Балалар, уенчык кошларны ясау җиңел түгел. Балчыктан ясалган уенчыклар тиз ватылалар. Шуңа күрә алар белән бик сак уйнарга кирәк. Уенчык кош безнең бүлмәбезне матурлап, бизәп торсын. Мин аны киштәгә куям. Булдырдыгыз! Үзегезне мактап, кул чабыгыз!

## *Унынчы бүлек.* ЯЗ

### Тема. УРАМДА ЯЗ

**Бурычлар:**

1) балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау барышында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү;

3) язгы күренешләр белән кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту.

**Җиһазлар:** язгы күренешләр төшерелгән рәсем, «Язгы тамчы» җырының аудиоязмасы (М. Шәмсетдинова көе, Х. Хәкимуллина сүзләре).

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә бер матур шигырь сөйлим, тыңлагыз әле:

Яз килә, яз килә,
Кояш нурларын сибә.



– Балалар, мин нәрсә турында сөйләдем? (*Яз турында*). Балалар, бу рәсемгә карагыз әле. Сез монда нәрсә күрәсез? (Балаларның җаваплары). Бик дөрес әйттегез, балалар. Хәзер елның кайсы вакыты? *(Яз).* Язны барлык кешеләр дә көтә. Яз җиткәнен без ничек беләбез? (Балаларның җаваплары). Дөрес, балалар. Яз җиткәч, табигатьтә күп кенә үзгәрешләр була. Яз көне нинди үзгәрешләр була? *(Кояш ныграк җылыта, кар эри)*. Балалар, кояш нишли? (*Кояш җылыта*). Кояш ныграк җылыткач, кар эри. Яз көне кар нишли? (*Кар эри*). Яз көне тагын нинди үзгәрешләр була? (*Сулар җыела*). Дөрес, кояш ныграк җылыта, кар эри һәм сулар җыела. (Күмәк, индивидуаль кабатлаулар). Җыелган кар суын икенче төрле күлләвекләр диләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: күлләвекләр. (*Күлләвекләр*). Язын тамчылар тып-тып тама. Нәрсәләр тып-тып тама? (*Тамчылар*). Дөрес, тамчылар тып-тып тама. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: тып-тып-тып. Тамчылар нишли? (*Тамчылар тама*).

– Балалар, сез бүген сорауларга бик матур итеп җавап бирдегез Шуның өчен мин хәзер сезгә таныш булган язгы тамчы турында җыр куям. Ә сез биерсез.

Аудиоязмада җыр яңгырый**.** Балалар, җыр сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

Тып, тып, тып, ты-пы-тып,
Тып, тып, тып.
Тамчы тама талларга,
Талларымның бөреләре
Куаныша шуңарга, куаныша шуларга.
Тып, тып, тып, ты-пы-тып,
Тып, тып.

Яз тама тамчы булып.
Кояш нурлары биешә,
Шул тамчыларга кунып,
Шул тамчыларга кунып.

– Булдырдыгыз, балалар! Бик матур биедегез. Балалар, яз көне бар кешенең кәефе үзгәрә. Һәркем яз килүгә шатлана. Сезнең күңелегездә дә гел яз, шатлык кына булсын! Бергәләп, күңелле яшик!

## *Унберенче бүлек.* ҖӘЙ

### Тема. «КӘҖӘ ҺӘМ КӘҖӘ БӘТИЛӘРЕ» РӘСЕМЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны тәрбияче ярдәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга, аның турында сөйләргә, тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү; йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, дуслык турындагы күзаллауларын үстерү;

3) хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре» рәсеме.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез, уйныйбыз. Без барыбыз да кәҗәләр булабыз. (Тәрбияче балаларга кәҗә битлекләре кидерә).

– Балалар, кәҗәнең ничек итеп йөргәнен күрсәтегез әле. Кәҗә ничек кычкыра? (*Ме-е-е*). Балалар, кәҗәнең мөгезләрен күрсәтегез. (Балалар бармаклары белән башларында мөгез ясыйлар). Менә шулай. Булдырасыз! Барлык зур кәҗәләрнең дә мөгезе бар. Мөгез булгач, сөзәргә була! Ә хәзер уйныйбыз.



*Балалар, шигырь сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар:*

Мөгезле кәҗә бара,
Сөзәсе килеп бара.
Тәпиләре тек-тек-тек,
Ә күзләре леп-леп-леп.
Кем ботка ашамый,
Кем сөт яратмый,-
Сөзәмен! Сөзәмен! Сөзәмен!

Тәрбияче балаларны «сөзәргә» тели, балалар качалар һәм «ме-е-е» дип кычкыралар.

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар! Берегез дә сөздермәдегез. Хәзер кәҗә һәм кәҗә бәтиләре турында рәсем карарбыз. (Тәрбияче рәсемне мольбертка куя). Балалар, бу рәсемгә карагыз әле. Бу нәрсә? (Кәҗәгә күрсәтә). (*Кәҗә*).). Ә менә болар нәрсә? (*Кәҗә бәтиләре*). Әйе, бу - кәҗә, ул үзенең балалары - кәҗә бәтиләре белән. Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре, матур җәй килгәненә шатланып, яшел яфрак ашарга чыкканнар. Балалар, кәҗә нәрсә эшли? *(Кәҗә яшел яфраклар ашый).* (Күмәк кабатлаулар). Әйе, балалар, кәҗә куак янында басып тора һәм куак ботакларындагы яшел яфракларны ашый. Кәҗә кечкенәме, әллә зурмы? *(Кәҗә зур)*. Кәҗәнең башында нәрсә бар? *(Мөгез)*. Балалар, бармакларыгызны башыгызга куеп, кәҗәнең мөгезен күрсәтегез әле. Менә шулай, булдырдыгыз! Кәҗәнең башында тагын нәрсәләре бар? *(Колаклары, күзләре, сакалы бар).* (Күмәк кабатлаулар). Кәҗәнең гәүдәсе нәрсә белән капланган? *(Йон белән).* Кәҗәнең йоны нинди төстә? *(Ак йон)*. Кәҗәнең йоны тагын нинди? *(Йомшак, озын*). Кәҗәнең тәпиләре бармы? *(Бар)*. Кил әле, Гүзәл, кәҗәнең тәпиләрен күрсәт. Гүзәл кәҗәнең нәрсәләрен күрсәтте? *(Тәпиләрен).* Бу нәрсә? (Койрыгына күрсәтә). *(Койрык).*

– Балалар, ни өчен кәҗәнең муенына кыңгырау бәйләгәннәр

икән? (Тәрбияче үзе аңлата). Кәҗә башын селкетсә, кыңгырау челтери. Кыңгырау челтерәгәч, хуҗа кәҗәне бик тиз таба. Балалар, кәҗә бәтиләре нәрсә эшлиләр? *(Уйныйлар, шаяралар).* Кәҗә бәтиләре зурмы, әллә кечкенәме? *(Кечкенә)*. Кәҗә бәтиләренең мөгезе бармы? *(Юк)*. Әйе, кәҗә бәтиләренең мөгезе юк. Мөгезләре булмаса да, алар сөзешкән булалар. Кәҗә бәтиләренең тәпиләре юанмы, әллә нечкәме? *(Нечкә)*. Кәҗә бәтиләренең йоны нинди? *(Йомшак*). Әйе, йомшак һәм куе. (Активлаштыру). Бергәләп кабатлагыз әле: «Куе». Балалар, кәҗә бәтиләренең йоны кебек, кешеләрнең чәчен дә куе дип әйтәләр. Хәзер мин сезгә кәҗә һәм кәҗә бәтиләре турында сөйлим, сез игътибар белән тыңлагыз.

– Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре җәй көне куаклыкка килгән. Кәҗәнең мөгезе, сакалы бар, муенына кыңгырау такканнар. Аның йоны ак, озын. Кәҗә куак яфраклары ашый. Аның янында кәҗә бәтиләре уйный. Аларның тәпиләре нечкә, йоннары куе, йомшак. Кәҗә бәтиләре көч сынашалар. Арт аякларына басып, алгы аякларын бөгеп, бер-берсен этәләр. Шаян кәҗә бәтиләре сөзешкән булып уйныйлар. Сөзә алмыйлар, әле мөгезләре үсмәгән!

– Балалар, сезгә кәҗә бәтиләре ошадымы? Әйе, алар бик матур, кечкенә. Аларны рәнҗетергә ярамый. Сез ничек уйлыйсыз, кәҗә бәтиләре үзара дусмы икән? *(Дус).* Дус булгач, алар турында нәрсә әйтергә була? *(Алар - дуслар).* Әйе, балалар, алар да сезнең кебек дуслар. Көчле булу өчен, дус, тату булырга кирәк. Рәхмәт сезгә, балалар! Булдырдыгыз! Һәрвакыт дус һәм тату булыгыз!

## Тема. ТУЗГАНАК ЧӘЧӘГЕН КАРАУ

**Бурычлар:**

1) балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү;

2 үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту, хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;

3) үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** чәчәк битлекләре, вальс мелодиясе.

### Эшчәнлек барышы

Эшчәнлек балалар бакчасы территориясендә бара.

**Тәрбияче.** Балалар, як-ягыгызга карагыз әле. Безнең балалар бакчасы нинди матур! Ямь-яшел үлән, аллы-гөлле чәчәкләр үсә, күбәләкләр оча.

Матур җәй, кил безгә,
Кил, кил тизрәк син безгә,
Гөлләр белән бизәп җирне,
Чәчәкләр бир син безгә.

– Балалар, карагыз әле, безнең бакчабызда нинди чәчәкләр үсә! Мәйданчыгыбыз сары чәчәкләр белән капланган. Бу сары чәчәкләр турында без сезнең белән сөйләшкән идек инде. Сары чәчәкләрнең исеме ничек икән? (*Тузганак*). (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Тузганак нинди төстә? *(Сары).* Тузганак нәрсәгә охшаган? *(Кояшка).* Балалар, карагыз әле, тузганакның сары чәчәге сабагында утыра. (Балаларны активлаштыру). Сабак нинди? *(Озын, шома).*

Тәрбияче балаларга тузганак чәчәген, сабагын тотып карарга бирә.

– Балалар, сак кына чәчәкләрне тотып карагыз, иснәп карагыз, аларның матурлыгына сокланыгыз әле. Нәрсә тоясыз? Сары тузганакларга нинди ягымлы сүзләр әйтәсегез килә? Балалар, тузганакның шушы сары чәчкәләре бераздан ак йомгакка әйләнә. (Күрсәтә). Әйдәгез, шундый ак йомгакларны табыгыз әле. (Балалар эзлиләр). Беләсезме, бу йомгакларда нәрсәләр

бар? Нәни «парашютлар». Ә ул «парашютлар» – тузганакның орлыклары. Җил аларны ерак-еракларга очыртып алып китә. Алар төшкән урыннарда яңа тузганаклар үсеп чыга. Балалар, әйдәгез, җилгә ярдәм итик. (Балалар берәр тузганак өзеп алалар, аңа өрәләр, «парашютларны» очырталар, аларның очканын карап торалар). Бер-ике-өч! Тузганак, оч! Озак та үтмәс, сез очырткан «парашютлар»дан яңа сары чәчәкләр барлыкка килер. Тузганаклар бөтен җирдә үсә: урманда, болында, ишек алдында, безнең участокта да күп алар. Яшел үлән арасында сары башлы тузганаклар бик матур булып үсә. Алар безне сөендерәләр.

– Хәзер уйнап алырбыз. Сез тузганак чәчәкләре булырсыз. Яшел үлән өстенә җайлап утырыгыз. Сезгә карап кояш елмая. Ә сез басыгыз һәм менә шулай (*күрсәтә*) бармакларыгызны җәеп, кулларыгызны өскә - кояшка күтәрегез. Кояш чыкты, тузганаклар кояшка карыйлар, аның җылысын тоялар. (*Балалар кояшка таба үреләләр*). (*Кояшны аска төшерә*). Кояш йоклый, чәчәкләр дә йоклый. (*Чүгәлиләр, кулларны аска төшерәләр*). (*Уен 2-3 тапкыр кабатлана*).

– Балалар, сез бүген бик матур итеп җавап бирдегез. Мин сезгә кояшлы көннәр генә телим.



## СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ (КОММУНИКАЦИЯ) ӨЛКӘСЕ

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | «Ә» авазы | 1) «ә» сузык авазын дөрес итеп, кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту;<br>2) сорауларга җавап бирергә теләк уяту;<br>3) сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәрбияләү. |
| 11.09.-30.09. | Күз | Бакчада алмалар өлгерде | 1) балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү;<br>3) күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| | | Алтын көз | 1) тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә, аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда, «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүзләрен куллана, сүзләрдә [с], [з], [ф], [к] тартыкларын ачык итеп әйтә белүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын үстерү; тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; табигатьнең матурлыгын аңларга өйрәтү;<br>3) табигатькә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.10.-<br>15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Безнең гаилә | 1) балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни-әнием) күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3) олылар белән иркле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 16.10.-<br>04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | Уенчык песи баласы турында хикәяләү | 1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту; йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Алсуның яңа өе. | 1) балаларны йорт җиһазлары белән таныштыру, билгеләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү; бирелгән сорауны аңлау һәм җавап бирүләренә ирешү;<br>2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен, аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү; *артында, янында, өстендә* кебек сүзләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) йорт җиһазларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 15.11.-<br>31.12. | Яңа ел бәйрәме | Төлке бездә кунакта | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, «кайда?, «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән иркле аралашырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, тәрбиянең күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү;<br>3) җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 01.01.-<br>31.01. | Кыш | Алсуны урамга киендерәбез. (Кышкы киемнәрне карау) | 1) кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, аерым детальләрен, материалын атап, аны сурәтләргә; исемне сыйфат белән бәйләп, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел, зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүләрен, игътибарларын, күрү хәтерләрен үстерү;<br>3) киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Кар ява | 1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын, сөйләм сулышын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.02.-<br>23.02.. | Ватанны саклаучы-лар көне | Очучылар | 1) балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, формасын билгеләргә һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүгә күнектерүне дәвам итү; *очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү, игътибарларын үстерү;<br>3) очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. |
| 24.02.-<br>08.03.. | Сигезенче Март | Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! | 1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә катнашуга тарту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү;<br>3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| 09.03.-<br>31.03. | Халык җәүһәр-ләре | «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү | 1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;<br>2) *Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак, аю- Камытаяк* сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.04.-<br>20.04. | Яз | Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез | 1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне (*зур – кечкенә, калын – нечкә*) таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту;<br>2) балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. |
| 02.05.-<br>31.05. | Җәй | Автобуста сәяхәт | 1) балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү, йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту, йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3) тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Мин җәйне яратам | 1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә кулланууларын активлаштыру, «бер», «күп» төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хискичерешләрен, аңга алуларын үстерү;<br>3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |

## *Беренче бүлек.* САУ БУЛ, ҖӘЙ! ИСӘНМЕ, БАЛАЛАР БАКЧАСЫ!

### Тема. «Ә» АВАЗЫ

**Бурычлар:**

1) «ә» сузык авазын дөрес итеп әйтергә өйрәтергә, авазны кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту;

2) сорауларга җавап бирергә теләк уяту;

3) сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** курчак, карават, фланелеграф; сөт эчеп торган песи, ползунки кигән курчак рәсемнәре. Аерым өстәлгә уенчыклар куелган (аю, төлке, курчак, әтәч һ.б.).

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, матур итеп утырыгыз. Аркалар төз, куллар тез өстендә. Мин сезгә бер әкият сөйлим. Игътибар белән тыңлагыз.

– Яшәгән ди Күңелле Тел. Ул үзенең өендә яшәгән. Ә аның өе – авыз. Өйнең ишеге ачыла һәм ябыла. Менә шулай. (Тәрбияче күрсәтә*).* Тел өйдән йөгереп чыга да (күрсәтә), тагын кереп кача. Яңадан йөгереп чыга һәм тагын югала. Балалар, телләрегезне күрсәтегез әле. Менә шулай. Тел өеннән чыкты, аннан качты. Булдырдыгыз! (Берничә тапкыр кабатлыйлар). Тел әле кечкенә, аның бар нәрсәгә дә өйрәнәсе килә. Бервакыт ул песинең сөт эчкәнен күрде. (Тәрбияче фланелеграфка сөт эчеп торган песи рәсемен куя). Тел дә, песи кебек, сөтне ялап эчә башлады. Менә шулай! Сез дә песи кебек сөт эчкәнне күрсәтегез. Булдырдыгыз. (Кул чабалар).

– Тел төрле җырлар җырларга ярата. Аңа бигрәк тә кечкенә Әминә җыры ошый. (Тәрбияче балаларга ползунки кигән курчак күрсәтә). «Ә – ә – ә», – дип җырлый Әминә. Әминә авызын киң итеп ача, менә шулай итеп (тәрбияче күрсәтә):«Ә – ә – ә», – дип җырлый ул. Әминә ничек итеп җырлый? Әйдәгез, күрсәтегез әле. (Күмәк кабатлаулар). Хәзер, балалар, Әминәнең җырын аерым-аерым җырлап карыйк. Әмир (Айгөл, Ясминә һ.б.), Әминәнең җырын җырлап күрсәт әле. (Балалар «ә» авазын җырлыйлар). Булдырдыгыз, балалар! Ә хәзер без Әминәнең җырын җырларбыз: ә – ә – ә. Аны җеп шикелле итеп сузарбыз. Менә шулай.

Тәрбияче күкрәк турысында ике кулның баш һәм имән бармакларын кушып, җеп сузган кебек хәрәкәт ясый, ә – ә – ә авазын сузып җырлый (3 сек.). Күнегү 2-3 тапкыр кабатлана. Тәрбияче «ә» авазын әйткәндә, балаларның башларын туры тотуын күзәтә.

- Әминә арыды, аның йокысы килә. Әйдәгез, аны йокларга салыйк. Ул йокласын, ә без аңа бишек җыры җырлыйк.

Әлли – бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Бәү – бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.

Балалар тәрбияче белән 2-3 тапкыр бишек җырын җырлыйлар. Тәрбияче курчакны караватка сала.

**Тәрбияче.** Хәзер мин табиб булам. (Тәрбияче ак халат һәм ак баш киеме кия). Безнең төркемдәге курчакларның һәм җәнлекләрнең тамаклары авыртмый микән? Тикшереп карыйк. Камил, өстәлдәге аюны минем янга алып кил әле. Аюкай, авызыңны ач әле, ә-ә-ә дип әйт. (Бала уенда катнаша). Булдырдың. Тагын бер тапкыр ә-ә-ә дип әйт. Әкрен (кычкырып) әйт.

Тәрбияче шулай итеп берничә баланы чакыра. «Шифаханә» уены белән эшчәнлек тәмамлана.

## *Икенче бүлек.* КӨЗ
### Тема. БАКЧАДА АЛМАЛАР ӨЛГЕРДЕ

**Бурычлар:**

1) балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү;

3) күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Тылсымлы капчык», алма («тылсымлы капчыкка» салына); чыршы, каен, алмагач рәсемнәре; магнитлы такта, алмагач макеты, төрле төстәге зур һәм кечкенә алмалар, ковро-граф, зур һәм кечкенә ике чиләк.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, урамда елның кайсы вакыты? (*Көз*). Көз турында нәрсәләр беләсез? (*Яфраклар саргая, яңгырлар ява, кошлар җылы якка китәләр, бакчада җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгерә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Дөрес, балалар, көз билгеләрен яхшы беләсез. Без бүген сезнең белән җиләк-җимешләр турында сөйләшербез. Алма, слива, груша, кура җиләге, виноград, мандарин, әфлисун, лимон – болар барысы да җиләк-җимеш. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

Тәрбияче «тылсымлы капчык» күрсәтә.

– Балалар, бу нәрсә? (*«Тылсымлы капчык»*). Аның эчендә



әйбер бармы? Тотып карагыз әле. (Берничә бала капчыкны тотып карыйлар). Карамыйча гына, капчык эчендә нәрсә бар икәнен әйтеп буламы? (*Юк*). Хәзер мин сезгә табышмак әйтәм. Җавабын тапкач, «тылсымлы капчык» эчендә нәрсә барлыгын шунда ук әйтерсез:

Алсу битле кыз үсте,
Кызарып җиргә төште. (*Алма*).

– Дөрес, балалар. Үзегез зирәк, тапкыр булып чыктыгыз әле! (Тәрбияче капчык эченнән алманы ала). Карагыз әле, нинди матур алма! Алма нинди төстә? (*Алма кызыл*). Тагын нинди төстәге алмалар була? (*Яшел, сары*). Алма нинди формада? (*Шар формасында*). Алманың формасы турында тагын ничек дип әйтергә була? (*Алма түгәрәк*). Алманың түгәрәк икәнен каян белдең? (*Ул тәгәри*). (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Зурлыгы буенча нинди алмалар була? (*Зур, кечкенә*). Әйе, балалар, зур һәм кечкенә алмалар була.

Тәрбияче «тылсымлы капчыктагы» алмадан кечерәк булган алманы алдан әзерләп куя. Балалар ике алманы чагыштыралар.

**Тәрбияче.** Балалар, менә бу алмаларның да берсе зур, икенчесе кечкенә. Барыгызның да алма ашап караганыгыз бармы? (*Бар*). Алманың тәме нинди соң? (*Баллы*). Баллы алма турында тагын ничек әйтергә була? (*Татлы, шикәрле*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Алмалар баллы, татлы гына буламы? Тәме буенча алмалар тагын нинди була? (*Ачы. Әче*). Балалар, алма ни өчен кирәк? (*Алманы ашыйлар*). Алмадан нәрсәләр ясыйлар? (*Сок, компот, повидло ясыйлар, пирог пешерәләр*). Дөрес, балалар, алма бик файдалы, алмада витаминнар күп. Балалар, алманың исе бармы? Иснәп карагыз әле. Дөрес, алманың исе бар. Алмадан нинди ис килә? (*Алма исе, хуш ис килә*). Әйдәгез,

бергәләп: «Ә-ә-әх! Алмадан нинди тәмле ис килә!»- дип әйтик. (Балалар җөмләне кабатлыйлар). Булдырдыгыз, балалар! Балалар, кешеләрнең дә *бит алмалары* бар. Менә алар! Сез дә тотыгыз әле, күрсәтегез әле бит алмаларыгызны. Бит алмаларыгызны бармакларыгыз белән сыйпагыз, яратыгыз. Менә шулай! (Балалар бит алмаларын сыйпыйлар). Хәзер бит алмаларыгызны чын алмалар шикелле кабартып, түгәрәкләгез. Менә шулай. (Бераз шулай түгәрәкләп торалар, аннары сулыш чыгаралар). Иреннәрегез белән кысып кына озак итеп сулыш чыгарыгыз!

Тәрбияче күрсәтә. Күнегү 2-3 тапкыр кабатлана.

– Балалар, без сезнең белән алмадан повидло, кайнатма ясыйлар дип сөйләштек. Әйдәгез, алма кайнатмасын ялап карыйбыз. Авызыгызны ачыгыз, елмаегыз. Телне киң итеп чыгарып, өске иренегезне ялагыз. Тел өстән аска хәрәкәтләр ясый. Менә шулай! (Тәрбияче күрсәтә). (Күнегү 5-10 тапкыр кабатлана). Хәзер тел авыз эченә кереп китә, авыз ябыла. Булдырдыгыз, балалар!

Тәрбияче коврографка чыршы, каен, алмагач рәсемнәре куя.

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә агач рәсемнәре күрсәтәм. Игътибар белән карагыз, яхшылап уйлагыз, бу агачларның кайсында алма үсә икән?

Тәрбияче алма күрсәтә. Берәр баланы чакыра.
Чакырган бала алма үскән агачны күрсәтә.

– Дөрес, ә ничек атала соң бу агач? (*Алмагач*). Балалар, алмагач кайда үсә? (*Бакчада. Алма бакчасында*).

– Балалар, ә хәзер без сезнең белән бер уен уйнап алырбыз. Менә бу алмаларны җыябыз. (Тәрбияче төрле зурлыктагы кызыл, яшел, сары алмалар күрсәтә). Бу алма зурмы, кечкенәме?



(*Кечкенә*). Ә бу алма нинди зурлыкта? *(Зур)*. Әмир, кил әле, зур чиләкне күрсәт. (Күрсәтә). Бу чиләк нинди зурлыкта? *(Зур)*. Бу чиләк зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә)*. Ә хәзер зур алмаларны зур чиләккә, ә кечкенә алмаларны кечкенә чиләккә җыярбыз. (Балалар җыялар).

– Балалар, алмаларны дөрес җыйдыгызмы, тикшереп карыйк әле.(Тәрбияче балалар белән бергә ике чиләкне дә карыйлар). Булдырдыгыз, балалар! Бер дә ялгышмагансыз. Зур чиләккә нинди зурлыктагы алмалар җыйдыгыз: кечкенәме, зурмы? (*Зур*). Кечкенә чиләккә нинди зурлыктагы алмалар җыйдыгыз? (*Кечкенә*). Балалар, нинди төстәге алмалар җыйдыгыз? (*Кызыл, яшел, сары*). Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: «Без зур һәм кечкенә чиләкләргә кызыл, яшел, сары алмалар җыйдык». Бик яхшы!

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

– Балалар, ишек шакыйлар бугай. Әллә кунак килдеме икән?

Тәрбияче ишекне ачып карый, һәр балага җитәрлек итеп алмалар салынган кәрзин алып керә.

– Балалар, карагыз әле, бакчачы бабай сезгә күчтәнәчкә алмалар җибәргән, рәхмәт аңа! Кулларыгызны юыгыз да, алма ашарга утырыгыз! Алмалар тәмле булсын!

### Тема. АЛТЫН КӨЗ

**Бурычлар:**

1) тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә өйрәтүне; аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда, «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүзләрен куллана, сүзләрдә [с], [з],

[ф], [к] тартыкларын ачык итеп әйтә белергә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын; табигатьнең матурлыгын тоемлауларын, тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирә белүләрен үстерү;

3) табигатькә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** көз рәсеме төшерелгән рәсем; кызыл һәм сары тасмалар бәйләнгән ике кәрзин; һәр балага кызыл һәм сары яфракларның контурлы сурәтләре, берәр алма.

**Эшчәнлек барышы**

Тәрбияче. Балалар, хәзер урамда елның кайсы вакыты дип уйлыйсыз? (*Көз*). Әйе, көз. Ә ни өчен көз дип уйлыйсыз? (*Яфраклар саргая, салкын; яңгырлар ява, кошлар җылы якка китәләр*). (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар). Дөрес, балалар, агачларда сары яфраклар күренә, үләннәр саргайды, яңгырлар ява.

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

– Балалар, көз килгәч, үләннәр нишләде? (*Саргайды, шиңде*). Бу җөмләне бергәләп кабатлагыз әле: «Көз килгәч, үләннәр саргайды, шиңде». (Тәрбияче балаларга көз темасына рәсем күрсәтә). Балалар, ә менә бу рәсемдә елның кайсы вакыты икән? (*Көз*). Елның нинди матур вакыты! рәсемдә нәрсә сурәтләнгән? Рәсемдә ничә агач бар? *(Бер)*. Дөрес. Агачларда нәрсәләр үсә? (*Яфраклар*).

– Балалар, карагыз әле, көз безгә нинди матур кәрзин җибәргән (Кәрзиннең өсте капланган). Ә кәрзиндә нәрсә бар икән? Карамыйча гына белеп буламы? Балалар, барыгыз да минем күзләремә карагыз, мин сезгә кәрзиндә нәрсәләр бар икәнен белергә ярдәм итәрмен:

– Алар агачта үсәләр,- агачның күлмәге кебек. Нәрсәләр икән ул?



«Алар агачта үсәләр, агачның күлмәге кебек», дигәч, башка сыйфатларын әйтмичә генә балалар әйткәнне тыңларга кирәк, бәлки, берәрсе әйтер. Әгәр дә әйтә алмасалар, яфракларны сурәтли торган тагын бер сыйфатны атыйлар; мәсәлән, җилдә селкенәләр, яшел төстә, көз көне сары, кызыл төстә дә булалар. Һәм шулай предметка хас 4-5 сыйфатны атагач та, нәрсә икәнен әйтә алмасалар, тәрбияче үзе ярдәм итә.

– Дөрес, балалар, бу яфраклар була. Бу кәрзиндә төрле төстәге яфраклар. Карагыз әле, алар ничек күп! Ничек уйлыйсыз, көз агачларның яфракларын нинди төскә буяган? (*Кызыл, сары*). Әйе, көз агачларның яфракларын сары, кызыл төскә буяган. Әйдәгез, бу җөмләне бергәләп кабатлагыз әле: «Көз агачларның яфракларын сары, кызыл төскә буяган». Сары төс күп булганга, көзне «алтын көз» дип йөртәләр. Нинди көз? (*Алтын көз*). (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар). Барлык яфраклар да бер төслеме, яисә төрле төстәме? (*Төрле төсле: кызыллары да, сарылары да бар*). Яфраклар барысы да бер төслеме? (*Юк, алар төрле төсле: яшел, сары, кызыл яфраклар*). Ә бу яфрак нинди төстә? (*Сары*). Ә монысы нинди төстә? (*Кызыл*). Монысы нинди төстә? (*Яшел*). Бу ике яфрак (күрсәтә) бертөслеме, яисә төрле төстәме? (*Төрле төстә*). Алар нәрсәләре белән төрле? (*Кызыл, сары*). Сез төсләре буенча төрле дип әйтергә телисезме? Кабатлагыз әле: төсләре буенча төрле.

Балалар бер-берсенә «төсләре буенча төрле» дип әйтәләр. Балалар тәрбияче белән бергә «сары», «кызыл», «төрле төстә» сүзләрен кабатлыйлар

**Тәрбияче.** Агачта нинди төстәге яфраклар бар? (*Яшел, сары, кызыл*). Бергәләп кабатлагыз әле: «Агачта яшел, сары, кызыл төстәге яфраклар бар». Ә яфраклар нәрсәләре белән бертөрле? (Балалар яфракларның охшашлыкларын аңласалар да, җавап бирергә авырсыналар. Яфракларны берсе өстенә

икенчесен куеп карыйлар). Мин сезгә ярдәм итәм: яфраклар үлчәмнәре (размеры) буенча бертөрле. (Балаларны активлаштыру: балалар «үлчәм», «үлчәмнәре буенча бертөрле» фразаларын бергәләп, хор белән һәм һәр бала үзенә үзе әйтеп карыйлар). Ә хәзер уйнап алыйк. Сары тасмалы кәрзиндә сары яфраклар, ә кызыл тасмалысында кызыл яфраклар яши. Барлык яфраклар да үз кәрзиннәрендәме? (Балаларны активлаштыру). Ә хәзер күзләрегезне йомыгыз. Мин кыңгырау шылтыраткач, күзләрегезне ачарсыз һәм кәрзиннәрдә нәрсә үзгәрүен әйтерсез. (Тәрбияче яфракларның урыннарын алыштыра. Балалар адашкан яфракларны табып, үз урынына салалар*)*.

Тәрбияче балаларның эшчәнлеген күзәтеп тора.

– Дөрес, бер яфрак адашкан. Кызыл яфраклар арасына сары яфрак килеп кергән. Ничә сары яфрак? (*Бер*). Ничә кызыл яфрак? Дөрес! Тагын бер кат уйнарга телисезме?

Уен тагын бер кат кабатлана, яфракларның төсләре генә алыштырыла.

**Тәрбияче.** Миндә ничә яфрак? (*Берәү дә юк*). Ә сездә ничә яфрак? (*Берәү дә юк*). Ә кәрзиннәрдә ничә яфрак бар? (*Күп*). Дөрес, күп. Көз көне сары, кызыл яфраклар җиргә коела. (Тәрбияче идәнгә яфраклар коя, кәрзиндә берничә генә яфрак калдыра). Бергәләп кабатлагыз әле: «Көз көне сары, кызыл яфраклар җиргә коела». (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар). Балалар, карагыз әле, идәндә ничә яфрак? (*Күп*). Кәрзиндә ничә икән? (*Аз*). Берәр яфрак алыгыз әле. Кызыл яфракларны кызыл тасмалы кәрзингә, ә сары яфракларны сары тасмалысына салыгыз. Сездә ничә яфрак? (*Бер*). Яфрак нинди төстә? Кайсы кәрзингә саласың? Дөрес! Дөрес эшләдегез, шуның өчен сезгә Көздән бүләк - һәрберегезгә берәр матур алма. **(**Һәр балага алма тарата**)**.



– Балалар, алмалар нинди формада? (*Шар формасында. Түгәрәк формада*). Дөрес, шар формасында. Түгәрәк формада дип тә әйтергә була. Алманы уң кулыгызга алыгыз! Сул кулыгызга алыгыз! Алманы өстәлдә тәгәрәтеп карагыз! Алманы ике кулыгызга алыгыз! Ул катымы, йомшакмы! (*Каты*). Алманы иснәп карыйк әле, нинди ис килә алмадан? (*Тәмле ис, хуш ис*). Сез нинди төстәге яфраклар белән уйнадыгыз? Көз сезгә нәрсә бүләк итте? Кулларыгызны юыгыз, алма ашарга утырыгыз! Алмагыз тәмле булсын!

## *Өченче бүлек.* МИН ҺӘМ МИНЕМ ГАИЛӘМ

### Тема: БЕЗНЕҢ ГАИЛӘ

**Бурычлар:**

1) балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни-әнием) күнектерү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;

3) олылар белән ирекле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гаилә (әти, әни, бабай, әби, кыз, малай) сурәтләнгән рәсем; әти, әни, бабай, әби, кыз сурәтләнгән рәсемнәр; күп әниләр, әтиләр, әбиләр, бабайлар, кызлар, малайлар сурәтләнгән рәсемнәр, малай курчак.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунак килгән. Каршылыйк әле кунакны! (Тәрбияче кыз курчак алып керә). Балалар, кунакны ничек каршылыйлар? Әйе, кунакларга: «Исәнмесез! Без сез килүгә бик шат. Рәхим итегез! Түрдән узыгыз!»- диләр. (Күмәк кабатлаулар).

Тәрбияче курчакны урындыкка утырта.

– Балалар, курчак белән танышыгыз әле. Танышу өчен бер-беребезнең исемнәрен әйтеп чыгарга кирәк. (Тәрбияче үрнәк бирә). Мин – Алсу Ринатовна. (Курчакка мөрәҗәгать итә). Синең исемең ничек?

**Әминә.** Минем исемем Әминә.

– Бик яхшы! Балалар, курчакның исеме бик матур икән. Әйдәгез, кабатлыйк әле: Әминә. (Балаларга мөрәҗәгать итә). Гүзәл (Әмир, Марат, Әминә...), син дә Әминә белән таныш әле! (*Минем исемем – Гүзәл (Әмир, Марат, Әминә...).* (Индивидуаль кабатлаулар). Балалар, Әминә сезгә бер рәсем алып килгән. (Тәрбияче гаилә төшерелгән рәсем күрсәтә). Игътибар белән карагыз әле бу рәсемгә. Бу рәсемдә сез кемнәрне күрәсез? (*Әти, әни, әби, бабай, кыз, малай*). Балалар, әти, әни, әби, апа, сеңел, абый, эне - бик якын кешеләр. Алар сезнең туганнарыгыз. Туганнарыгызны яратыгыз! Әйдәгез, аларны ратуыбызны ягымлы сүзләр әйтеп белдерик. Әти сүзен ягымлы итеп әйтеп күрсәтегез әле. (*Әтием*).

Шул рәвешле башкаларны да рәсемдә күрсәтеп, ягымлы итеп (бабам, бабакай; әбием, әбекәй; әнием, әнкәй; апам, сеңлем, абыем, энем) әйтеп чыгалар.

**Тәрбияче.** Бик яхшы! Сез Әминәгә дә бик ошадыгыз. Балалар, урындыкларга утырыгыз әле. Бармак уены уйнап алырбыз.

Бу бармак – бабай,
Бу бармак - әби,
Бу бармак - әти,
Бу бармак - әни,
Бу бармак – нәни бәби,
Аның исеме – чәнти!

Тәрбияче уенның сүзләрен әйтә, бармаклар белән уйнап күрсәтә. Балаларның уенда катнашуын хуплый.



**Тәрбияче.** Балалар, Әминә башка рәсемнәр дә алып килгән. (Тәрбияче бер әни (әти, әби, бабай, кыз, малай) һәм күп әниләр (әтиләр, әбиләр, бабайлар, кызлар, малайлар) төшерелгән рәсемнәр күрсәтә). Балалар, бу рәсемдә – әниләр. Алар күп булганда - әниләр. Бер генә булса, ничек була ? (*Әни*).

Тәрбияче әле күп әниләр, әле бер генә әни төшерелгән рәсемнәр күрсәтә. Балалар, күп әниләр төшерелгән рәсемгә «әниләр» (әтиләр, әбиләр, бабайлар, кызлар, малайлар) диләр, ә бер генә булганда «әни» (әти, әби, бабай, кыз, малай) дип әйтәләр.

**Тәрбияче.** Сез сорауларга бик матур җавап бирдегез. Мин бик шат. Булдырдыгыз, балалар! Әминә дә сезнең белән уйнарга кала. Сез бик акыллылар. Алга таба да шундый булыгыз! Сезнең һәрберегезгә мин бүген елмайган кояш рәсеме бүләк итәм. Әйдәгез, без сезнең белән кояш нурлары ясыйк әле. Кулларыгызны алга сузыгыз, бер-берегегез белән кулга-кул тотышыгыз. Үзегезне җылы кояш нуры кебек күзаллап, тыныч кына басып торыгыз. Әйдәгез, кулларны алга сузып, кояш нурларын әтигә, әнигә, әбигә, бабайга - барлык кешеләргә бүләк итик.

## ***Дүртенче бүлек.*** МИНЕМ ЙОРТЫМ, МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ

### Тема. АЛСУНЫҢ ЯҢА ӨЕ.

**Бурычлар**:

1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү;

3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту, йорт

хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** курчак, аның бүлмәсенең макеты, уенчык йорт җиһазлары (өстәл, урындык, табуретка, диван, кәнәфи, сервант), машина.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, минем яныма килегез әле. Мин кичә Камилләрдә кунакта булдым. Камил әти-әниләре белән яңа фатирга күчкән, алар өй туе үткәрделәр. Фатирда Камилнең үз бүлмәсе бар. Бүлмәдә зур диван, өстәл, шкаф тора, идәндә келәм. Камилнең бүлмәсе бик матур. Йорт җиһазын – диван, өстәл, шкафны – кибеттә сатып алганнар. Балалар, йорт җиһазын кайда сатып алалар? (*Кибеттә*). Җиһазны өйгә нәрсә белән алып кайталар? (*Машина белән).*

– Балалар, Алсу курчакның да яңа бүлмәсе бар. Карагыз әле, бүлмә буш, җиһаз юк. Әйдәгез, Алсуга яңа йорт җиһазлары алабыз, бүлмәгә матур итеп яңа җиһаз куябыз. Сез ризамы? (Балаларның җаваплары). Менә бу йорт җиһазлары кибете. Әйдәгез, керик. Исәнмесез. Мин йорт җиһазлары алам. Бәясен түләдем. Машинага төягез әле. (Йөк машинасына йорт җиһазлары куялар). Рәхмәт сезгә. Сау булыгыз. (Тәрбияче руль артына бер баланы утырта, ул машина йөртә). Менә килеп тә җиттек. Балалар, без нәрсә сатып алдык? Әйе, йорт җиһазы. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Бу җиһаз кем өчен? *(Алсу өчен).* Әйдәгез, карыйк әле, Алсуга без нинди җиһаз сатып алдык? Утырыгыз.

Тәрбияче балаларны ярымтүгәрәккә утырта.

– Балалар, Алсу урамда уйный, ә без аңа алган җиһазны карарбыз һәм аның бүлмәсенә урнаштырырбыз. (Тәрбияче машинадан урындык ала). Балалар, бу нәрсә? *(Урындык).* Бу



урындыкның нәрсәсе? (Утыргычка күрсәтә). *(Утыргычы).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Утыргыч ни өчен кирәк? (*Утыру өчен).* Ә бу нәрсә? (Урындыкның аркасына күрсәтә). *(Урындыкның аркасы).* Ул ни өчен кирәк*? (Утырырга уңайлы булсын өчен).* Ә бу нәрсә? (Урындыкның аякларына күрсәтә). (*Урындыкның аяклары).* Балалар, урындыкның ничә аягы бар? *(Күп).* Балалар, урындыктан башка тагын кайда утырырга була? *(Кәнәфидә, диванда, эскәмиядә, табуреткада).* Марат, табуретка алып кил әле. Син нәрсә алып килдең? *(Табуретка).* Карагыз әле, табуретканың нәрсәләре бар? *(Утыргычы, аяклары).* Балалар, урындык белән табуретка бер-берсеннән нәрсәләре белән аерылалар? (Балаларның җаваплары). Әйе, урындыкның аркасы бар, ә табуретканың юк. Балалар, ә бу нәрсә? *(Кәнәфи).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кәнәфи белән урындык берберсеннән нәрсәләре белән аерылалар? *(Кәнәфи зур, урындык кечкенә).* Кәнәфинең кулларны кую өчен култыксасы бар. Менә алар. (Күрсәтә). (Тәрбияче кәнәфине Алсу бүлмәсенә куя).

– Балалар, утырып ашар өчен Алсуга нәрсә кирәк? *(Өстәл).* Дамир, өстәлне Алсу бүлмәсенә куй әле. (Балалар шул рәвешле өстәлне карыйлар). Балалар, Алсу савыт-сабаны кая куяр? *(Сервантка).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Сервантның киштәләре, ишекләре бар. Сервантның ишекләре пыяладан ясалган. (Тәрбияче сервантны Алсу бүлмәсенә куя).

– Балалар, бу нәрсә? *(Диван).* Диван ни өчен кирәк? Әйе, диванда утырырга була, йокларга була. Балалар, килегез, тотып карагыз әле, диван нинди? *(Йомшак, җылы, шома).* Әйе, диванны агачтан ясыйлар, аннан тукыма белән төрәләр. Бу диванның тукымасы шома, яшел төстә. (Тәрбияче диванны кәнәфи белән бергә куя). Менә, балалар, Алсуның бүлмәсе әзер. Бүлмәдә диван, кәнәфи, өстәл, урындык, табуретка, сервант бар. (Тәрбияче предметларны кулы белән күрсәтә һәм атый). Болар барысы бергә йорт җиһазлары дип атала. (Җиһазны кулы белән күрсәтә). Йорт җиһазлары агачтан ясалган, аны осталар ясаган.

Курчак Алсу керә.

**Алсу.** Бүлмәм бигрәк матур булган! Рәхмәт сезгә, балалар. Урындыкка утырыйм әле. (Тәрбияче курчакны табуреткага утырта).

**Тәрбияче.** Балалар, Алсу кая утырды? Әйе, Алсу табуреткага утырды. Әйдәгез, Алсуга аның бүлмәсендә булган җиһазларны атап чыгыйк әле. (Балалар аерым-аерым предметларны атап чыгалар). Булдырдыгыз, балалар! Менә нинди матур бүлмә! Безнең Алсу сөенә. Өстәл, урындык, диван аның бүлмәсен бизи. Балалар, ул сезне уйнарга чакыра. Уен «Алсу кайда?» дип атала. Күзләрегезне йомыгыз. Хәзер ачыгыз. Алсу кайда тора? (Урындыкта утыра, сервант янында, диван артында һ.б.). Балалар, Алсу бик тәртипле кыз, ул җиһазны саклый. Урындыкта, табуреткада тыныч утыра, тирбәлеп утырмый. Тирбәлеп утырсаң, урындыкның аяклары сынарга мөмкин. Җиһазны сакласаң, ул һәрвакыт яңа, матур, төзек булыр. Хәзер Алсу белән бергә уйнагыз.

## Тема. УЕНЧЫК ПЕСИ БАЛАСЫ ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү;

3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту, йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык ак һәм кара песи балалары, уен өчен күңелле көй аудиоязмасы.



**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез, бармаклар белән уйнап алыйк әле:

Бу бармак – бабай, бу бармак - әби, бу бармак - әти, бу бармак – әни, бу бармак – бәби. Аның исеме - чәнти. Балалар, бабай, әби, әти, әни, балаларның бергә яшәве ничек дип атала? (*Гаилә)*. Сезнең гаиләдә кемнәр яши? (Балаларның җаваплары). Хәзер мин сезгә бер шигырь укыйм:

**Безнең гаилә**

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи,
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

*Г.Тукай*

– Балалар, шигырьдә әйтелгәнчә, кайбер гаиләләрдә кешеләрнең кече дуслары да яши. Нәрсәләр икән соң ул? (Песиләр, этләр, ташбакалар, попугайлар, балыклар, әрләннәр (хомяк)). Сезнең гаиләдә хайваннардан нәрсә дә булса яшиме? Нәрсә яши? Сез аларны яратасызмы? (Балаларны активлаштыру). Бүген без сезнең белән өйдә яши торган бер кызыклы хайван турында сөйләшербез. Нәрсә икән ул? Игътибар белән тыңлагыз: «Зур мыеклы үзе, аннан курка күсе, ул бит ... (*песи*), ул бит ... (*песи*), «мияу», - ди. Дөрес, балалар, бу песи. Песигә иркәләп, назлап эндәшегез әле. (*Песием, пескәем, пескәй*). Балалар, песи нинди була? (*Йонлач, йомшак, шаян*). Песи нәрсә ярата? (*Сөт*). Песи нәрсәләр эшли белә? (*Сикерә, сөт эчә, уйный, тычкан тота).* (Активлаштыру). Булдырдыгыз, балалар! Песи турында күп нәрсәләр беләсез икән. Песинең балаларын ничек атыйлар? (Песи баласы). Песиләр үзләренең балаларын бик яраталар, алар турында кайгырталар, аларны саклыйлар. (Тәрбияче кәрзингә салынган ак һәм кара төстәге ике уенчык песи балалары күрсәтә). Балалар, песи балалары нинди икән соң, карыйк әле. (Тәрбияче ак песи баласын алып күрсәтә). Бу нәрсә? (*Песи*

*баласы*). Песи баласы нинди төстә? (*Ак*). Дөрес, песи баласы ак. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (Ак песи баласы). Балалар, песи баласының нәрсәләре бар? (Тәрбияче песи баласының башына, гәүдәсенә, тәпиләренә, койрыгына күрсәтә). Бу нәрсәсе? (*Башы*). Әйе, бу песи баласының башы. Песи баласының башында нәрсәләре бар? *(Песи баласының башында колаклары, зур күзләре, мыеклары бар).* Ә менә монысы нәрсә? (*Гәүдәсе*).

Шул рәвешле балалар песи баласының тәпиләрен, койрыгын күрсәтәләр, сурәтлиләр**.**

**Тәрбияче.** Алсу, кил әле, песи баласының тәпиләрен күрсәт. (Бала күрсәтә һәм атый). Балалар, Алсу песи баласының нәрсәләрен күрсәтте? (*Тәпиләрен*). Әмир, песи баласының койрыгын күрсәт әле. Син нәрсә күрсәттең? *(Койрык).* Балалар, песи баласының койрыгы кыскамы, озынмы? (*Озын*). Дөрес, койрыгы озын.

Шул рәвешле кара песи баласын карыйлар. Ак һәм кара песине чагыштырып, төсләре белән аерылып торуларын билгелиләр.

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер песи балалары кебек йөреп күрсәтегез әле (Балалар келәмдә йөриләр). Песи балалары мияулыйлар: мияу-мияу. (Балалар мияулыйлар). Хәзер песи балалары сөт яларга дип телләрен чыгаралар. Менә шулай. (Тәрбияче күрсәтә). Булдырдыгыз! Балалар, хәзер песи балалары белән уйнап алырсыз. (Тәрбияче, балалар тиз генә табарлык итеп, песи балаларын яшерә). Энҗе, ак песи баласын эзләп тап әле. (Энҗе ак песи баласын табып, тәрбиячегә алып килә). Энҗе, син нинди төстәге песи баласын таптың? (*Ак песи баласын*). Аның нәрсәләре бар? Песи баласының башын, гәүдәсен, тәпиләрен, койрыгын күрсәт. (Бала күрсәтә һәм атый). Илмир, син кара песи баласын табып алып кил әле. Син нинди песи



баласын табып алып килдең? *(Кара).* Аның нәрсәләре бар? (Бала песи баласының башын, гәүдәсен, тәпиләрен, койрыгын күрсәтә һәм атый).

Әңгәмә ахырында тәрбияче балаларның җавапларын гомумиләштереп, бәйләнешле хикәя төзи.

**Тәрбияче.** Илмир кара песи баласын тапты. Песи баласының башы, башында колаклары, зур күзләре, мыеклары бар. Песи баласының гәүдәсе матур, тәпиләре йомшак, койрыгы озын. Ул сөт эчә һәм мияу-мияу дип мияулый. Балалар, песи балалары сезгә ошадымы? Песиләр ни өчен кирәк дип уйлыйсыз? *(Алар тычкан тоталар).* Дөрес, балалар, песиләр, бигрәк тә авылда, тычкан тотып, кешеләргә файда китерәләр. Алар тычкан гына тотып калмыйлар, кешеләрне дәвалыйлар, циркларда катнашып, кешеләрнең күңелен күтәрәләр, көлдерәләр. Песиләр өйдә яшиләр, шуңа күрә аларны нинди хайваннар рәтенә кертәләр? *(Йорт хайваннары).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Песиләрне рәнҗетергә, аларга сугарга ярамый. Булдырдыгыз, балалар! Бик яхшы. Әйдәгез, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыгыз әле. Башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып: «Без бик әйбәт, тәрбияле балалар! Хайваннарны рәнҗетмибез!» – дип әйтегез.

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ
### Тема. ТӨЛКЕ БЕЗДӘ КУНАКТА

**Бурычлар:**

1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (*эчендә, артында, астында, өстә, өстендә*) кулланырга, «кайда?», «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән irekле аралашырга өйрәтүне дәвам итү;

2) игътибарны, тәрбияченең күрсәтмәләре буенча эшләү

күнекмәләрен үстерү;

3) җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** балалар саны буенча тылсымлы тартмага салынган кечкенә уенчык төлкеләр, бизәп куелган чыршы, уенчык бүре, татар көенең аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Уен бүлмәсендә бизәлгән чыршы тора.
Тәрбияче балаларны чыршы янына чакыра.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, нинди матур чыршы! Әйдәгез, бергәләп: «Ай-ай матур чыршы!» – дип сокланыйк. (Активлаштыру). Килегез монда, чыршы янына басыгыз! Йәгез әле, чыршыны мактыйк: *яшел, бик матур, биек, купшы, төз, хуш исле, ямьле, энәле, йомшак, матуркай һ.б.* Булдырдыгыз, балалар! Сез чыршыны матур сүзләр әйтеп куандырдыгыз. Карагыз әле, чыршы төбендә нәрсәдер бар. Нәрсә икән бу? *(Тартма).* (Активлаштыру*).* Әйе, балалар, тылсымлы тартма. Тартма кайда ята? *(Чыршы төбендә).* Тартма матурмы? *(Матур).* Аның эчендә нәрсәдер бар. *(Селкетә).* Ишетәсезме, тавыш ишетелә. Балалар, тартманы ачмыйча гына эчендә нәрсә барлыгын әйтеп буламы ? *(Юк).* Әгәр дә мин тартма эчендәге әйбер турында:«Озын койрыклы, хәйләкәр», – дисәм, әйтә аласызмы? Нәрсә ул: үзе озын койрыклы, хәйләкәр? (*Төлке*). Дөрес, төлке. Балалар, төлкеләр кайда? *(Тартма эчендә). (Активлаштыру).* Хәзер тартманы ачабыз. *(Тәрбияче тартманы ача һәм балаларга күрсәтә).* Монда төлкеләр азмы, әллә күпме? (*Күп*) (Активлаштыру*).* Гөлшат, кил әле, син бер төлкене үзеңә кунакка чакыр! Гөлшат, син нәрсәне кунакка чакырдың? *(Төлкене).* Хәзер Марат (Алсу, Дилә, Әмир һ.б.) бер төлкене үзенә кунакка чакырсын.

– Дилә, ал төлкене. Син нәрсә алдың? (*Төлке)*. Балалар, барыгыз да берәр төлке алыгыз.



– Төлке бүредән курка. (Бүрене күрсәтә). Төлке нәрсәдән курка? *(Бүредән*). (Активлаштыру: Алсу әйтә, Марат әйтә һ.б.). Төлке бүредән курка, шуңа күрә ул кача. (Тәрбияче төлкене артына яшерә). Балалар, сез дә төлкене артка яшерегез. Төлке качты. Хәзер төлкене өскә күтәрегез, минем кебек. Менә шулай. *(Күрсәтә).* Алсу, син төлкене кая яшердең? *(Өскә).* (Активлаштыру). Төлке кайда? *(Өстә).* Төлкене өстәл өстенә куегыз! Төлке кайда*? (Өстәл өстендә)*. Әйдәгез, тыныч кына кабатлагыз! (*Өстәл өстендә*). Бүре ишетә күрмәсен! Бүре килә. (Бүрене күрсәтә)*.* Әйдәгез, төлкене тагын артка качырыгыз. Менә шулай, булдырдыгыз. Хәзер төлке кайда? *(Артта).* Хәзер төлкене тартма эченә яшерегез. Сез төлкене кая яшердегез? *(Тартма эченә).* Төлке чыршы артына качты. Төлке, син кайда? Балалар, төлке кайда? *(Чыршы артында).* Ә хәзер төлке чыршы артыннан чыкты. Рамил, төлке кая качты? (*Чыршы астына*). Әйдәгез, тыныч кына кабатлагыз, бүре ишетә күрмәсен. (Балалар кабатлыйлар: *Төлке чыршы астына качты*). Булдырдыгыз, балалар! Балалар, ә хәзер бер уен уйнарбыз. Сез барыгыз да төлкеләр булырсыз, ә без бүре белән сезне күзәтербез. Кайсыгыз төлкене остарак күрсәтер икән.

Тәрбияче берәр татар көенең аудиоязмасын куя, кулына бүре уенчыгын ала һәм балаларны күзәтә. Балалар төлке булып, «койрыкларын» боргалап йөриләр. Тәрбияче дөрес хәрәкәтләр ясаган балаларны билгели.

**Тәрбияче.** Балалар, булдырдыгыз! Сез бик матур, купшы төлкеләр булдыгыз! Мондый матур «төлкеләрне» чыршы бәйрәменә бик теләп чакырабыз. Кул чабыйк!

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ
### Тема. АЛСУНЫ УРАМГА КИЕНДЕРӘБЕЗ.
### (Кышкы киемнәрне карау)

**Бурычлар:**

1) кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, детальләрен, материалын аерып алып, аны карарга өйрәтү, исемне сыйфат белән туры китереп, сорауларга җавап бирүне дәвам итү;

2) *тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел (зәңгәр)* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүне, игътибарны, күрү хәтерен үстерү;

3) киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрзин, тукыма, мех кисәкләре. Кышкы киемнән (куртка, башлык, итекләр, бияләйләрдән) курчак Алсу. Төзү материалы.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, курчак Алсу бүген бездә кунакта. Исәнләшегез әле аның белән. Исәнме, Алсу! (*Исәнмесез, балалар!)* Балалар, Алсуның кулында нәрсә бар? *(Кәрзин).* Нәрсә бар икән кәрзиндә? Карамыйча әйтеп буламы? *(Юк).* Әйдәгез, карыйк әле, кәрзин эчендә нәрсә бар икән? (Тәрбияче балалар янына килә, кәрзиндәге тукымаларны күрсәтә). Бу нәрсә? *(Тукыма. Чүпрәк).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). (Тәрбияче тукыманы балаларга тарата). Балалар, тотып карагыз әле, тукыма нинди? *(Йомшак, җылы, кызыл, сары, яшел, шома һ.б.)*. Тукыма ни өчен кирәк? *(Кием тегәргә).* (Тәрбияче балаларга йон кисәкләре тарата). Бу нәрсә? *(Йон).* (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар). Балалар, тотып карагыз әле, йон нинди? *(Йомшак, җылы, йонлы, ак, кара һ.б.).* Йон ни өчен кирәк? *(Йоннан бүрек, тун тегәләр. Ул җилдән, салкыннан саклый).*

– Балалар, курчак Алсу урамга чыгам, ди. Әйдәгез, аны



киендерәбез. Карагыз әле, бу Алсуның киемнәре. Иң элек Алсуга нинди кием киертик? *(Итекләр).* Итекләр нинди? *(Җылы, йомшак, салкын үткәрми).* Кәмилә, курчакка итекләрен киерт! (Кәмилә курчакка итекләр киертә). Син нәрсә эшлисең? (Җаваплар). Балалар, Кәмилә нәрсә эшли? Менә Алсуга итекләр киерттек. Хәзер нәрсә киертәбез? Дөрес, хәзер Алсуга куртка киертәбез. Самира, кил, Алсуга курткасын киерт. Син нәрсә эшлисең? (Җаваплар). Балалар, Самира нәрсә эшли? Куртка нинди? (Җаваплар). Менә Алсуга куртка киерттек. Хәзер нәрсә киертәбез? Дөрес, хәзер Алсуга башлык киертәбез. Самат, кил, Алсуга башлык киерт. Син нәрсә эшлисең? (Җаваплар). Балалар, Самат нәрсә эшли? Башлык нинди? (Җаваплар). Менә Алсуга башлык та киерттек. Нәрсә киертәсе калды? (Бияләйләр). (Балалар шул рәвешле бияләйләр дә киертәләр). Алсу киенеп бетте. Ул сезне дә урамга чакыра. Алсу урамда уйный торсын, без аңа йорт төзик. Урыннарыгызга утырыгыз.

Өстәлләрдә төзү материаллары. Балалар йорт төзиләр. Төзү материалларының исемен, төсен, формасын, билгеләнешләрен атыйлар.

### Тема. КАР ЯВА

**Бурычлар:**

1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү;

2) балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, сөйләм сулышын; рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын үстерү;

3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** һәр балага җитәрлек мамык кисәкләре, зәңгәр төстәге кәгазь битләре, ак гуашь, уенчык куян, кыш темасына аудиоязма.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер мин сезгә бер шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз! Нәрсә турында икән ул шигырь?

Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна;
Үзләре матур
Һәм салкын була.
*Ә. Бикчәнтәева*

– Балалар, шигырьдә нәрсә урында сүз бара? (*Кыш турында. Кар турында.*) Дөрес, кыш, кар, кар бөртекләре, саф һава турында сүз бара. Урамда елның кайсы вакыты? (*Кыш*). Ни өчен кыш дип уйлыйсыз? (*Кар ява*). Тагын ни өчен кыш дип уйлыйсыз? (*Салкын*). Ә тагын? (*Кешеләр җылы киенеп йөриләр*). (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар). Балалар, әйдәгез, кар турында сөйләшеп алыйк. Кар нинди төстә? (*Кар ак*). (Күмәк җаваплар). Кар каян ява? (*Һавадан, күктән*). Күккә карагыз! Күк кайда? (*Өстә, биектә, югарыда*). Кар күктән кая төшә? (*Җиргә*). (Күмәк җаваплар). Хәзер җиргә карагыз! Җир кайда? (*Аста, түбәндә*). Балалар, хәтерегездәме, без сезнең белән урамда кар яуганын күзәткән идек? Кар яуганда кар бөртекләре очалар, бөтереләләр. Әйдәгез әле, кар бөртекләре кебек очып, бөтерелеп алыйк.

Тәрбияче аудиоязма куя. Балалар кар бөртекләре булып бииләр.

– Булдырдыгыз, балалар! Бик яхшы. Чын кар бөртекләре шикелле җиңел очасыз, бөтереләсез. Исегездәме, кар бөртекләре безнең бияләйләргә очып кундылар. Без аларга өргән идек. Тагын шуны кабатлыйк әле, кар бөртекләренә өреп карыйк.

Тәрбияче балаларга мамык бирә. Балалар мамыкны өреп очырталар. Уен 2-3 тапкыр кабатлана.

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәге, тирән итеп сулыш алыгыз да, мамыкны очыртып карагыз. Никадәр ераграк очса, шулкадәр яхшырак. Бик яхшы. Күрәсезме, Азатның, Мәдинәнең, Сөмбелнең, Әмирнең кар бөртекләре бик ерак очтылар. Булдырдыгыз, балалар!

Ишек шакыган тавыш ишетелә.

**Тәрбияче.** Балалар, тыңлагыз әле, ишек шакыйлар бугай. Карыйм әле, әллә кунак бармы икән.

Елый-елый куян килеп керә.

– Балалар, бу нәрсә? (*Куян*). Куян белән исәнләшегез! *(Исәнме, куян!).* Куян, нигә елыйсың? (Тәрбияче куянны тыңлый). Балалар, куянга балалары – кечкенә куяннары янына кайтырга кирәк. Әле кар аз яуган, шуңа күрә ул куяннары янына кайтырга курка, төлке күрер дә, эләктереп алыр, дип уйлый. Балалар, әйдәгез, куянны юатыйк: «Елама куян, без сиңа ярдәм итәбез.» Менә куян елаудан туктады да. Башта куян турында матур сүзләр әйтеп, аны мактагыз. (*Куянкай, йомшаккай, куркаккай, җитез, тиз чаба, сикерә, кишер, кәбестә ярата, колаклары озын, койрыгы кыска һ.б.*). Булдырдыгыз, балалар! Хәзер инде куян төлкедән курыкмасын өчен, без аңа булышыйк, күп итеп ак кар ясыйк.

Балалар зәңгәр кәгазь битенә ак буяу белән кар ясыйлар. Карны өстән аска төртү юлы белән ясыйлар.

**Тәрбияче.** Балалар, күрәсезме, күпме кар яудырдыгыз. Кыш

көне кар күп булырга тиеш. Хәзер куян да төлкедән курыкмас, балалары янына тиз кайтып җитәр. Кар турында сөйлик әле. Нинди ул кар? (*Ак, салкын, мамыктай йомшак, ялтырап тора, шыгырдый*). (Күмәк җаваплар). Булдырдыгыз, балалар! Куян сезгә рәхмәт әйтә. Ул инде балалары янына китә. Куян белән саубуллашыйк! (*Сау бул, куян!*). Балалар, мин дә сезгә күңелле көн телим! Әйдәгез, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыйк, бер-беребезгә кулларыбызның җылысын бүләк итик!

## *Җиденче бүлек.* ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ
### Тема. ОЧУЧЫЛАР

**Бурычлар:**

1) балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, формасын билгеләргә һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүгә күнектерүне дәвам итү; *очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү, игътибарларын үстерү;

3) очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** хәрбиләрнең баш киемнәре, уенчык самолетлар.

**Эшчәнлек барышы.**

Тәрбияче төркемгә алдан ук хәрбиләрнең төрле баш киемнәрен кертеп куя.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, өстәлдә сез нәрсәләр күрәсез? (*Фуражкалар*). Мондый фуражкаларны кемнәр кия? (*Солдатлар, хәрбиләр*). Дөрес, балалар, аларны армиядә хезмәт итүчеләр, солдатлар, офицерлар кия. (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Тиздән әтиләр, бабайлар – ягъни ир-атлар бәйрәме. Алар армиядә хезмәт иткәннәр. 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, менә бу очучылар кия торган фуражка. (Күрсәтә). Очучылар нәрсәдә очалар? *(Самолетта, вертолетта.)* Дөрес, балалар. Монда карагыз әле, бу нәрсә? *(Самолет).* Балалар, әйдәгез, самолетның нәрсәләре бар икән, карыйк әле. Самолет кечкенәме, зурмы*? (Зур).* Балалар, менә бу - самолетның кабинасы, анда очучы утыра. Самолетның тагын, кошларныкы кебек, канатлары бар. Ә монысы - самолетның койрыгы. Ринат, бу нәрсә? *(Кабина).* Самолетның канатларын күрсәт әле. Ә бу нәрсә*? (Койрыгы).* Самолетны кем йөртә*? (Очучы*). Булдырдың, Ринат! Балалар, самолет «у-у-у» дип оча. (Самолетны «очырытып» күрсәтә). Илһам, самолет, очканда, нинди тавыш чыгара? *(У-у-у).* (Активлаштыру). Балалар, менә самолет очып китте. Самолет нәрсә эшләде? *(Очып китте).* Балалар, самолет аска таба очамы, әллә өскәме? (*Өскә*). Менә самолет борылып китте. Ул кая борылды: сулгамы, әллә уңгамы? (*Уңга*). Ә хәзер кайсы якка борылды? (*Сулга*). Самолет кая таба оча? (*Аска таба).* Ә хәзер, балалар, самолет яңадан очып килде. Самолет нәрсә эшләде? *(Очып килде).* Балалар, сез дә, бәлки, зур үскәч, очучылар булырсыз. Малайлар армиядә хезмәт итәрләр. Ватанны сакларлар.

– Балалар, әйдәгез, самолетлар булып уйнап алыйк. Сез барыгыз да самолетлар булырсыз. Кулларны ян-якка канатлар кебек җәябез һәм самолет тавышы чыгарып (у-у-у) «очып китәбез» һәм «очып киләбез». (Уен берничә тапкыр кабатлана).

## *Сигезенче бүлек.* СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ

### Тема. КОЯШ ГОМЕРЕ ТЕЛИМ МИН, ӘНИЕМ, СИҢА!

**Бурычлар:**

1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә катнашуга тарту;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү;

3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** әниләренең фотолары; «Кояш гомере» (Г.Зәйнашева сүзләре, Ф.Әхмәдиев көе), «Әниләр бәйрәме» (Гариф Гомәр сүзләре, М.Бикбова көе) җырларының аудиоязмалары.

**Эшчәнлек барышы.**

Аудиоязмада «Әниләр бәйрәме» (Гариф Гомәр сүз., М.Бикбова көе) җыры яңгырый.

**Тәрбияче.** Балалар, әйтегез әле, нинди бәйрәм якынлаша? (*Әниләр бәйрәме*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Дөрес, балалар, әниләр бәйрәме – 8 нче Март якынлаша. 8 нче Март – иң ягымлы, иң гүзәл, иң матур бәйрәм, чөнки ул - әниләр бәйрәме. 8нче Март бәйрәме нинди бәйрәм ул? Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: 8нче Март – иң ягымлы, иң гүзәл, иң матур бәйрәм. Ни өчен шулай әйтәләр икән соң? *(Әниләр бәйрәме булганга).* Безнең әниләребез - ягымлы, гүзәл, иң матур кешеләр. Шуңа күрә 8нче Март бәйрәме иң җылы, иң гүзәл, иң матур бәйрәм. Балалар, әниләр бәйрәмен елның кайсы вакытында билгеләп үтәләр? *(Яз көне).* Дөрес, балалар, әниләр бәйрәмен яз көне бәйрәм итәләр. Яз билгеләрен әйтегез әле. (*Көннәр җылына, кар эри, түбәдән тамчы тама*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). 8нче Март әниләр бәйрәме генәме соң? Тагын кемнәр бәйрәме ул? (*Әбиләр, апалар, кызлар бәйрәме*). Дөрес, балалар, 8нче Март - әниләр, әбиләр, апалар, кызлар бәйрәме. Икенче төрле аны хатын-кызлар бәйрәме диләр. Нинди бәйрәм диләр? *(Хатын-кызлар бәйрәме).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: хатын-кызлар бәйрәме. Булдырдыгыз!

- Балалар, әниләрегез эшкә йөриләр, анда бик тырышып эшлиләр. Аннан кайткач та әниләрнең өйдә эшләре күп. Алар ниләр эшлиләр? (*Ашарга әзерлиләр. Кер юалар. Савыт-саба юалар.*) (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, сез әниләрегезгә булышасызмы? Нәрсәләр эшлисез? *(Өстәл әзерләргә булышам. Уенчыкларны җыеп куям.)*. Бик яхшы, балалар! Әйе, сез инде чәй өстәле әзерли беләсез, шуңа күрә өстәл әзерләгәндә кирәкле савыт-сабаны өстәлгә куярга, ашагач, җыеп куярга ярдәм итә аласыз. Әниләрегезгә булышыгыз. Аларның да арыган, авырган вакытлары була. Әйдәгез, әниләргә кер юганда булышырга өйрәник. Хәзер кер юабыз.

Ял минуты үткәрелә.Тәрбияче.

| | |
|---|---|
| Әнигә булышам | *кер юу хәрәкәте ясыйлар* |
| Керләрне юышам. | |
| Югачтын әйбәтләп | |
| Чайкатып аламын | *кер чайкау хәрәкәте ясыйлар* |
| Чайкагач, көч белән | |
| Ныгытып сыгамын | *керне сыгу хәрәкәте ясыйлар* |
| Һәм бауга эләмен. | *керне элеп кую хәрәкәте ясыйлар* |
| Кипкәчтен, шәп итеп | |
| Үтүкләп куямын. | *уң кулга үтүк «тотып», үтүкләү хәрәкәте ясыйлар* |

Булдырдыгыз! Менә кер дә юып карадыгыз. Бик тырыштыгыз.

«Кояш гомере» җырының аудиоязмасы куела.

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез, матур итеп түгәрәккә басыгыз. Бергәләп, башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннары кычкырып: «Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!» – дип әйтәбез. Булдырдыгыз, балалар!

## *Тугызынчы бүлек.* ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Тема. «ТЕРЕМКӘЙ» РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;

2) *Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак, аю-Камытаяк* сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү;

3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф (коврограф), «Теремкәй» әкиятенең персонажлары, битлекләр, кыршаулар, төзү материалы.

### Эшчәнлек барышы

Балалар ярымтүгәрәк булып утыралар. Алар алдында фланелеграф (коврограф).

**Тәрбияче.** Балалар, фланелеграфка карагыз әле. Бу нәрсә? (Тәрбияче эзлекле рәвештә әкияттә булган җәнлекләрнең сурәтен күрсәтә: тычкан, бака, куян, төлке, бүре, аю). Бу җәнлекләр бер өйдә яшәгәннәр. Алар нинди әкияттән? *(«Теремкәй» әкиятеннән).* Мин сезгә «Теремкәй» әкиятен сөйлим, игътибар белән тыңлагыз.

Тәрбияче әкиятне сөйли, фланелеграфта сюжетның эзлеклелеген күрсәтә бара.



– Хәзер без уйнап алырбыз. Сез әкияттәге җәнлекләр булырсыз (Тәрбияче балаларга тычкан, бака, куян, төлке, бүре, аю битлекләре кидерә, идәнгә кыршауларны таратып сала). Бу өйдә тычканнар (бакалар, куяннар, төлкеләр, бүреләр, аюлар) яши. (Тәрбияче балаларны кыршауларга кертеп урнаштыра). Терем-теремкәй, теремкәйдә кем яши? (Тәрбияче һәр кыршау янына килеп, балаларга сорау бирә, һәр баланың җавабын тыңлый: *тычкан-Чыелдык, бака–Бакылдык һ.б.*). Булдырдыгыз, балалар. Хәзер әкияттәге җәнлекләр өчен без өй төзербез. Урыннарыгызга утырыгыз.

Балаларның өстәлләрендә төзү материаллары һәм әкият персонажлары. Тәрбияченең күрсәткән үрнәге буенча балалар җәнлекләргә өй төзиләр һәм әкият геройлары белән уйныйлар.

## *Унынчы бүлек.* ЯЗ

### Тема. БОЗАУ, КОЛЫН, БӘРӘН ТУРЫНДА СӨЙЛИБЕЗ

**Бурычлар:**

1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне (*зур – кечкенә, калын – нечкә*) таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның авазияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту;

2) балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү;

3) балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сарай-ширма**,** уенчыклар: ат – колын, сыер – бозау, сарык – бәрән; чирәмлек рәсеме; су салынган тәлинкәләр (балалар санынча).

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, урамда нинди ел фасылы? *(Яз)*. Яз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр күзәтелә? (*Кояш нык яктырта, яшел чирәм күренә, күбәләкләр, май коңгызлары оча)*. (Активлаштыру. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

- Бергәләп кабатлыйк әле: кояш нык яктырта, яшел чирәм күренә, күбәләкләр, май коңгызлары оча. Кошлар да, хайваннар да яз килүенә шатланалар. Ат, сыер, сарык үзләренең балаларын яшел чирәм белән сыйларга дип, чирәмлеккә килгәннәр. Менә алар рәхәтләнеп чирәм ашыйлар. (Тәрбияче чирәмлектә йөрүче уенчык ат-колын, сыер-бозау, сарык-бәрәннәрне күрсәтә). Балалар, бу нәрсә? (Тәрбияче атка күрсәтә). (*Ат*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар. Тәрбияче ат кешнәгән тавыш чыгара: их-ха-ха!).

Балалар, ат үзенең баласын чакыра. Ат нишли?

(*Баласын чакыра)*. Ат баласын ничек чакыра? (*Их-ха-ха!)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Атның баласы *колын* дип атала. Бергәләп кабатлыйк: *колын*. Балалар, әни-ат зур, ә баласы – колын нинди? (*Кечкенә)*. Балалар, колын нечкә итеп тавыш чыгара. Колын нинди тавыш белән кычкыра? (*Нечкә)*. Атның, колынның кычкыруын башка төрле итеп *кешни* дип әйтәләр. Бергәләп кабатлыйк әле: колын кешни. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Колын ничек кешни?(Кабатлыйлар).

«Му-у-у» – дигән тавыш ишетелә.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? (*Сыер)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Сыер ничек мөгри? (*Му-у-у)*. Балалар, сыер шулай үзенең баласын чакыра. Сыерның баласы ничек атала? (*Бозау)* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). (Тәрбияче уенчык бозау күрсәтә). Сыер зур, ә бозау нинди?(*Кечкенә)*. Дөрес, сыерның бозавы кечкенә, ул нечкә тавыш белән кычкыра. Бозау нинди тавыш белән кычкыра? (*Нечкә)*.



Бозау ничек кычкыра, күрсәтегез әле. *(Му-у-у)*

«Мә-мә-мә, бә-бә-бә» – дигән нечкә тавыш ишетелә.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә тавышы икән? Аның әнисе нәрсә була? (*Сарык)*. (Тәрбияче уенчык сарык күрсәтә). (*Бу – сарык. Ул – әни)*. Сарыкның баласы ничек атала икән? Бу нәрсә? (Уенчык бәрән күрсәтә). (*Бәрән*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

Дөрес, бәрән. Сарык зур. Ул ничек мәэлди? (Тәрбияче түбән (калын) тавыш белән: «мә-мә-мә, бә-бә-бә»- ди). Ә сарыкның баласы, бәрән, нечкә тавыш белән кычкыра. Бәрән ничек кычкыра? (*Мә-мә-мә, бә-бә-бә)*. Бәрән зурмы, кечкенәме? (*Кечкенә)*. Ул нинди тавыш белән кычкыра? (*Нечкә*). Дөрес, бәрән нечкә тавыш белән кычкыра.

– Хәзер уйнап алабыз. Балалар, каяндыр болыт килеп чыкты. (Тәрбияче балаларны келәмгә утырта). Яңгыр тама башлады. (Балалар бармаклары белән идәнгә кагалар). Яшен яшнәде. (Кул чабалар). Күк күкрәде. (Кулларының йодрыкларын бер-берсенә бәреп алалар). Ат, колын, сыер, бозау, сарык, бәрән сарайга кереп качтылар.

Балалар урындыкларга утыралар. Уен 2-3 тапкыр кабатлана.
Өстәлгә сарай-ширма куелган, анда хайваннар яшеренгән.

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер без сезнең белән тагын бер уен уйнарбыз. Бу сарайга яңгыр яуганда хайваннар кереп качкан. Мин сезгә аларны күрсәтермен, ә сез аның нинди хайван икәнен атарсыз. (Тәрбияче барлык хайванны да күрсәтеп чыга). Менә алар тагын качтылар һәм кычкыралар. Ә сез тавышы буенча нинди хайван икәнен әйтерсез. Хайваннарның әниләре зур, алар калын (түбән) тавыш белән кычкыралар, ә балалары кечкенә, алар нечкә (югары) тавыш белән кычкыралар.

Тәрбияче аваз ияртемнәрен калын яки нечкә тавыш белән әйтә.

**Тәрбияче.** «Мияу». Нәрсә икән бу, шундый нечкә тавыш белән нәрсә кычкыра?

(*Песи баласы)*. Дөрес, бу песи баласы, песинең улы шулай мияулый. Ә хәзер нәрсә кычкыра: их-ха-ха? (*Бу – колын)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әйе, колын, атның яраткан баласы. Му-у-у! Кем шундый калын тавыш белән кычкыра? Бу нәрсә икән? *(Сыер)***.** Дөрес, сыер. Балалар, сыерның баласы ничек атала? (*Бозау)*. Ишетәсезме, бозау кычкыра: му-у-у! Әйдәгез, сез дә бозауның ничек кычкырганын күрсәтегез инде. (Кабатлыйлар)

Тәрбияче хайваннарның балаларын тезеп куя.

**Тәрбияче.** Балалар, менә бу ат баласы. Ул ничек атала? (*Колын)*. Ничә колын бар?

(*Бер)*. Бу нәрсә? (*Бозау)*. Ничә бозау? (*Бер)*. Бозауның әнисен ничек дип атыйлар? (*Сыер)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Алсу, сарык баласын күрсәт әле. Балалар, Алсу нәрсәне күрсәтте? (*Бәрәнне*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Ничә бәрән бар? (*Бер)*. Балалар, бәрән нинди? Ул...(*кечкенә, йомшак, ак, йонлач*). Аның йоны...(*бөдрә)*. Бәрән яшел чирәм... (*ярата)*. Ул сикергәләп...(*уйный*). Балалар, колын нинди? Ул... (*кечкенә, матур*). Аның ялы,...(*койрыгы бар*). Колынның аяклары...(*нечкә*). Аякларында...(*тояклары*) бар. Колын оста... (*чаба*). Сыер баласы ничек атала? (*Бозау*). Бозау нинди? Бозау... (*кечкенә, матур*). Аның әле...(*мөгезләре юк*). Бозауның...(*койрыгы, тояклары бар*). Ул...(*үлән ашый, «му-у-у»-дип кычкыра*).

– Балалар, кем бәрән (бозау, колын) турында сөйләргә тели? (Тәрбияче теләгән балалардан сөйләтә). Атны, сыерны, сарыкны һәм аларның балаларын бер сүз белән *йорт хайваннары* диләр. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, бозау да,



колын да, бәрән дә су эчәргә телиләр. Әйдәгез, аларга су эчерик. (Тәрбияче балалар санынча уенчыклар өләшә). Хәзер һәрберегез берәр хайван баласын алып, сулы тәлинкә янына куегыз.

Алдан аерым өстәлгә балалар санынча
су салынган тәлинкәләр куелган була.

Тәрбияче. Балалар, яшел үлән ашагач, аларның су эчәсе килгән. Бозаулар да, колыннар да, бәрәннәр дә су эчсеннәр. Әйдәгез, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыгыз әле. Башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан соң кычкырып: «Без акыллы балалар! » – дип әйтегез. Булдырдыгыз, балалар! Хайваннарны рәнҗетмәгез! Аларны яратыгыз!

## *Унберенче бүлек.* ҖӘЙ
### Тема. АВТОБУСТА СӘЯХӘТ

**Бурычлар:**

1) балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү; йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту; йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;

2) кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;

3) тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уен бүлмәсендә чәчәкләр, агачлар, ә агачта чыпчыклар; агач төбендә карга йөри торган аланлык, авылда ишек алды сурәтләнгән күренеш. Ишек алдында эт, песи, сыер.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, без сезнең белән сәяхәткә барабыз. Менә, сезне алырга автобус та килеп җиткән.

Автобусны тәрбияче алдан әзерләп куя, сюжетлы-рольле уен өчен ясалган атрибутны алырга була.

– Балалар, менә барыгыз да автобуска кереп утырдыгыз. Хәзер китәбез. (Музыка уйный). Барыгыз да җайлап утырыгыз. Автобус кузгала. Балалар, менә без сезнең белән аланлыкка килеп җиттек. Балалар, аланлыкта нәрсәләр үсә? (*Чәчәкләр*). Монда чәчәкләр азмы, әллә күпме? (*Күп*). Чәчәкләрнең хуш исен иснәп карагыз әле. (Балалар белән сулыш гимнастикасы үткәрелә). Борын белән тирән итеп сулыш алыгыз һәм сулышны тыныч кына чыгарыгыз. Сулыш чыгарганда «Ә-әх!» – дип әйтегез. Әйе, чәчәкләр чынлап та бик хуш исле. (Гимнастика өч тапкыр кабатлана).

– Балалар, ә бу нәрсә? (Агачка күрсәтә). Агачта нәрсәләр утыра? (*Чыпчыклар*). Чыпчыклар кайда утыралар? (*Агачта. Агач ботагында*). Чыпчыклар ничек кычкыралар? (*Чырык-чырык*). Бергәләп кабатлагыз: чырык-чырык. Әйе, чыпчыклар чырык-чырык киләләр, чыркылдыйлар. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: чырык-чырык киләләр, чыркылдыйлар. Бик яхшы. Булдырдыгыз, балалар! Ә бу нәрсә? *(Карга).* Карга кайда йөри? (*Җирдә. Агач төбендә*). Балалар, карга кычкырганда нинди тавыш чыгара? (*Кар-кар*). Әйе, балалар, карга «кар-кар» дип кычкыра, каркылдый. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: кар-кар, каркылдый. Балалар, карга да, чыпчыклар да канатларын җилпеп очып киттеләр. Әйдәгез, сез дә чыпчыклар һәм карга кебек очып алыгыз әле. (Балалар куллары белән очу хәрәкәтләре ясыйлар). Булдырдыгыз, балалар! Балалар, барыгыз да автобуска утырыгыз.

– Менә без авылга килеп җиттек. Авылда, ишек алдында йорт хайваннары яши. Мин хәзер сезгә шулар турында табышмаклар



әйтәм. Игътибар белән тыңлагыз:

– Койрыгы озын, башында колаклары, зур күзләре, мыеклары бар, ул тычкан тота. Ул нәрсә? (*Песи*). Песи ничек кычкыра? (*Мияу, мияу*). Әйе, песи «мияу» ди, мияулый. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. Булдырдыгыз, балалар! Әйдәгез, песигә яратып, иркәләп эндәшик: песием, пескәем. Балалар, песи нәрсәләр эшли? (*Тычкан тота, сөт эчә, мияулый, тырный, уйный*).

– Әбинең ишек алдында йорт саклый торган хайван бар. Ул нәрсә? (*Эт*). Чит кешеләрне күрсә, эт нишли? (*Өрә*). Ул нәрсә дип өрә? (*Һау-һау*). Эт нәрсә эшли белә? (*Эт өрә, өй саклый, сөяк кимерә, улый, ырылдый, йөгерә, койрыгын селкетә*). Балалар, этне тагын башка төрле сүз белән ничек атыйлар? (*Маэмай*).

– Әбинең ишек алдында мөгезле зур хайван да бар. Ул нәрсә икән? (*Сыер*).

– Сыер ничек мөгери? (*Му-уу*). Җәй көне сыерны иртән көтүгә куалар, ул кич белән генә кайта. Сыер нәрсә бирә? (*Сөт*). Песи, эт, сыер бер сүз белән ничек атала? (*Йорт хайваннары*). (Активлаштыру).

– Балалар, каяндыр болыт килеп чыкты. (Тәрбияче балаларны келәмгә утырта). Яңгыр тама башлады. (Балалар бармаклары белән идәнгә кагалар). Яшен яшьнәде. (Кул чабалар). Күк күкрәде. (Кулларының йодрыкларын бер-берсенә бәреп алалар). Менә яңгыр әкренәйде һәм бөтенләй туктады.

– Хәзер автобуска утырып, бакчага «кайтып китәбез». Сәяхәт шуның белән тәмам. Балалар, сез бүген бик күп матур сүзләр кабатладыгыз. Исән-сау булыгыз! (Кул чабалар).

## Тема. МИН ҖӘЙНЕ ЯРАТАМ

**Бурычлар:**

1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне

сөйләмдә кулланууларын активлаштыру; «бер», «күп» төшенчәләрен ныгыту; [з] авазын дөрес әйтергә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, уңай хис-кичерешләрен үстерү;

3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** күбәләк, бал корты, чебен, черки рәсеме; урман, елга буе, яшелчә бакчасы сурәтләнгән рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы.**

– Балалар, хәзер мин сезгә бер шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз, нәрсә турында икән ул шигырь:

Киң болында һәр җәй саен
Чәчәкләр була.
Ал, сары, ак чәчәкләргә
Бал корты куна.

– Дөрес, балалар, шигырь җәй турында. Җәй җиткәч, табигатьтә күп кенә үзгәрешләр була: кояш кыздыра, бар җир яшәрә, күбәләкләр чыга... Бергәләп кабатлагыз әле! (*Кояш кыздыра, үләннәр яшәрә,..)*.

Тәрбияче бөҗәкләрнең рәсемен күрсәтә.

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез, бергәләп бөҗәкләрнең исемнәрен кабатлагыз: күбәләк, бал корты, черки, чебен. (Күмәк кабатлаулар). Күбәләк, бал корты, черки, чебенне бер сүз белән ничек әйтергә була? (*Бөҗәкләр*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, бөҗәкләр – бал кортлары, чебеннәр, черкиләр-безелдиләр. Бөҗәкләр нишлиләр? (*Безелдиләр*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Бөҗәкләр ничек безелдиләр? (*Без-з-з*). Бергәләп кабатлыйбыз: без-з-з. (Кабатлаулар).

– Әйдәгез, «Аю һәм бал кортлары» уенын уйнап алабыз. Балалар, сез бал кортлары булырсыз. Урындыкларга утырыгыз әле! Менә һәр бал корты үз оясында. (Тәрбияче балаларга бал корты битлекләре кидерә). Ләйсән – бал корты. Зилә - бал корты. Әминә - бал корты. Марат - бал корты. Әмир - бал корты. Кәрим - бал корты. Камил - бал корты. Балалар, ничә бал корты бар? (*Бал кортлары күп*) Ә Алмаз аю булыр. Ничә аю бар? (*Бер аю*). Балалар, бал кортлары аланлыкта очып йөриләр. Аю килә, өйләрегезгә качыгыз! (Урындыкларга утыралар). Бик яхшы. Булдырдыгыз, балалар! Бал кортлары тагын аланлыкка очып чыктылар: бер бал корты, тагын бер бал корты – бал кортлары күп, бик күп. Бал кортлары күп иде, аю өеннән чыккач, бал кортлары курыктылар һәм үз ояларына очып керделәр. Бу ояда бер бал корты, бу ояда бер бал корты һәм бу ояда да бер бал корты. Һәр ояда ничә бал корты бар? (*Бер*)

Уен берничә тапкыр кабатлана. Уеннан соң, атрибутларны җыйганда, балаларның игътибары тагын *бер, күп* булган предметларга юнәлтелә.

**Тәрбияче.** Балалар, менә бер битлек, тагын бер, ә барысы бергә күп була. Бик яхшы. Булдырдыгыз, балалар! Без сезнең белән җәй турында сөйләштек. Җәйне барыбыз да бик яратабыз.

## МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ ӨЛКӘСЕ

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | З. Гомәрованың «Ул шуңа кечкенә» дигән шигырен уку | 1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү; аерым сүзләрне, фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына ирешү; сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерләрен, хәрәкәт активлыкларын үстерү;<br>3) әсәргә карата кызыксыну уяту, сәламәт яшәү теләге тәрбияләү. |
| | | Э.Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» шигырен уку | 1) балаларны Э. Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» дигән шигыре белән таныштыру; аерым сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлап, сөйләмдә активлаштыру;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү. |
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | Ә. Бикчәнтәеваның «Туп» шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; сорауларга җавап бирүгә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кечкенәләр турында кайгыртучанлык хисе тәрбияләү; бергә шөгыльләнергә теләк уяту. |
| 11.09.-30.09. | Көз | «Аю белән Бабай» әкиятен уку. | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; үсемлекләр турындагы белемнәрен киңәйтү; сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, кулның вак моторикасын үстерү;<br>3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11.09.-<br>30.09. | Көз | Ә. Ерикәйнең «Көз» шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; шигырьдәге килде, *саргайды, шиңде, сибелде* фигыльләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарларын үстерү;<br>3) көзге матурлыкка соклану хисе, күзәтүчәнлек тәрбияләү. |
| | | М. Фәйзуллинаның «Көзге яңгыр» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, уен барышында чикләнгән мәйданда йөгерергә күнектерү;<br>2) аңга алуларын, игътибарларын үстерү; тәрбияче сигналы буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү;<br>3) шигъри әсәр белән кызыксыну, уен ярдәмендә тыңлаучанлык тәрбияләү. |
| 1.10.-<br>15.10. | Мин һәм минем гаиләм | «Баш бармак...» шигъри әсәрен уку. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеге аша бармак атамаларын истә калдыру, бармак уеннары өйрәнү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, бармакларының хәрәкәтчәнлеген үстерү;<br>3) халык авыз иҗатына хөрмәт тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.10.-<br>15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Ә.Бикчәнтәеваның «Бәтиләр» шигырен уку | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү; сорауларга тулы җаваплар бирергә, аваз ияртемнәрен дөрес кабатларга өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, сүзлек байлыгын, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисе тудыру. |
| | | Ш. Маннурның «Яратам» шигырен яттан өйрәнү. | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; сүзлекне баету һәм активлыштыру; гаилә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br>2) шигъри әсәрне яттан сөйләргә теләк уяту; аңга алуларын, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.10.-15.10. | Мин һәм минем гаиләм | «Кем нәрсә ярата?» дигән татар халык әкиятен сөйләү. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы күзаллауларына төгәллек кертү; аваз ияртемнәрен ачык һәм дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү;<br>3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 16.10.-04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | «Әлли-бәлли итәргә ...» бишек җырын уку. | 1) бишек җырының эчтәлеген, тәрбияче сөйләмен аңлауларына ирешү; сөйләмдә *тирбәтергә* фигылен куллана белергә өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарны, конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади кагыйдәсен (тәмле йокы теләү) тормышта куллану теләге уяту; бишек җырлары белән кызыксыну, аларны уен вакытларында җырларга омтылыш тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 16.10.-04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | Н. Каштанның «Безнең сыер» шигырен уку. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; кайбер сүзләрне (мөгери, китер, йөгер) үзләштерүләренә ирешү, [у] авазы кергән аваз ияртемнәрен әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. |
| | | Җ. Тәрҗемановның «Үзен бик чиста йөртә» шигырен уку. | 1) балаларның яңа шигырьне эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, сорауларга төгәл итеп җавап бирергә күнектерү;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен, хәрәкәтләре төгәллегенен үстерү;<br>3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге тәрбияләү. |
| | | «Олыга – утын ярырга» бармак уены | 1) фольклор әсәрләренә карата кызыксыну уяту; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү;<br>2) балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру;<br>3) хезмәткә уңай караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15.11.-31.12. | Яңа ел бәйрәме | Б.Рәхмәтнең «Кыш бабай» шигырен яттан өйрәнү. | 1) эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; шигырьне яттан сөйләүгә омтылышларын хуплау, сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүгә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сүзлеген, игътибарын, хәрәкәтләр төгәллеген үстерү;<br>3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай хисләр тәрбияләү. |
| | | И.Шәймөхәммәтовның «Мактанчык бака» әсәрен уку. | 1) балаларны хикәя белән таныштыру, мактанчык сүзен сөйләмдә активлаштыру, тәрбияче биргән сорауларга аңлап җавап бирергә күнектерү; әйләнә-тирә турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) балаларда тыйнаклык; бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 15.11.-31.12. | Яңа ел бәйрәме | Р. Вәлиеваның «Сүз тыңлаучан булыгыз» шигырен уку. | 1) балаларны Р.Вәлиеваның шигыре белән таныштыру, сорауларга төгәл җавап бирүләренә ирешү, *җиһаз* сүзен актив сүзлеккә кертү. Җиһаз атамаларын таный һәм атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, диалогик сөйләмен үстерү;<br>3) тыйнаклык, тыңлаучанлык тәрбияләү, кунакта үз-үзеңне тота белү кагыйдәләрен үзләштерә башлау. |
| 01.01.-31.01. | Кыш | Һ.Такташның «Ләйлә» шигырен уку | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес җавап бирүләренә ирешү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга теләк уяту; ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләр төгәллеген үстерү;<br>3) кышкы табигатьнең матурлыгын күрә, соклана белүләренә шартлар тудыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.01.-<br>31.01. | Кыш | Җ. Дәрзамановның «Алмаз» шигырен уку. | 1) балаларны<br>Җ. Дәрзамановның шигыре белән таныштыру, тәрбияченең сорауларына җавап бирергә күнектерү; җыр тыңлаганда актив булырга өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарны, сүзлекне, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br>3) дөрес киенергә теләк уяту, шигырьләр белән кызыксыну хисе тәрбияләү. |
| | | Ә. Бикчәнтәеваның «Салкын саф һава» шигырен ятлау. | 1) балаларны шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, кышкы табигать турындагы белемнәрен тирәнәйтү, шигъри текстны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) сәнгатьле сөйләмнәрен үстерү;<br>3) шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| 01.02.-<br>23.02. | Ватанны саклаучылар көне | З. Туфайлованың «Шофер булам» дигән шигырен уку. | 1) балаларны шигырьнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирә белүләренә ирешү, сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) шофер хезмәтенә карата кызыксынуларын үстерү, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген төшендерү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.02.-<br>23.02. | Ватанны саклаучылар көне | Ә.Исхакның «Гүзәл» шигырен уку. | 1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү, тәрбияче сорауларына аңлы рәвештә җавап бирүләренә, җырның сүзләренә туры китереп, төгәл хәрәкәтләр ясауларына ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда культура-гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| 24.02.-<br>08.03. | Сигезенче Март | Д. Аппакованың «Рөстәм» әсәрен уку. | 1) чәчмә әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияченең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен үстерү;<br>3) табын әдәбе тәрбияләү. |
| | | «Чәбәк-чәбәк әбкәсе...» юаткычын уку | 1) балаларның юаткычны күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белүләренә ирешү; истә калдыру максатыннан, юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан берничә тапкыр кабатларга мөмкинлек бирү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын; кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) татар халык аваз иҗаты белән кызыксыну, әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 24.02.-08.03. | Сигезенче Март | З. Туфайловның «Әни сүзе» шигырен ятлау. | 1) балаларны шигырь белән таныштыру; истә калдыру максатыннан, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, аларда уңай эмоцияләр тудыру;<br>3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | Г. Нәбиуллинаның «Әнигә булышам» шигырен уку. | 1) балаларны Г.Нәбиуллинаның шигыре белән таныштыру, бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, диалогик сөйләмнәрен, кулларының вак моторикасын үстерү;<br>3) әниләргә ярдәм итү теләге, тырышлык, пөхтәлек тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 09.03.-31.03. | Халык җәүһәрләре | Л. Толстойның «Өч аю» әкиятен уку | 1) балалар өчен зур күләмле булган әкиятне игътибар белән тыңлауларына һәм аңлауларына ирешү; сәнгатьле сөйләм аша балаларда әдәби персонажларның эшгамәлләренә бәя бирү, үз кичерешләрен чагылдыра белү күнекмәләре формалаштыра башлау; сүзлекне активлаштыру, балаларның сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Л. Толстойның « Өч аю» әкиятен сөйләү | 1) әсәрне кабаттан игътибар белән эчтәлеген аңлап тыңлауларына ирешү, башкаларның эмоциональ халәтен аңлый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>3) әйләнә-тирәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; җиһазга карата сакчыл караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 09.03.-31.03. | Халык җәүһәрләре | «Төлке, Куян һәм Әтәч» әкиятен сөйләү | 1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү; сюжетның үсеше артыннан күзәтергә, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлек, кайгыртучанлык, ярдәмчеллек, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү. |
| 01.04.-20.04. | Яз | Д. Гарифуллинның «Тавыклар һәм Таһир» шигырен уку | 1) шигъри әсәр белән таныштыру; йорт кошлары турындагы белемнәрен тирәнәйтү; сорауларга аңлап, дөрес җавап бирүләренә ирешү; аваз ияртемнәре әйтелешен ныгыту; бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның аңга алуларын, күзаллауларын, игътибарын, кул хәрәкәтләрен, иҗади сәләтләрен үстерү; фантазияләрен баету;<br>3) балаларда йорт кошларына карата кайгыртучанлык, үзләре башкарган эшкә шатлана белү хисләре тәрбияләү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.04.-20.04. | Яз | Р. Батулланың «Елак әтәч» әсәрен уку | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүләренә ирешү; төрле орлыкларны (бодай, дөге) аера белергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, кул чукларының вак мускулларын үстерү; яңа сүзләрне сөйләмдә активлаштыру;<br>3) тешләрне саклау, алар турында кайгырту кирәклеген аңлауларына ирешү; культура-гигиена кагыйдәләре формалаштыру. |
| | | Б. Рәхмәтнең «Яз» шигырен ятлау | 1) балаларны Б. Рәхмәтнең «Яз» шигыре белән укып таныштыру, истә калдырырга ярдәм итү; эчтәлегенә туры китереп, сорауларга җавап бирергә өйрәтү, яз турында белемнәрен баету;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, сөйләмнәренең сәнгатьлелеген үстерү;<br>3) шигырьдә сурәтләнгән язгы табигатькә карата кызыксыну, соклану хисе тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.04.-<br>20.04. | Яз | Х.Вахитның «Уңган сыерчык» шигырен уку | 1) балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларына шигырь сүзләре белән җавап бирүләрен ныгыту; музыка астында түгәрәктә бер-берсенә комачауламый йөри белүләрен формалаштыру; кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда туган якка мәхәббәт, җылы яктан кайткан кошларга карата кызыксыну, мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү. |
| 02.05.-<br>31.05. | Җәй | «Тилгән» эндәшен уку | 1) балаларның шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белүләренә ирешү; шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзлекләрен баету, шигырь сүзләрен истә калдыруларына ирешү; кошлар (тилгән) турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, конкрет–образлы фикерләвен үстерү;<br>3) балаларның шигырьне дөрес интонация белән сөйләүләренә ирешү. |



| | | | |
|---|---|---|---|
| 02.05.-<br>31.05. | Җәй | «Аю белән хатын» әкиятен уку | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; сүзлекне баету, сөйләмдә активлаштыру. [3] авазын дөрес, ачык әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, фикерләүләрен үстерү; чикләнгән пространствода йөгерергә өйрәтүне дәвам итү;<br>3)халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белүчәнлек хисләре тәрбияләү. |
| | | Җ. Тәрҗемановның «Кикрикүк» шигырен уку. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; тема буенча сүзлекләрен баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатларга һәм аваз ияртемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен, бармак хәрәкәтләрен үстерү; вакыт буенча (иртә-кич) ориентлашырга өйрәтә башлау;<br>3) балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 02.05.-31.05. | Җәй | М. Мазуновның «Кәҗә» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирергә, аваз иялтемен дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) йорт хайваннары белән кызыксыну, алар турында кайгыртучанлык тәрбияләү. |



## *Беренче бүлек.* САУ БУЛ, ҖӘЙ! ИСӘНМЕ, БАЛАЛАР БАКЧАСЫ!

### Тема. 3. ГОМӘРОВАНЫҢ « УЛ ШУҢА КЕЧКЕНӘ» ДИГӘН ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү; аерым сүзләрне, фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына ирешү; сүзлекләрен активлаштыру;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерләрен, хәрәкәт активлыкларын үстерү;

3) әсәргә карата кызыксыну уяту, сәламәт яшәү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** курчак, «Курчак» җырының аудиоязмасы (М.Бикбова сүзләре һәм көе).

**Эшчәнлек барышы**

Аудиоязмада М.Бикбова сүзләре һәм көенә « Курчагым» җыры яңгырый.

**Тәрбияче.** Балалар, игътибар белән җырны тыңлагыз әле. Нинди матур җыр! Ул нәрсә турында икән? *(Курчак турында)*. Балалар, менә ул курчак бүген безгә кунакка килгән. Аның белән исәнләшик әле. (Активлаштыру). Балалар, әйдәгез, курчакны сөендерик, аның турында шигырь укыйк. (Тәрбияче шигырь укый).

Ул шуңа кечкенә

Әнием гел миңа :<br>– Үскәнем минем, -ди.

Ник минем курчакның<br>Үскәне күренми?

| | |
|---|---|
| Әй, минем курчагым | Ул шуңа үсми шул. |
| Ашамый һич кенә. | Ул шуңа кечкенә. |

*З. Гомәрова*

– Балалар, менә нинди матур шигырь тыңладык. Әнисе кызына ничек дип эндәшә? *(Үскәнем минем)*. Әйе, балалар, әнисе кызына «үскәнем» дип эндәшә, чөнки кыз үсә. Балалар, әйдәгез, без дә үсеп күрсәтик әле. (Кулларны өскә күтәреп, аяк очларына басалар). Булдырдыгыз, сез дә зур, акыллы булып үсәсез. Балалар, кызның курчагы үсәме? *(Юк)*. Ни өчен үсми? (Активлаштыру). Үсәр өчен, нәрсә эшләргә кирәк? (Активлаштыру). Әйе, балалар, үсәр өчен, сәламәт булу өчен, (авырмас өчен) ботка, аш, ипи, ит, салатлар, балык ашарга кирәк, уйнарга, саф һавада булырга кирәк. (Тәрбияче шигырьне икенче кат укый). Балалар, мин шигырьне тагын бер кат укыйм, ә сез кайбер сүзләрне минем арттан кабатларсыз. Ә курчак безне тыңлап утыра. Булдырдыгыз! (Кул чабалар).

– Балалар, «үскәнем» дип тыңлаучан, үскән балаларга гына әйтәләр.Шуңа күрә әниләрнең, әтиләрнең сүзләрен тыңларга, акыллы булырга кирәк. Әйдәгез, хәзер бер уен уйнап алыйк.

«Үсәм» уенын уйныйлар. Балалар басып торалар, тәрбияче шигырьне сөйли, балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

| | |
|---|---|
| Мин әле бик кечкенә. | *Балалар алга таба иеләләр.* |
| Миңа бары өч кенә. | *Күтәреләләр.* |
| Үсә, үсә зур булам, | |
| Бик матур малай (кыз) булам. | *Ике кулның да имән бармакларын бит урталарына куеп, башларын чайкыйлар.* |

– Булдырдыгыз, балалар! (Кул чабалар).



**Тема. Э.МӨЭМИНОВАНЫҢ « ҮЗ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ» ШИГЫРЕН УКУ.**

**Бурычлар:**

1) балаларны Э. Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» дигән шигыре белән таныштыру; аерым сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлап, сөйләмдә активлаштыру;

2) аңга алуларын, игътибарларын, фикерләүләрен үстерү;

3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** «Туган тел» җырының аудиоязмасы ( Г. Тукай сүзләре, халык көе).

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, һәрбер кешенең авыз эчендә теле бар. Сез дә телегезне күрсәтегез әле. Әйе, менә шулай. Тел авыз эченнән чыкты да уңга борылды, сулга борылды.(Тәрбияче күрсәтә, балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар). Әйе, тел бик хәрәкәтчән. Тел ни өчен кирәк? (Балаларны активлаштыру). Әйе, тел сөйләшү өчен кирәк. Төрле кешеләр төрле телләрдә сөйләшәләр: татар, рус, инглиз һ.б. телләрдә. Ә сез нинди телдә сөйләшәсез? *(Татар телендә)*. Әйе, безнең туган телебез татар теле. Хәзер мин сезгә туган тел турында бер матур шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз.

Үз телендә сөйләшә

Әтисе дә сөйләшә,
Әнисе дә сөйләшә.
Шулай булгач , нигә әле
Айдарга сөйләшмәскә?!
Теле бар бит аның да!
Кара- каршы сөйләшергә
Әбисе бар янында.

– Әт- тә, ән-нә, тәт- тәт- тәт!...
Әб- бә, баб- ба, тәт- тәт- тә...
Айдар шулай матур итеп,
Үз телендә сөйләшә.
*Э. Мөэминова*

– Шигырьдә кем турында сүз бара? *(Малай)*. (Активлаштыру). Аның исеме ничек? (*Айдар*). Айдар нәрсә эшли белә? *(Сөйләшә белә)*. Аңа сөйләшергә нәрсә булыша? *(Тел)*. (Балаларны активлаштыру). Айдар әле кечкенә. Ул сөйләшергә өйрәнә генә. Ул нинди сүзләр әйтә? (*Әт-тә, ән-нә, тәт- тәт, әб-бә, баб-ба*). Айдар белән кемнәр сөйләшә? *(Әтисе, әнисе, әбисе*). Балалар, тыңлагыз әле, шигырьне мин тагын бер кат укыйм, ә сез миңа ярдәм итегез, кайбер сүзләрне минем арттан кабатлагыз. (Тәрбияче шигырьне укый).

– Балалар, безнең телебез бик матур! Үз телендә сөйләшкән балалар акыллы, зирәк булалар. Айдар да шундый малай булып үсеп җитәр. Сез дә беркайчан туган телегезне онытмагыз, аны өйрәнегез һәм яратыгыз! Хәзер Г.Тукайның «Туган тел» җырын тыңлагыз. Белсәгез, кушылып җырларга мөмкин.

Г.Тукайның «Туган тел» җыры яңгырый.

## Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «ТУП» ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрнең эчтәлеге аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; сорауларга җавап бирергә күнектерү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;

3) балаларда кечкенәләр турында кайгыртучанлык хисе тәрбияләү; бергә шөгыльләнергә теләк уяту.



**Җиһазлар:** курчак, бала санынча кәрзингә салынган кечкенә туплар, савытлар белән су.

### Эшчәнлек барышы

Бала елаган тавыш ишетелә.

**Тәрбияче.** Балалар, ишетәсезме, кемдер елый. Кем елый икән? (Тәрбияче балаларны курчаклар почмагына алып килә). Карагыз әле, курчак елый. (Тәрбияче курчакны кулына ала). Курчакның исеме Әминә икән. Әминә, нигә елыйсың? (Курчакны якын китерә). Әминәнең тубы суга төшеп киткән икән. Балалар, туп суда батамы? (Балаларны активлаштыру). Туп суда батмый. Әминә, елама, туп суда батмый. Туп суга төшеп китсә дә, аны алып була. Әйдәгез, шул турыда шигырь укыйк. Әминә, син дә утырып тыңла әле.

Туп

Әминә елый үкереп,
Тубым суга төште, дип.
– Чү, Әминә, елама,
Туп батмый ул елгада.
*Ә.Бикчәнтәева*

– Балалар, Әминә нигә елый? *(Тубы суга төшкән)*. Әминә еламасын өчен, нәрсә әйтергә кирәк? *(Чү, Әминә, елама)*. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. Чү, Әминә, елама, туп батмый ул елгада. Гүзәл, әйдә, син кабатла һәм Әминәне тынычландыр, юат. (Бала курчакны кочаклый, йә башыннан сыйпый). Марат белән Алсу, ә сез бергә кабатлагыз әле. (Активлаштыру. Тәрбияче шигырьне икенче кат укый. Өченче кат шигырьне бергәләп кабатлыйлар). Әйдәгез әле, балалар, шигырьне бергәләп укыйк.

– Балалар, карагыз әле, Әминә сөенде. Чөнки ул тупның суда батмавына ышанды. Ул елмая. Ә хәзер, әйдәгез, туплар белән уйнап алыйк. Кәрзиндә нәрсәләр бар?

(Туп салынган кәрзин күрсәтә). *(Туплар).* Балалар, һәрберегез берәр туп алыгыз һәм савыттагы суга салыгыз. Карагыз әле, туплар никадәр күп. Алар суда батамы? *(Юк).* Булдырдыгыз! Хәзер тубыгыз суга төшеп китсә дә, еламассыз.

## *Икенче бүлек.* КӨЗ

### Тема: «АЮ БЕЛӘН БАБАЙ» ӘКИЯТЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; үсемлекләр турындагы белемнәрен киңәйтү; сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, кулның вак моторикасын үстерү;

3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф (коврограф); аю, бабай, шалкан, бодайның контурлы сурәтләре; поднос; капчыкка салынган бодай бөртекләре, балалар санынча аю битлекләре.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, барыгыз да матур итеп keләмгә утырыгыз. Мин сезгә әкият сөйлим. Әкият аю белән бабай турында, шуңа күрә әкият тә «Аю белән Бабай» дип атала.

Тәрбияче балаларга әкият сөйли. Сөйләү барышында коврографта (фланелеграфта) әкият персонажларының контурлы сурәтләрен күрсәтә яки күләмле уенчыклар, өстәл театр куллана.

**Тәрбияче.** Балалар, әкият геройларын исегездә калдырдыгызмы? Әкияттә катнашкан геройларны атагыз әле. *(Аю, Бабай).*



Сораулар биргәндә, тәрбияче аю һәм бабай сурәтләрен фланелеграфта күрсәтә бара.

– Дөрес, балалар, менә ул Аю (фланелеграфка куя). Менә Бабай (фланелеграфка куя). Аю белән Бабай нәрсә чәчкәннәр? *(Шалкан).* (Шалкан сурәтен фланелеграфка куя). Дөрес, шалкан бик мул булып үскән. Мул булып, ягъни, күп булып үскән, уңган. Балалар, шалканның тамырын, яфрагын күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр). Гүзәл шалканның нәрсәсен күрсәтте? *(Яфрагын)* Әмир шалканның нәрсәсен күрсәтте? *(Тамырын).* (*Тамыр* сүзен активлаштыру). Аю шалканның нәрсәсен алган: тамырынмы, яфрагынмы? *(Яфрагын)*. Балалар, Аю шалканның яфрагын алып, дөрес эшләгәнме? *(Юк).* Дөрес, шалканның яфрагын ашамыйлар. Аю алданган. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: алданган. (Күмәк кабатлау). Бабайга кайсы җире калган? *(Тамыры*). Дөрес, тамыры, ягъни, шалкан үзе калган. Балалар, икенче юлы Аю белән Бабай нәрсә чәчкәннәр? *(Бодай).* Менә ул бодай. (Тәрбияче фланелеграфта бодай рәсемен куя). Балалар, карагыз әле, бодайның нинди өлешләре бар? *(Сабагы, тамыры).* Сабагында аның орлыклары бар. (Капчыкка салынган бодай бөртекләре күрсәтә). Балалар, бодай бөртекләрен кулыгызга алып карагыз әле. Алар йомшакмы, катымы? *(Каты).* Аю бодайның кайсы өлешен алган? *(Тамырын*). Аю дөрес эшләгәнме? *(Юк).* Ни өчен? *(Бодайның тамырын ашамыйлар).*

– Ә Бабай бодайның кайсы өлешен алган? *(Сабагын)*. Дөрес, балалар, Бабай сабагын алган һәм алданмаган. Аю тагын алданган. Аюга, алданмас өчен, үсемлекләрне яхшы белергә кирәк иде шул. Кайбер үсемлекләрнең тамырын, ә кайберләренең сабагын, яфрагын, орлыгын ашыйлар. Аю белән Бабай бергә шалкан, бодай үстергәннәр. Бик тырышканнар - шуңа күрә уңыш та мул булган. Ә уңышны дөрес бүлмәгәннәр. Аю кебек үзеңне алдатмас өчен, күп белергә кирәк. Балалар, әйдәгез, уйнап алыйк.

Сез аю балалары булырсыз. (Тәрбияче балаларга аю битлекләре кидерә).

| | |
|---|---|
| Аю башта шалкан чәчкән, | *Чүгәләп, түтәлгә орлык чәчү хәрәкәте ясыйлар.* |
| Аннан бодай чәчкән, | *Басып, Аю кебек йөреп, бер кулга бодай салынган савыт тотып, икенче кул белән аннан бодай алып, җиргә сибү хәрәкәте ясыйлар.* |
| Эшләгәч, ул бик арган, | *Башны уңга-сулга селкиләр.* |
| Тәмләп йокыга талган. | *Кулларның учларын бергә кушып, биткә куеп, «йоклап китәләр».* |

– Балалар, Аюның бодайларын менә бу капчыкка салганнар. Хәзер мин аларны бушатам (подноска сала). Сез аларны яңадан капчыкка тутырыгыз. Бер генә бөртекне дә идәнгә төшермәгез! Булдырдыгыз! (Кул чабалар).

## Тема. Ә. ЕРИКӘЙНЕҢ «КӨЗ» ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; шигырьдәге *килде, саргайды, шиңде, сибелде* фигыльләре хисабына сүзлекне баету;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарларын үстерү;

3) көзге матурлыкка соклану хисе, күзәтүчәнлек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** көзге урман сурәтләнгән рәсем, «Яфрак бәйрәме» җырының аудиоязмасы *(Р. Еникеева көе, Л. Лерон сүзләре).*



**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, бүген мин сезне көзге урманга чакырам. (Тәрбияче балаларны көзге урман сурәтләнгән рәсем янына алып килә). Балалар, үләннәргә игътибар итегез әле. Үләннәр нинди төстә? *(Сары).* Әйе, үләннәр сары төстә, алар саргайган һәм шиңгән. Үләннәр нишләгән? *(Саргайган, шиңгән).* (Балаларны активлаштыру). Балалар, агачтагы яфракларга карагыз әле. Алар нинди төстә? *(Сары, кызыл, яшел).* Җил искәч, яфраклар нишлиләр? *(Җиргә коелалар).* Карагыз әле, җирдә яфраклар күпме? *(Күп).* Хәзер сез сары яфраклар булырсыз.

Тәрбияче балаларга көзге яфраклар тарата. Аудиоязмада «Яфрак бәйрәме» җырын тыңлыйлар.

**Тәрбияче.** Балалар, агачларда бик күп яфраклар яши. Көз килеп, яфракларны сары, кызыл төсләргә буяган. Алар тагын да матурайганнар. Көчле җил искән, яфраклар оча, җиргә коела башлаганнар. (Балалар җыр барышында йөгерәләр, әйләнәләр һәм чүгәлиләр).

– Балалар, тиздән көз бәйрәме. Бәйрәмдә нәрсә эшлиләр? *(Җырлыйлар, бииләр, шигырь сөйлиләр).* Менә без дә бүген сезнең белән көз турында шигырь өйрәнербез. Игътибар белән тыңлагыз әле. (Тәрбияче шигырьне укый).

### Көз

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.
*Ә. Ерикәй*

Тәрбияче шигырьне тагын бер тапкыр укый. Балалар аңа ярдәм итәләр.

Тәрбияче

Көз *(килде)*. Үләннәр
*(Саргайды, шиңде)*.
Сап-сары *(яфраклар)*
Җиргә *(сибелде)*.

(Тәрбияче яфраклар сибә). Балалар, без хәзер сезнең белән яфраклардан гирлянда ясыйбыз. Бүлмәне шул гирлянда белән матур итеп бизәп куябыз. Карагыз әле, нинди матур гирлянда килеп чыкты! Көзнең матурлыгы урманны гына түгел, безнең бүлмәне дә бизәп торсын әле. Булдырдыгыз!

## Тема М. ФӘЙЗУЛЛИНАНЫҢ «КӨЗГЕ ЯҢГЫР» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) шигырьнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, уен барышында чикләнгән мәйданда йөгерергә күнектерү;

2) аңга алуларын, игътибарларын үстерү; тәрбияче сигналы буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү;

3) шигъри әсәр белән кызыксыну, уен ярдәмендә тыңлаучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** ковролграф. Кояш, болыт, яңгыр, апа, сеңелнең контурлы сурәтләре. Зур зонт.

### Эшчәлек барышы

Тәрбияче балаларны тәрәзә янына алып килә

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, бүген урамда һава торышы нинди? Әйе, көн болытлы, кояш күренми. Җил исә, агачлардан



яфрак коела. Шыбыр-шыбыр яңгыр ява. Яңгыр ничек ява? *(Шыбыр-шыбыр).* Балалар, бу көзге яңгыр. Көзге яңгыр салкын, ул битләрне, кулларны туңдыра. Балалар, нинди яңгыр салкын? *(Көзге яңгыр).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Тыңлагыз әле, көзге яңгыр турында мин сезгә шигырь укыйм.

Көзге яңгыр

Апа, безгә артыбыздан
Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
- Кем дә дәшми, көзге яңгыр
Зонтик белән сөйләшә.
*М. Фәйзуллина*

Тәрбияче шигырьне укый һәм ковролграфта шигырьдә сурәтләнгән күренешләрне күрсәтә: яңгыр ява, зонтик тоткан бала апасы белән бара. Шигырьне тагын бер тапкыр укый.

**Тәрбияче.** Балалар, кыз апасыннан нәрсә турында сораган? (Балаларны активлаштыру). Кыз апасы белән урамнан бара. Яңгыр ява. Шуңа күрә алар зонтик тотканнар. Яңгыр зонтикка төшә, ул шыбырдаган тавыш чыгара. Алсу, шигырьдәге кыз булып, апага сорау биреп кара әле. (Алсу шигырьнең ике юлын әйтә, әйтә алмаса, тәрбияче сүзне әйтеп җибәрә). Балалар, сеңлесе апасыннан нәрсә турында сорый? Апа, безгә артыбыздан шыбыр-шыбыр кем дәшә? (Балалар җавап бирә алмасалар, тәрбияче әйтеп җибәрә). Апасы сеңлесенә нәрсә дип җавап биргән? (*Кем дә дәшми, көзге яңгыр зонтик белән сөйләшә*). Шигырьне мин тагын бер тапкыр укыйм, ә сез миңа ярдәм итәрсез. (Тәрбияче шигырьне укый).

Апа, безгә артыбыздан
*шыбыр-шыбыр кем дәшә?*
– Кем дә дәшми, ... *көзге... яңгыр*

Зонтик белән ... *сөйләшә.*

– Булдырдыгыз. (Балалар кулларын чәбәклиләр).

– Сез дә яңгырлы көнне бакчага зонтик астында киләсез. Зонтик астына яңгыр керми, зонтик сезне яңгырдан саклый. Әйдәгез әле, «Кояш һәм яңгыр» уенын уйнап алыйк. (Тәрбияче коврографка кояш рәсемен куя). Кояш чыкты, көн җылы, балалар уйныйлар. (Балалар бүлмә буенча йөгерәләр). (Тәрбияче коврографка болыт рәсемен, яңгыр тамчыларын куя). Балалар, карагыз әле, кояш болыт артына качты, яңгыр ява башлады. Килегез минем яныма, зонтик астына. Менә шулай. Барлык балалар да: Алсу, Булат, Камилә һ.б. зонтик астына качтылар. Аларга яңгыр тими. Булдырдыгыз.

Уен шулай 2-3 тапкыр кабатлана.

## *Өченче бүлек.* МИН ҺӘМ МИНЕМ ГАИЛӘМ

### Тема. «БАШ БАРМАК...» ШИГЪРИ ӘСӘРЕН УКУ.

**Бурычлар**.

1) шигъри әсәрнең эчтәлеге аша бармак атамаларын истә калдыру, бармак уеннары өйрәнү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, бармакларының хәрәкәтчәнлеген үстерү;

3) халык авыз иҗатына хөрмәт тәрбияләү.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, бу – минем кулларым. Үз кулларыгызны күрсәтегез әле. Балалар, әйдәгез, үзебезнең кулларыбызны яратыйк әле, сыпырыйк. Балалар, куллар безгә ни өчен кирәк? *(Ашау өчен, рәсем ясау өчен, уйнау өчен, юату өчен, ярату өчен һ.б).* (Активлаштыру). Балалар, һәр бармакның үз атамасы бар. Бу бармак - баш бармак. (Тәрбияче күрсәтә). Бу нинди бармак? *(Баш бармак)*. Ә бу бармак - имән бармак. Бу



нинди бармак? *(Имән бармак)*. Бу бармак уртада урнашкан. Шуңа аның исеме дә урта бармак дип атала. Бу бармакның исеме ничек? *(Урта бармак)*. Ә бу бармакның атамасы юк. Шуңа күрә аны атсыз бармак диләр. Балалар бу нинди бармак? *(Атсыз бармак)*. (Активлаштыру). Балалар, ә монысы нинди бармак икән? *(Нәни, кечкенә)*. Әйе, балалар, бу бармак кечкенә, аның исеме - чәнти. *(Чәнти).* Балалар, мин хәзер сезне бармак уены белән таныштырам, тыңлагыз әле. (Тәрбияче шигъри әсәрне сөйли).

Баш бармак бау ишә,
Имән бармак имән кисә,
Урта бармак утын кисә,
Атсыз бармак ат җигә,
Чәнти бармак чәй эчә.

– Балалар, баш бармак нәрсә эшли? *(Бау ишә)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Имән бармак нәрсә кисә? *(Имән кисә)*. Ә урта бармак нәрсә кисә? *(Утын кисә)*. Атсыз бармак нәрсә эшли? *(Ат җигә)*. Ә чәнти бармак ни эшли? *(Чәй эчә)*.

– Балалар, шигъри әсәрне тагын бер тапкыр укыйм, игътибар белән тыңлагыз. (Тагын бер кат укый ). Балалар, ә хәзер әсәрне сөйләргә сез ярдәм итәрсез.

Баш бармак ...*(бау ишә)*,
Имән бармак ...*(имән кисә),*
Урта бармак ...*(утын кисә),*
Атсыз бармак ...*(ат җигә),*
Чәнти бармак ...*(чәй эчә).*

– Булдырдыгыз, балалар, матур итеп, сәнгатьле итеп сөйләдегез. Бу бармак уенын башка вакытта да кабатларбыз, уйнарбыз.

## Тема. Ә.БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «БӘТИЛӘР» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү; сорауларга тулы җаваплар бирергә, аваз ияртемнәрен дөрес кабатларга өйрәтү;

2) балаларның аңга алуларын, сүзлек байлыгын, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;

3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисе тудыру.

**Җиһазлар:** уенчык бәрән яки бәрән рәсеме; йон, йоннан бәйләнгән бияләй, шәл, оекбаш, киез итекләр; «Бәтиләр» җырының (Ә. Бакиров музыкасы, Ә. Бикчәнтәева сүзләре) аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы.

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунак килгән.
Ак бөдрә тун кигән.
Үзе кечкенә.
Бә-бә дип кычкыра. Нәрсә икән ул? Әйе, ул бәрән.

Балаларга уенчык бәрән күрсәтә яки фланелеграфка аның контурлы сурәтен беркетә.

**Тәрбияче.** Балалар, бүген безгә бәрән юкка гына килмәгән, аның үзе турында шигырь тыңлыйсы килгән. Сез дә ул шигырьне тыңлап карагыз әле.(Тәрбияче шигырьне укый).

Бәтиләр

Үсә безнең фермада
Бик күп нәни бәтиләр.
– Бә! – диләр.– Бә! – диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.
– Ничек исемнәрегез? –
Дип сорагач, бәтиләр:
– Бә! – диләр. – Бә! – диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.
– Сезгә ничә яшь? – дигәч,
Аңламыйлар бәтиләр;
– Бә! – диләр. – Бә! – диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.
– Шәл бәйләргә йон безгә
Бирегезче, бәтиләр!
– Мә! – диләр. – Мә! – диләр,
Бөдрә тунлы бәтиләр.

*Ә.Бикчәнтәева*

Тәрбияче балаларга фермадагы бәтиләр сурәтләнгән иллюстрация күрсәтә.

**Тәрбияче.** Балалар, шигырьдә нәрсә турында сөйләнә? *(Бәтиләр турында).* Дөрес, бәтиләр турында. Нинди бәтиләр? *(Нәни бәтиләр).* Бәтиләр кайда үсәләр? *(Фермада).* Бәтиләр нәрсә диләр? *(Бә-ә).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. Бәтиләр шәл бәйләргә нәрсә бирәләр? *(Йон).* (Тәрбияче йон күрсәтә). Балалар, бу нәрсә? *(Йон).* Балалар, йонны тотып карагыз әле, ул нинди? *(Ак, йомшак, җылы, кабарып тора).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, йоннан нәрсәләр бәйлиләр? *(Шәл, оекбаш, бияләй).* (Тәрбияче шәл, оекбаш, бияләй күрсәтә). Йоннан тагын нәрсә эшлиләр? *(Итек басалар).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: итек басалар. (Балалар кабатлыйлар). Балалар, нәни генә булсалар да, бәрәннәр безгә менә никадәр файда китерәләр. Алар турында кайгыртырга, аларны сакларга, якларга кирәк. Хәзер шигырьне тагын бер кат тыңлагыз. Бәтиләр әйткән «бә» сүзен бергәләп кабатлагыз. (Тәрбияче укый, балалар «бә» аваз ияртемен бергәләп кабатлыйлар). Балалар, бу шигырьгә көй язылган. Хәзер шул җырны тыңлагыз.

«Бәтиләр» җырын тыңлыйлар.

– Бергә кушылып җырласагыз да була. Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кул чабалар).

### Тема. Ш. МАННУРНЫҢ «ЯРАТАМ» ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.

**Бурычлар:**

1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; сүзлекне баету һәм активлыштыру; *гаилә* сүзен сөйләмдә кулланырга күнектерү;

2) шигъри әсәрне яттан сөйләргә теләк уяту; аңга алуларын, хәтерне, игътибарны үстерү;

3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** гаилә сурәтләнгән рәсем: әти, әни, абыйлы-энеле ике малай һәм бишектәге кыз бала.

#### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балаларга гаилә сурәтләнгән рәсем күрсәтә.

**Тәрбияче.** Балалар, бу рәсемгә игътибар белән карагыз әле. Рәсемдә кемнәр сурәтләнгән? *(Әти, әни, ике малай (абыйлы-энеле) һәм бишектәге кечкенә кыз).* Балалар, бу ике малайга игътибар итегез әле. Аның зуррагын кем дип атыйбыз? *(Абый).* (Активлаштыру). Кечерәк малай зур малайга кем була? *(Энесе була).* Ә бишектәге кыз аларга кем була? *(Сеңел).* Балалар, бу өйдә әти, әни, абыйлы-энеле ике малай һәм аларның сеңелләре яшиләр. Икенче төрле аларны ничек итеп әйтергә була? *(Гаилә).* (Сүзләрне активлаштыру). Игътибар белән аларга карагыз әле. Бу гаиләдәге кешеләр бер-берсен яраталар дип әйтеп буламы? *(Әйе).* Нәрсәдә күренә ул? *(Алар елмаялар, өйләрендә тәртип,*



*чисталык).* Сез үзегезнең гаиләгезне яратасызмы? *(Әйе).* Ә хәзер гаилә турында шигырь тыңлагыз.

Яратам

Яратам мин өемне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.
*Ш. Маннур*

Тәрбияче шигырьне икенче кат укый, ә балалар аңа ярдәм итәләр.

**Тәрбияче.** Балалар, мин шигырьне икенче кат укыйм. Ә сез миңа булышыгыз.

Яратам мин *(өемне),*
Әти белән *(әнине),*
Абый белән *(энемне),*
Бишектәге *(сеңлемне).*

– Балалар, гаиләдә бар кеше дә бер-берсен яратсын, хөрмәт итсен. Шул вакытта гына гаилә тату, дус, андагы кешеләр сәламәт була. Ә хәзер без сезнең белән «Гаилә» уены уйнарбыз. (Тәрбияче сюжетлы-рольле уен оештыра).

### Тема «КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?» ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ.

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы күзаллауларына төгәллек кертү; аваз

иятемнәрен ачык һәм дөрес әйтергә күнектерү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү;

3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** песи, эт, әтәч, кәҗә уенчыклары, «Безнең дусларыбыз» җырының аудиоязмасы *(М. Хөсәен сүзләре, А. Ключарев музыкасы)*

## Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, бүген безгә кунаклар килгән. Ләкин алар качканнар. (Уенчыкларның өсләре капланган). Нинди кунаклар икәнен сезнең үзегездән әйттерергә телиләр. Нинди кунаклар икән? Әйдәгез, мин сезгә булышам. Ул мыеклы, йомшак йонлы, сөт ярата, тычкан тота. Белдегезме нәрсә икәнен? *(Песи).* Бик дөрес, песи. (Тәрбияче яшергән урыннан уенчык песи алып өстәлгә куя). Песи ничек кычкыра? *(Мияу).*

– Песи белән тагын башка кунак та килгән: ул йорт саклый, сөяк кимерә, өрә. Бу нәрсә була? *(Эт).* Дөрес. Балалар эт ничек өрә? *(Һау-һау).* (Тәрбияче, яшергән урыннан алып, уенчык этне өстәлгә куя). Тагын бер кунак турында әйтим әле. Кызыл кикрикле, томшыклы, канатлы, бар кешене йокыдан уята. Бу нәрсә? *(Әтәч).* Әтәч ничек кычкыра? *(Кикри-кү-үк).* (Тәрбияче яшергән урыннан уенчык әтәч чыгарып, өстәлгә куя). Тагын бер кунак турында әйтик әле. Үзе сакаллы, сөт бирә, кәбестә ярата. Бу нәрсә икән? *(Кәҗә).* Дөрес, балалар. Кәҗә ничек кычкыра? *(Мә-ә-ә).* (Тәрбияче яшергән урыннан уенчык кәҗә чыгарып куя). Балалар, карагыз әле, безгә күпме кунак килгән! Алар арасында кош та, хайваннар да бар. Алар турында бер әкият сөйлим, игътибар белән тыңлагыз.

(Тәрбияче әкият сөйли һәм өстәлдәге уенчыклар белән сәхнәләштерү алымнары куллана). Бер йортта нәрсәләр яшәгән? *(Песи, эт, әтәч, кәҗә).* Алар нәрсә турында бәхәсләшәләр? *(Нинди ризык тәмлерәк? дип бәхәсләшкәннәр).* Песи нинди сыйны иң тәмлесе дип әйткән? *(Сөт).* Ә әтәч кайсы азыкны мактаган? *(Ярма бөртекләре, солы орлыгы).* (Активлаштыру). Менә ул, балалар, ярма бөртекләре, ә монысы - солы орлыгы. Әтәч менә шуларны ярата. Балалар, әтәч ярма бөртекләрен, солы орлыкларын ничек итеп чүпли? Күрсәтегез әле. (Чүгәләп утыралар, баш бармак белән имән бармакларын тоташтырып, идәндә «тук-тук» дип, ярма чүпләү хәрәкәтләре ясыйлар).

– Булдырдыгыз, балалар! Ә Акбай нәрсә ярата? *(Сөяк).* Ә кәҗә нәрсә ярата икән? *(Кәбестә).* Кәбестә ашап, тамагы туйгач, ничек кычкыра? *(Мэ-э-э).* Балалар, хайваннар, бәхәсләшеп, кайсы азыкның тәмлерәк икәнен белә алганнармы? *(Алар килешә алмаганнар).* (Балалар әйтә алмасалар, тәрбияче үзе әйтеп җибәрә). Һәрбер кошның, хайванның бик яраткан азыгы бар. Шуңа күрә ул турыда бәхәсләшергә дә кирәк түгелдер. Сезгә бары тик кайсы хайван нәрсә ératканын истә калдырырга һәм ул хайваннар очраганда, аларны сыйларга, алар турында кайгыртырга кирәк. Балалар, мин сезгә песи, эт, әтәч турында җыр җырлап күрсәтәм. Сез игътибар белән тыңлагыз һәм үзегез дә кушылып җырлагыз.

Тәрбияче М. Хөсәен сүзләре, А. Ключарев көенә «Безнең дусларыбыз» җырын җырлый. Балалар түгәрәккә басалар, уртада тәрбияче.

Яле, безгә әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
– Зур мыеклы үзе,
Аннан курка күсе.
– Ул бит песи, ул бит песи:
«Мияу», ди, –
Курыкмагыз, мин һәрвакыт уяу, – ди.
Яле, тагын әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
Койрык болгый үзе,
Ялт-йолт итә күзе.
– Ул бит маэмай, ул бит маэмай:

«Һау-һау», ди, –
Минем эшем – сезнең өйне
Саклау, – ди.

Тагын, тагын әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
– Башындагы бүрек
Кып-кызыл ут кебек!
– Ул бит әтәч, ул бит әтәч:
Кикри – күк!
Безне йокыдан уята бик иртүк.

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар! Бик матур җырладыгыз. Хайваннар – безнең дусларыбыз. Аларны яратыгыз!

## *Дүртенче бүлек.* МИНЕМ ЙОРТЫМ, МИНЕМ ШӘҺӘРЕМ

### Тема. «ӘЛЛИ-БӘЛЛИ ИТӘРГӘ ...» БИШЕК ҖЫРЫН УКУ.

**Бурычлар:**

1) бишек җырының эчтәлеген, тәрбияче сөйләмен аңлауларына ирешү; сөйләмдә *тирбәтергә* фигылен куллана белергә өйрәтү;

2) аңга алуларын, игътибарны, конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;

3) сөйләм этикетының гади кагыйдәсен (тәмле йокы теләү) тормышта куллану теләге уяту; бишек җырлары белән кызыксыну, аларны уен вакытларында җырларга омтылыш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** елый торган курчак, бишек.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? *(Бишек)*. (Балаларны активлаштыру). Бишек ни өчен кирәк? *(Бәбиләрне йоклатыр өчен)*. Бала йоклап китсен өчен, бишекне тирбәтәләр. Нишлиләр? *(Тирбәтәләр)*.



Балалар, бишекне сак кына, йомшак кына хәрәкәтләр ясап тирбәтергә кирәк. Бәбиләр курыкмасын өчен шулай тирбәтәләр. Гүзәл, (Марат, Энҗе, Әмир, Әминә), кил әле, бишекне тирбәтеп кара әле. Син нишлисең? *(Тирбәтәм)*. (Шул рәвешле, башка балаларны да бишекне тирбәтеп карарга чакырырга мөмкин). Балалар, әйдәгез, һавада бишекне тирбәтү хәрәкәте ясагыз әле. Менә шулай! Бик матур итеп күрсәттегез. Булдырдыгыз!

Тәрбияче елый торган курчак алып керә. Курчак елый.

**Тәрбияче.** Балалар, ишетәсезме, кемдер елый. Кем елый икән? *(Курчак Алсу)*. Әйдәгез, бергәләп курчак янына килик әле. Курчак нигә елый икән? Алсу, нигә елыйсың? (Балаларны активлаштыру. Балалар үзләре курчакка сорау белән мөрәҗәгать итәләр). Балалар, Алсуның йоклыйсы килә. Ул бит әле кечкенә. Әйдәгез, Алсуны бишеккә салыйк.

Тәрбияче курчакны бишеккә сала һәм бишекне тирбәтеп көйли.

**Тәрбияче.**

Әлли- бәлли итәргә,
Ал бишеге бар аның.
Өзгәләнеп тирбәтергә
Үз әнкәсе бар аның.

– Балалар, әйдәгез, тагын бер тапкыр җырны бергәләп кабатлыйк әле. (Тәрбияче балалар белән бергәләп көйли). Менә Алсу йоклап китте. Алсуга нәрсә дип әйтергә кирәк? Алсу, йокың тәмле булсын! Бергәләп кабатлыйк әле. (Күмәк кабатлаулар). Әйдәгез, аны уятмас өчен, әкрен генә аяк очларына басып, чишенү бүлмәсенә чыгабыз. Балалар, бишек җыры Алсуга бик ошады, шуңа ул бик тиз йокыга китте. Сез дә, курчакларыгыз белән уйнаганда, аларны йоклатканда, бишек җыры җырлый

аласыз. Үзегез йокларга ятканда, әниләрегез җырлар. Шул вакытта сезнең йокыгыз тәмле булыр.

### Тема. Н. КАШТАННЫҢ « БЕЗНЕҢ СЫЕР» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; кайбер сүзләрне (*мөгери, китер, йөгер*) үзләштерүләренә ирешү, [у] авазы кергән аваз ияртемнәрен әйтергә күнектерү;

2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү;

3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сыер рәсеме.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, игътибар белән тыңлагыз әле, мин сезгә бер хайван турында табышмак әйтәм:

Үзе зур, мөгезле,
Озын гына койрыклы.
Сөт бирә, май бирә,
Җәен йөри көтүдә. (*Сыер)*

– Бу нәрсә? Әйе, сыер. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. (Күмәк кабатлау). Балалар, сыер турында бер матур шигырь укырбыз. (Тәрбияче шигырь укый).

Безнең сыер

– Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә мөгери?



– Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер, – ди.
– Ашап туйгач, ник сыер
Сузып – сузып »Му-у» ди ул?
– Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! – ди ул.

*Н.Каштан*

– Балалар, шигырьдә сүз нәрсә турында бара? *(Сыер)*. Кемнең сыеры бар? *(Әбинең сыеры бар).* (Активлаштыру). Сыер нигә мөгери? Әйе, карыны ачкан, аның ашыйсы килгән. Балалар, сыер нәрсә ашый? *(Печән)*. (Активлаштыру). Сыерга печәнне кем бирә? *(Малай)*. Әйе, малай, йөгереп, сыерга печән китерә. Печән ашаткач, сыерга тагын нәрсә бирәләр? *(Су)*. Сыерга суны кем китерә? *(Малай)*. Сыер ничек итеп су сорый? Әйе, сузып-сузып *«Му-у»* ди. Әйдәгез, бергә кабатлыйк әле: Му-у! Китер миңа су-у!

– Балалар, әбинең оныгы кайгыртучан. Ул сыерны печән белән сыйлый, аңа су эчертә. Тыңлагыз әле, мин шигырьне сезгә тагын бер тапкыр укып чыгам, ә сез миңа булышыгыз. (Тәрбияче шигырьне укый).

– Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә *...(мөгери)?*
– Карыны ачкан, улым,
Печән *...(китер, йөгер, – ди).*
– Ашап туйгач, ник сыер
Сузып – сузып ... *(«Му-му»)* ди ул?
– Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа *...(су-у!)* – ди ул.

– Булдырдыгыз, балалар! (Балалар кулларын чәбәклиләр).

**Тема. Ж. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ « ҮЗЕН БИК ЧИСТА ЙӨРТӘ» ШИГЫРЕН УКУ.**

**Бурычлар:**

1) балаларның яңа шигырьне эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, сорауларга төгәл итеп җавап бирергә күнектерү;

2) аңга алуларын, игътибарларын, фикерләүләрен, хәрәкәтләре төгәллегенен үстерү;

3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** песи уенчыгы.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунак килгән. Нинди кунак икән? Әйтеп карагыз әле.

Үзе мыеклы,
Туны мамыклы,
Битен ул юа,
Тик сусыз гына.

– Бу нәрсә? *(Песи).* (Тәрбияче балаларга уенчык песи күрсәтә). Бик дөрес, бу – песи. Песиләр юынырга бик яраталар. Хәзер шул турыда шигырь укырбыз. Игътибар белән тыңлагыз.

Үзен бик чиста йөртә.

Күрәсезме песине,
Юына, чистарына.
Ул кунакка барамы?
Ник юына, арына?
Йомшак тәпие белән
Битен әйбәтләп сөртә.



Ул шулай һәрвакытта.
Үзен бик чиста йөртә.
*Ж. Тәрҗеманов*

– Шигырьдә нәрсә турында сөйләнә? *(Песи турында).* Песи нәрсә эшли? *(Юына).* Балалар, песигә юынырга су кирәкме? *(Юк).* Ә ул битен нәрсә белән сөртә? *(Тәпие белән).* Аның тәпие нинди, катымы, әллә инде йомшакмы? *(Йомшак).* (Активлаштыру). Песи йомшак тәпие белән битен сөрткән кебек, сез дә кулларыгыз белән менә шулай (күрсәтә) маңгаегызны, яңакларыгызны, иягегезне яратып сыпырыгыз әле. Булдырдыгыз! Песи үзен ничек йөртә? (Песи үзен чиста йөртәме?) *(Песи үзен чиста йөртә).* Әйе, балалар, песи шулай һәрвакытта да үзен чиста йөртә.

Тәрбияче шигырьне тагын бер кат укый. Балаларга тәрбияче белән бергә кабатларга тәкъдим итәргә була.

**Тәрбияче.** Балалар, песи һәрвакыт юына, чөнки ул чисталык ярата. Мин дә сезнең пөхтә һәм чиста булуыгызны телим. Чисталык ул – сәламәтлек. Шуңа күрә кулларны, битләрне һәрвакыт юып йөрегез. Балалар, хәзер без сезнең белән песи балалары булып уйнап алырбыз. Әйдәгез, барыгыз да келәмгә басыгыз әле.

| | |
|---|---|
| Нәни песи балалары<br>Тәпиләрен юалар.<br>Менә шулай! Менә шулай!<br>Тәпиләрен юалар. | *Балалар иелеп куллары белән аякларын сыйпыйлар.* |
| Колакларын, корсакларын<br>Ышкып-ышкып юалар,<br>Менә шулай! Менә шулай! | *Уң кул белән уң, ә сул кул белән сул колакларын сыйпыйлар.*<br>*Уң кул белән сәгать теле буенча эчләрен* |

| | |
|---|---|
| Ышкып-ышкып юалар. | *массажлыйлар.* |
| | |
| Аннары соң аралар, | |
| Тәмләп йоклап алалар. | *Балалар келәмгә яталар, күзләрен йомалар һәм йоклаган булып кыланалар.* |
| Менә шулай! Менә шулай! | |
| Тәмләп йоклап алалар. | |

Аннары уенны яңадан кабатларга була.

– Булдырдыгыз, балалар! (Бергәләп кул чабалар).

## Тема. «ОЛЫГА – УТЫН ЯРЫРГА» БАРМАК УЕНЫ

**Бурычлар:**

1) фольклор әсәрләренә карата кызыксыну уяту; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү;

2) балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру;

3) хезмәткә уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** М. Андерьянова көе һәм сүзләренә «Нәниләр» җырының аудиоязмасы

### Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, кулларыгызны карагыз әле. Безнең куллар матур, чиста. Әйдәгез әле, аларны сыпырыйк. (Тәрбияче балалар белән кулларын сыпыралар). Балалар, безнең кулларыбызда бармаклар бар. Бармаклар безгә нәрсә өчен кирәк? (*Елаган баланы юатыр өчен, чәч тарар, кашык тотар өчен һ.б. )* Әйдәгез, мин сезне бер бармак уены белән таныштырам.

Олыга – утын ярырга,
Ә сиңа – чыгып алырга,
Уртага – мичкә ягарга,



Ә сиңа – казан асарга,
Чәнтигә – җырлый башларга,
Дусларның күңелен ачарга.

– Балалар, барыгыз да олы бармакны күрсәтегез әле. (Балалар күрсәтәләр). Олы бармак нәрсә эшли? (*Утын яра*). Бу бармак нишли? (Тәрбияче имән бармакка күрсәтә). (*Утынны чыгып ала*). Бу бармак ничек атала? (*Урта бармак)*. Урта бармак нишли? (*Мичкә яга*). Ә бу бармак нишли икән? (Тәрбияче атсыз бармакка күрсәтә). (*Казан аса*). Ә чәнти бармак нәрсә эшли? (*Ул җырлый, дусларның күңелен ача*). (Активлаштыру).

Тәрбияче бармак уенын икенче кат кабатлый һәм балаларны сүзләрне кабатлауга тарта.

М. Андерьянова көе һәм сүзләренә язылган «Нәниләр» җырының аудиоязмасын куя. Әлеге көйгә балалар, эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

| | |
|---|---|
| Безнең нәни аяклар | *Балалар йөгерү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Шәп итеп йөгерәләр | |
| Куллар да калышмыйлар, | *Кулларны күтәреп чәбәклиләр* |
| Чәп-чәп итеп бииләр. | |
| Әллә-лә, әллә-лә, | *Фонариклар ясыйлар һәм әйләнәләр.* |
| Чәп-чәп итеп бииләр. | |
| Шушы нәни бармаклар | *Иелеп, уенчыклар җыйган хәрәкәтләр ясыйлар.* |
| Уенчыкларны җыя. | |
| Уенчыкларны җыя да | |
| Урыннарына куя. | |
| Әл-лә-лә, әл-лә-лә, | *Балалар әйләнәләр.* |
| Урыннарына куя. | |

| | |
|---|---|
| Апа әйткәч, балалар<br>Беркая да бармыйлар. | *Музыка астында балалар урыннарына утыралар.* |
| Тыныч кына утырып<br>Әкиятләр тыңлыйлар.<br>Әл-лә-лә, әл-лә-лә<br>Әкиятләр тыңлыйлар. | |

– Матур итеп биедегез, яхшы итеп шөгыльләндегез. Булдырдыгыз!

## *Бишенче бүлек.* ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ
### Тема. Б.РӘХМӘТНЕҢ « КЫШ БАБАЙ» ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.

**Бурычлар:**

1) эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; шигырьне яттан сөйләүгә омтылышларын хуплау, сорауларга текст сүзләре белән җавап бирергә күнектерү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сүзлеген, игътибарын, хәрәкәтләр төгәллеген үстерү;

3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай хисләр тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык Кыш бабай.

### Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, балалар бакчасында тиздән нинди бәйрәм булачак? *(Яңа ел)*. (Балаланы активлаштыру). Яңа ел бәйрәмендә балалар нәрсә эшлиләр? *(Җырлар җырлыйлар, биилэр,чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйныйлар)*. Дөрес, балалар, без җырлар, биюләр, уеннар өйрәнәбез. Алсу, Яңа ел бәйрәмендә син нәрсә эшләргә җыенасың? (*Шигырь сөйлим*). (Тәрбияче башка балаларны да шулай активлаштыра). Яңа ел бәйрәменә кемнәр килә?



(*Кыш бабай, Кар кызы, әтиләр, әниләр).* Бик дөрес, балалар. Яңа ел бәйрәмендә иң кадерле кунак – Кыш бабай. Кыш бабай нәрсәләр алып килә? (*Бүләкләр)*. Балалар, Кыш бабай тырыш, акыллы, җырлаган, биегән, шигырь сөйләгән балаларны бик ярата. Әйдәгез, без дә Кыш бабай турында шигырь өйрәник әле. Шигырьне игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче шигырьне яттан сөйли).

### Кыш бабай

Кыш бабай килгән,  
Ап-ак тун кигән.  
Көтә: кем генә  
Чыгар дип өйдән.  
Чыксаң чеметә,  
Битне өшетә,  
Менә шул аның  
Бөтен эше дә.

*Б. Рәхмәт*

– Балалар, шигырьдә кем турында сөйләнә? (*Кыш бабай*). Кыш бабай нәрсә кигән? (*Ап-ак тун*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Кыш бабай кемне көтә? (*Өйдән кешеләр чыкканын көтә. Өйдән кем дә булса чыкканын көтә. Өйдән балалар чыкканын көтә*). (Балаларны активлаштыру). Балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: Көтә: кем генә чыгар дип, өйдән. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Урамга чыксаң, Кыш бабай нишли? (*Битне чеметә*). (Активлаштыру). Тагын нишли? (*Битне өшетә*). (Активлаштыру). Әйе, балалар, чыксаң – чеметә, битне өшетә. Күрәсезме, Кыш бабай балалар белән ничек итеп шаяра. Шуңа күрә туңмас өчен урамда тик торырга ярамый. Уйнарга, хәрәкәтләнергә, йөгерергә кирәк. Кыш бабай хәрәкәтчән балаларны ярата. Балалар, бу шигырьне сез яттан сөйләрсез, шуңа күрә аны истә калдырырга тырышыгыз. Мин сезгә шигырьне тагын бер кат сөйлим.

Тәрбияче шигырьне икенче кат сөйли. Шигырьне өченче кат сөйләгәндә, балалар кушылып сөйлиләр. Тәрбияче шигырьне сөйләргә тиз истә калдыра торган баланы чакыра. Шигырь сөйләгәндә балага уенчык Кыш бабайны бирә. Тагын теләгән 2-3 баланы үз янына чакырып сөйләтә, балаларның сөйләм сәнгатьлелеген бәяли.

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер без сезнең белән бер уен уйнап алабыз.

| | |
|---|---|
| Без суыктан курыкмыйбыз, | |
| Куллар белән колакларны, | |
| Борыннарны ышкыйбыз. | *Колакларын,борыннарын ышкыйлар.* |
| Кулларны чәбәклибез, | *Кул чабалар.* |
| Аякны күтәрәбез. | *Аякларын күтәрәләр.* |
| Урында сикерәбез, | *Урында сикерәләр.* |
| Аннары йөгерәбез. | *Урында йөгерәләр.* |
| Суыктан курыкмыйбыз. | *Аяк очларына басып, кулларын өскә күтәреп чәбәклиләр.* |

– Булдырдыгыз, балалар! Хәзер урамга чыксагыз да, суык сезгә куркыныч түгел.

## Тема И.ШӘЙМӨХӘММӘТОВНЫҢ «МАКТАНЧЫК БАКА» ӘСӘРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны хикәя белән таныштыру, *мактанчык* сүзен сөйләмдә активлаштыру, тәрбияче биргән сорауларга аңлап җавап бирергә күнектерү; әйләнә-тирә турындагы белемнәрен киңәйтү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, сүзлек байлыгын үстерү;



3) балаларда тыйнаклык, бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык бака, үрдәк; тылсымлы тартмачык.

### Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунакка кечкенә генә җирсу хайваны килгән. Ләкин ул сезгә күренгәнче, ни өчендер, тылсымлы тартмачык эченә кереп качкан. Нәрсә икән ул? Ул яшел төстә, чебен-черки ашарга ярата, суда йөзә, җирдә сикерә, яңгыратып кычкыра. (*Бака*). Дөрес, балалар, сез дөрес әйттегез, бу – бака. (Активлаштыру). Хәзер инде ул тартма эченнән чыгарга да әзер. Ләкин аның тагын бер шарты бар. Әйдәгез әле, ул күренгәнче, аны үз җыры белән сәламлик. (*Бака-ка, бака-ка*). (Тәрбияче тартманы ача һәм аннан баканы ала). Менә ул бака – бака-ка. Хәзер мактанчык бака турында мин сезгә хикәя укыйм. Игътибар белән тыңлагыз.

Тәрбияче хикәяне укый.

– Балалар, хикәядә нәрсә турында сөйләнә? (*Бака турында*). Бака кайда яшәгән? (Балаларның җаваплары). Әйе, балалар, бака күл буенда, камышлыклар төбендә яшәгән.(Активлаштыру). Күл буенда, камышлыклар төбендә яшәгән бака нинди булган? (Балаларның җаваплары. Тәрбиче балалардан *мактанчык бака* дигән җавап алырга тырыша). Бака ничек мактанган? (Балаларның җаваплары). Дөрес, миннән дә оста җырчы юк дип мактанган. Балалар, мактану ул - урынсызга масаю. Мактанчык бака гына түгел, мактанчык куян да, мактанчык кешеләр дә була. Баканың мактануын кайсы кош ишеткән? (*Үрдәк*). (Тәрбияче өстәлгә уенчык үрдәк куя). Үрдәккә баканың җыры ошаганмы? Дөрес, балалар, үрдәккә баканың җыры ошаган. Үрдәк баканы мактаган. Үрдәк мактавын ишеткәч, бака нәрсә эшләгән? Ул шатланган һәм тагын да ныграк мактанган. Үрдәк бакага нәрсә дигән? Әйдәгез, балалар, үрдәкнең сүзләрен бергәләп кабатлыйк

әле. «Кил әле, борыным өстенә мен әле. Колакларым катырак, җырыңны тансыкладым». (Күмәк кабатлау). Шуннан соң бака белән ни булган? (*Үрдәк баканы капкан да йоткан*). Әйе, балалар, кирәксезгә мактансаң, ахры яхшы бетми икән. Мактану - начар сыйфат. Балалар, сез мактанчык бака кебек була күрмәгез!

## Тема. Р. ВӘЛИЕВАНЫҢ «СҮЗ ТЫҢЛАУЧАН БУЛЫГЫЗ» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны Р.Вәлиеваның шигыре белән таныштыру, сорауларга төгәл җавап бирүләренә ирешү, *җиһаз* сүзен актив сүзлеккә кертү. Җиһаз атамаларын таный һәм атый белергә өйрәтү**;** кунакта үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерә башлау.

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, диалогик сөйләмен үстерү;

3) тыйнаклык, тыңлаучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** курчак, курчак йорты, курчак йорты өчен җиһаз.

### Эшчәнлек барышы.

**Тәрбияче.** Балалар, минем янга килегез әле. Тыңлагыз, мин сезгә бер булган хәл сөйлим. Мин кичә кунакта булдым. Мин барган кешеләр яңа фатир алганнар. Фатирлары зур, иркен. Балалар, безнең курчак Алсу да яңа фатир алган. (Тәрбияче курчак Алсуны һәм аның яңа йортын күрсәтә). Алсу үзенең дусларын, курчакларны, кунакка чакырырга булган. Әйдәгез, мин сезгә бер шигырь укыйм.

Сүз тыңлаучан булыгыз

Курчакларым, килегез,
Яңа йортны күрегез.
Менә бусы - ишеге,



Рәхим итеп керегез!
Шаулашмагыз, елашмагыз,
Тату гына торыгыз.
Сез бит инде дәү курчаклар,
Сүз тыңлаучан булыгыз.

*Р.Вәлиева*

– Балалар, сезгә шигырь ошадымы? (Балаларның җавабы. Активлаштыру). Алсу яңа йортны күрергә кемнәрне чакыра? (Балалар җавабы). Әйе, яңа йортны күрергә курчакларны чакыра. Айдар, кил, яңа йортның ишеген күрсәт әле. Син нәрсә күрсәтәсең? *(Ишек)*. Балалар, кунакларны каршы алганда, нәрсә дип әйтәләр? (Балаларның җаваплары). Әйе, рәхим итегез диләр. Әйдәгез, бергә кабатлыйк әле. (Күмәк кабатлаулар). Кунакта үзеңне ничек тотарга кирәк? (Балаларның җаваплары). Дөрес әйттегез. Кунакта шаулашырга, елашырга ярамый. Кунаклар тату, сүз тыңлаучан булалар. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әйдәгез, шигырьне тагын бер тапкыр тыңлагыз.

Тәрбияче шигырьне икенче кат укый. Өстәлдәге өсләре капланган җиһазларны балаларга күрсәтә.

– Балалар, әйдәгез, без сезнең белән хәзер Алсуның яңа йортына җиһазлар бүләк итик. Йортка нинди җиһазлар куярга була? (*Диван*). Әмир, кил әле, Алсуның йортына диванны кертеп куй әле. Син Алсуның йортына нәрсә бүләк иттең? (*Диван*).

Шул рәвешле балалар йортка башка җиһазлар: өстәл, урындыклар, шифоньер, кәнәфи һ.б. кертеп куялар.

**Тәрбияче.** Балалар, диван, өстәл, урындыклар, шифоньер, кәнәфи - болар барысы да йорт җиһазлары. Әйдәгез, бергә кабат-

лыйк. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, Алсуның йортын уен почмагына куйыйк. Сез бу йорт белән уйный аласыз. Булдырдыгыз.

## *Алтынчы бүлек.* КЫШ

### Тема. Һ.ТАКТАШНЫҢ «ЛӘЙЛӘ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес җавап бирүләренә ирешү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга теләк уяту; ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләр төгәллеген үстерү;

3) кышкы табигатьнең матурлыгын күрә, соклана белүләренә шартлар тудыру.

**Җиһазлар:** уенчык чана, курчак.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, миндә нинди уенчыклар бар. (Чана һәм курчак күрсәтә). Бу нәрсә? *(Чана).* Чана елның кайсы вакытында кирәк? *(Кыш көнендә*). Чана ни өчен кирәк? *(Шуу өчен).* (Активлаштыру). Дөрес, балалар, чанага утырып таудан шуып төшәләр, боз өстендә шуалар, утырып йөриләр.

- Ә бу нәрсә? *(Курчак).* Курчаның исеме ничек? *(Ләйлә).* Балалар, Ләйлә кыш көне, сезнең кебек, чанада шуарга бик ярата. Әйдәгез, аны чанасына утыртыйк. Хәзер Ләйлә турында шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз:

Ләйлә

Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак кардан киенгән.



Ләйлә чанасын өстерәп
Чыгып китте өеннән.

*Һ. Такташ*

– Балалар, менә Ләйлә турында нинди матур шигырь язылган. Сезгә шигырь ошадымы? (Балаларны активлаштыру). Шигырьдә кайсы ел вакыты турында сүз бара? *(Кыш турында).* Кыш турында икәнен каян белдегез? *( Урамнар ап-ак кар белән капланган. Урамнарга ап-ак кар яуган).* (Балаларны активлаштыру). Ләйлә нәрсә өстерәп чыгып киткән? *(Чана).*

Тәрбияче шигырьне икенче кат укый, балалар кайбер сүзләрне аның артыннан кабатлыйлар.

**Тәрбияче.** Урамнар бүген *(сөенгән),*
Ап-ак кардан *(киенгән).*
Ләйлә чанасын *(өстерәп)*
Чыгып китте *(өеннән).*

– Балалар, сез ничек уйлыйсыз, Ләйләгә чана шуу рәхәт булдымы икән? (Балаларны активлаштыру). Ләйлә урамнан кергәч, үзен ничек хис итте икән? (Җаваплар). Балалар, әйдәгез, без дә күңелләребезне күтәреп, уйнап алыйк әле.

| | |
|---|---|
| Ап-ак йомшак карны | *Алга иеләләр һәм карны үзләренә таба ике кул белән җыялар* |
| Бергәләп җыябыз. | |
| Кардан шар ясыйбыз | *Тураялар һәм әвәләү хәрәкәтен ясыйлар.* |
| Һәм алга атабыз. | *Сул аякны алга чыгарып, җиңелчә иелеп, уң кул белән шарны алга ату хәрәкәте ясыйлар.* |

– Булдырдыгыз, балалар! Менә кар белән уйнау ничек рәхәт! Күңелләр күтәрелеп китте. Әйдәгез, үзебезне хуплап, бергәләп кул чабабыз.

**Тема. Җ. ДӘРЗАМАНОВНЫҢ «АЛМАЗ» ШИГЫРЕН УКУ.**

**Бурычлар:**

1) балаларны Җ. Дәрзамановның шигыре белән таныштыру, тәрбияченең сорауларына җавап бирергә күнектерү; җыр тыңлаганда актив булырга өйрәтү;

2) аңга алуларын, игътибарны, сүзлекне, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;

3) дөрес киенергә теләк уяту, шигырьләр белән кызыксыну хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчык аю *(ул дөрес киенмәгән)*, «Алмаз» җырының аудиоязмасы *(Р. Еникеев көе, Җ. Дәрзаманов сүзләре).*

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балаларга дөрес киенмәгән уенчык аю алып керә.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, безгә нинди кунак килгән? *(Аю).* Аюга игътибар белән карагыз әле, дөрес киенгәнме ул? *(Юк)*. Аю нәрсәне дөрес кимәгән? (Активлаштыру).

Тәрбияче балаларның игътибарын аюның башлыгына, бияләйләренә, итекләренә юнәлтә.

– Балалар, мин сезгә Алмаз исемле малай турында бер шигырь укыйм.



Алмаз

Бер итеге уңга карый,
Берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч,
Кыендыр ул аякка.

Бияләй – ишле-сыңарлы,
Бүрек каплаган күзен.
Әллә малай, әллә кыз ул -
Танып та булмый үзен.

Танымаса танымаслар,
Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн
Үзе киенә менә.

*Җ. Дәрзаманов*

– Балалар, Алмаз дөрес киенгәнме? *(Юк).* Ул нәрсәне дөрес кимәгән? (Балалар әйтә алмасалар, тәрбияче итекләрне ничек кию турында сорый). Балалар, Алмаз итекләрен ничек итеп кигән? (Балаларның җавабы). Әйе, балалар, уң итеген сул аякка, сул итеген уң аякка кигән. Шуңа күрә итекләр икесе ике якка карап тора. Ә бияләйләрен ничек кигән? (Балаларның җаваплары). Дөрес, уң бияләйне сул кулга, сул бияләйне уң кулга кигән. Икенче төрле аны «ишле-сыңарлы» диләр. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, Алмаз бүреген дөрес кигәнме? *(Юк).* Әйе, Алмаз бүреген дөрес кимәгән, ул аның күзләрен каплаган. Алмазны танып буламы? *(Юк).* Алмазны танымасалар да, ул сөенә. Балалар, ул ни өчен сөенә? (Активлаштыру). Әйе, ул бит үзе киенгән, шуңа сөенгән, шатланган. Балалар, әйдәгез әле, аю да сөенсен әле, аны дөрес итеп киендерик. Ул бит үзе киенә белми. *(*Аюга киемнәрен

дөрес итеп кияргә булышалар). Менә аю матур, дөрес итеп киенде. Хәзер ул урамга да чыга ала. Балалар, аю чыгып киткәнче, әйдәгез, Алмаз турында җыр тыңлыйк әле.

Р. Еникеев көе, Җ. Дәрзаманов сүзләренә «Алмаз» җырын тыңлыйлар.

**Тәрбияче.** Сез инде зурлар, дөрес итеп киенә беләсез. Киенгәндә бер-берегезгә ярдәм итәсез, булышасыз. Шуның өчен мин сезне яратам да инде.

## Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ «САЛКЫН САФ ҺАВА» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, кышкы табигать турындагы белемнәрен тирәнәйтү, шигъри текстны истә калдырырга ярдәм итү;

2) сәнгатьле сөйләмнәрен үстерү;

3) шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** мольберт, шигырьнең эчтәлеге сурәтләнгән рәсем, күңелле бию көе (аудиоязма), кар бөртекләре.

### Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, хәзер елның нинди фасылы? *(Кыш).* Кышын көннәр җылымы, салкынмы? *(Салкын).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Ә һава нинди? (Балаларның җаваплары). Әйе, һава саф. Балалар, кышын нәрсә ява? *(Кар).* Кар нинди? *(Кар ак).* Кар катымы, әллә йомшакмы? *(Йомшак).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Йомшак кар ява». Бик яхшы! Дөрес итеп кабатладыгыз. Кар яуганда, өскә нәрсә куна? *(Кар бөртекләре).* Дөрес, кар бөртекләре өстеңә куна. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Кар бөртекләре өстеңә куна». (Күмәк кабатлау). Кар бөртекләре матурмы? *(Матур).* Кар бөртекләре салкынмы? *(Салкын).* Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк



әле: « Үзләре матур һәм салкын була». Балалар, кар яуганда урамга чыккач, битләр нишли? *(Кызара).* Дөрес, балалар, битләр кызара. Хәзер бергәләп кабатлыйк: битләр кызара. Балалар, салкын саф һава турында мин сезгә бер шигырь укыйм . Игътибар белән тыңлагыз.

Тәрбияче кышкы пейзаж сурәтләнгән рәсемне мольбертка куя.

Салкын саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Шигырьне укыганда тәрбияче шигырьнең эчтәлеге буенча хәрәкәтләр ясый. Балалар тәрбияче белән хәрәкәтләрне кабатлыйлар.

**Тәрбияче.** Балалар, мин шигырьне тагын бер кат укыйм, сез игътибар белән тыңлагыз һәм истә калдырырга тырышыгыз. Аннан соң шигырьне үзегез сөйләрсез.

Тәрбияче шигырьне тагын бер кат укый, аннан соң яхшы хәтерле баланы шигырь сөйләргә чакыра.

– Булдырдың, Алсу, шигырьне сәнгатьле итеп һәм ялгышмыйча сөйләдең.

Шул рәвешле тәрбияче тагын бер-ике баланы шигырь сөйләргә чакыра.

– Хәзер, балалар, Алсу кар бөртекләре белән биер, ә сез кул чабып торыгыз.

Тәрбияче күңелле җыр көе куя.

– Булдырдыгыз, балалар!

## *Җиденче бүлек.* ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

### Тема. 3. ТУФАЙЛОВАНЫҢ « ШОФЕР БУЛАМ» ДИГӘН ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны шигырьнең эчтәлеген белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирә белүләренә ирешү, сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;

3) шофер хезмәтенә карата кызыксынуларын үстерү, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген төшендерү.

**Җиһазлар:** тылсымлы капчык, уенчык машина, шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсем, С. Низаметдинов көе, Ф. Рәхимголыва сүзләренә «Шофер» җыры аудиоязмасы.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, минем кулымда нәрсә? *(Тылсымлы капчык).* Аның эчендә нәрсә бар икән? Капчыкта нәрсә бар икәнен белү өчен нишләргә кирәк? *(Ачып карарга)*. Бу капчыкта малайлар ярата торган уенчык яшеренгән. Айдар, кил әле, капчыкны ачмыйча гына капшап кара әле. Бу нәрсә икән? Ничек уйлыйсың? *(Машина).*

Әгәр бала әйтә алмаса, тәрбияче уенчыкның детальләрен (тәгәрмәч, кабина) атый.



– Бу нәрсә? *(Машина)*. Машинаны кем йөртә? *(Шофер)*. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

– Хәзер мин сезгә «Шофер булам» шигырен укыйм.

Мин дә, әтием шикелле,
Шофер булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт
Машинам белән уйныйм.
Тизрәк үсеп, шофер булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем.

*З.Туфайлова*

Тәрбияче балаларга шигырьнең эчтәлеге буенча рәсем карарга тәкъдим итә һәм шуның буенча сораулар бирә.

**Тәрбияче.** Малай үскәч, кем булырга уйлый? *(Шофер)*. Ул нәрсә белән уйный? *(Машина белән)*. Шофер булгач, малай нәрсә эшләргә тели? *(Балаларны утыртып йөртергә)*.

Тәрбияче шигырьне икенче кат укый.

– Балалар, мин шигырьне укыганда, сез минем арттан кабатлап барсагыз да ярый. Әйдәгез, хәзер шофер турында күңелле җыр тыңлагыз әле.

С. Низаметдинов көе, Ф. Рахимголыва сүзләренә «Шофер» җырын тыңлыйлар.

Урындыкны әйләндереп,
Утырган да башына

Фәрит: – Хәзер мин шофер, – ди, –
Бу, – ди, – минем машина.
Ту-ту, ту-ту, ту-ту, ту-ту,
Бу, – ди,- минем машина.

**Тәрбияче.** Балалар, менә шофер турында шигырь дә укыдык, җыр да тыңладык. Сезнең шофер буласыгыз киләме? Әйе, шофер һөнәре бик кирәкле һәм җаваплы. Хәзер юлда машиналар бик күп. Юл һәлакәте булмасын өчен, шоферга игътибарлы булырга, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Юлда йөрүчеләрнең һәрберсенә имин юллар телик. Барлык юлчылар да барасы җирләренә исән-сау барып, кайтасы җирләренә исән-сау кайтып җитсеннәр.

### Тема. Ә. ИСХАКНЫҢ «ГҮЗӘЛ» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү, тәрбияче сорауларына аңлы рәвештә җавап бирүләренә, җырның сүзләренә туры китереп, төгәл хәрәкәтләр ясауларына ирешү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;

3) балаларда культура-гигиена күнекмәләре формалаштыру.

**Җиһазлар:** курчак, М. Бикбова сүзләре һәм көенә «Курчагым» җырының аудиоязмасы.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче пычракка буялган курчак алып керә

**Тәрбияче.** Гүзәл, сиңа нәрсә булды? Син нишләп болай буялдың, пычрандың?



**Гүзәл.** Мин урамда уйнадым, йөгердем, аннан соң егылдым һәм минем бөтен җирем пычранды.

– Гүзәл, син тынычлан. Балалар, Гүзәл чиста булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк? (Балаларның җаваплары). Әйе, аны юындырырга кирәк. Әйдәгез, Гүзәлне юындырырга Тәнзилә апага (тәрбияче ярдәмчесенә) бирик. Ул аны юындырсын, киемнәрен алыштырсын. Ә хәзер Гүзәл турында мин сезгә бер шигырь укыйм, ә сез игътибар белән тыңлагыз.

Гүзәл

Гүзәл кайткан урамнан,
Бите-кулы буялган.
Абыйсы Фәрит әйтә:
– Юыныйк, сеңлем, әйдә!
Үрнәк ал син песидән,
Көлә күрмәсен синнән.
Ул үзе бит юына
Туктаусыз көн буена.
*Ә. Исхак*

– Балалар, шигырь ничек дип атала? («*Гүзәл*»). Гүзәл кайдан кайткан? (*Урамнан*). Гүзәлнең нәрсәсе буялган? (*Бите-кулы*). Гүзәлнең абыйсы Фәрит нәрсә дип әйтә? *(«Юыныйк, сеңлем, әйдә*!») Әйдәгез әле, бергәләп кабатлыйк: Юыныйк, сеңлем, әйдә! Фәрит нәрсәдән үрнәк алырга куша? (*Песидән*). (Балаларны активлаштыру). Балалар, ни өчен Гүзәл песидән үрнәк алырга тиеш? (Балаларның җаваплары). Әйе, балалар, песи үзен бик чиста йөртә, ул туктаусыз көн буена юына. Хәзер «Гүзәл» шигырен тагын бер тапкыр укыйм, ә сез игътибар белән тыңлагыз.

Тәрбияче шигырьне укый.

– Балалар, урамнан кергәч, кулларны, битләрне юарга кирәк. Чиста йөргән балалар авырмыйлар.

Тәрбияче чиста итеп юылган курчакны ала.

– Балалар, карагыз әле, Гүзәл нинди чиста! Аның бите-кулы юылган. Тыңлыйк әле аны, ул сезгә нәрсәдер әйтергә тели.

**Гүзәл.** Мин хәзер бик чиста. Мине Тәнзилә апа бик чиста итеп юындырды. Аңа бик зур рәхмәт. Сез минем белән уйнарга телисезме?

Тәрбияче М.Бикбова сүзләренә һәм көенә «Курчагым» җырының аудиоязмасын куя. Балалар белән җырлыйлар. Җырның сүзләренә туры китереп,хәрәкәтләр ясыйлар.

**Тәрбияче.**

| | |
|---|---|
| Әй, курчагым, курчагым, | *Кул белән* |
| Кил, бергәләп уйнарбыз. | *чакыру хәрәкәтләре ясыйлар.* |
| Битеңне, кулларыңны | *Битләрен, кулларын* |
| Чиста итеп юарбыз. | *сыпыралар.* |
| Күлмәгеңне кидереп, | *Кидерү хәрәкәтләре ясыйлар.* |
| Чәчләреңне үрәем, | *Чәчләрен сыйпыйлар.* |
| Сине һәрчак сөйкемле, | *Кулларын билләренә куеп,* |
| Матур итеп күрәем. | *әйләнәләр.* |

– Булдырдыгыз,балалар. Сез һәрвакыт чиста йөрисез. Мин сезнең барыгызны да яратам.



## *Сигезенче бүлек.* СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ
### Тема. Д. АППАКОВАНЫҢ «РӨСТӘМ» ӘСӘРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) чәчмә әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияченең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен үстерү;

3) әдәплелек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф. Самовар, өстәл, конфетлар, сумса, карбыз, алманың контурлы сурәтләре.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, сезнең кунакта булганыгыз бармы? *(Бар).* Кунакта үзеңне ничек тотарга кирәк? *(Әдәпле, тәртипле).* (Балаларны активлаштыру). Әйе, кунакка баргач, үзеңне тәртипле тотарга кирәк. Кычкырып сөйләшергә ярамый. Уенчыкларны сорап кына алырга кирәк. Өстәл артына утыргач та, ризыкларны олы кешедән рөхсәт сорап кына алалар. Балалар, хәзер мин сезгә кунакка барган Рөстәм турында бер әсәр укыйм. Тыңлагыз әле. (Тәрбияче әсәрне укый). Балалар, әсәрдәге малайның исеме ничек? *(Рөстәм).* Рөстәм кемнәрдә кунакта булган? (*Әбиләрдә*).

Тәрбияче фланелеграфка өстәлнең контурлы сурәтен, өстәлгә самоварның контурлы сурәтен куя.

**Тәрбияче.** Әби өстәлгә нинди тәмле әйберләр куйган? *(Сумса, карбыз, алма, конфетлар).*

Тәрбияче балалар атаган ризыкның контурлы сурәтләрен фланелеграфка куя бара.

**Тәрбияче.** Балалар, карагыз әле, өстәл нинди тәмле әйберләр белән тулды. Бу нәрсә? (Сумсага күрсәтә). Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. Гүзәл, бу нәрсә? *(Сумса).* Рөстәмнең әбисе сумсаны нәрсә белән пешергән? *(Ит белән пешергән).* (Балаларны активлаштыру). Балалар, өстәлдә җиләк-җимешләрдән нәрсәләр бар? *(Алма).* Алмалар нәрсә дип әйтә сыман? *(Мине ал, мине ал!).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. Чәй эчә торган тәмтомнардан нәрсәләр бар? *(Конфетлар).* Конфетлар нәрсә дип әйтәләр шикелле? *(«Кулыңны суз! Ах, тәмле без, ах тәмле!»)* Балалар, әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. Хәзер Ленар кабатласын. Булдырдыгыз, балалар, чынлап та, конфетлар: «Ах, тәмле без, ах тәмле!» – дип әйтәләр кебек.

– Өстәлдә эче кызыл, үзе баллы тагын нәрсә бар? *(Карбыз).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Карбызлар нәрсә дип әйтә кебек? *(Ал-кызыл без! Ал-кызыл! Кап авызыңа, эрербез).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Рөстәм өстәлдәге тәмтомнарны шунда ук алып ашый башлаганмы? *(Юк).* Ул нәрсә эшләгән соң? *(Ул башта әнисенә, аннары әбисенә караган).*

Балалар әйтә алмаса, тәрбияче: «Рөстәм, рөхсәт сораган кебек, башта кемгә караган? Аннары кемгә караган?»- дип, өстәмә сорау бирә ала.

– Рөстәмнең тәлинкәсенә сумсаны кем салган? *(Әбисе салган).* Әнисе Рөстәмгә нәрсә алып биргән? *(Алма).* Рөстәмнең апасы нәрсә алып биргән? *(Конфет).* Тагын нәрсә биргән? *(Бер телем карбыз).* Рөстәм кунакта үзен ничек тоткан? *(Әдәпле).* (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әйе, Рөстәм үзен бик әдәпле тоткан. Балалар, әдәпле бала нинди була ул? Ул ничек ашый? *(Ашыкмыйча гына ашый).* (Балаларны активлаштыру). Әдәпле балалар азыкны ничек чәйниләр? Авызны чапылдаталармы? *(Авызны чапылдатмыйлар).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: авызны чапылдатмыйлар. Ашъяулык чиста булсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк? *(Түкмичә, чәчмичә ашарга кирәк).*



– Дөрес, балалар, кечкенәдән үк әдәпле булырга, үзеңне кунакта дөрес итеп тотарга өйрәнергә кирәк. Юкка гына: «Кунак булсаң, тыйнак бул!»-дип әйтмиләр. Әйдәгез, хәзер бергәләп тәм-томнар белән чәй эчеп алыйк. Үзегезне кунактагы кебек әдәпле итеп тотарга тырышыгыз.

Тәрбияче балаларны өстәл артына чәй эчәргә утырта.

## Тема. «ЧӘБӘК-ЧӘБӘК ӘБКӘСЕ...» ЮАТКЫЧЫН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларның юаткычны күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белүләренә ирешү; истә калдыру максатыннан, юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан берничә тапкыр кабатларга мөмкинлек бирү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын; кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү;

3) татар халык аваз иҗаты белән кызыксыну, әниләргә, әбиләргә карата хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кәрзин *(*җиләк салу өчен*).*

### Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә бер кыз турында сөйлим. Игътибар белән тыңлагыз әле. Бу кыз бүген бик боек. Нигә боек икән ул, нигә күңелсез икән?

– Кызның әнисе җиләккә киткән. Ул әбисе белән өйдә калган. Кыз әнисен сагынган, елыйсы килгән. Әбисе аны юатырга тырышкан һәм кызга юаткыч сөйләгән:

Чәбәк-чәбәк әбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Кызыбызга бүләккә.

– Балалар, әбисе Алсуга нәрсә сөйләгән? *(Юаткыч).* Әбисе ничек чәбәк-чәбәк иткән? (Күрсәтәләр). Кызның әнкәсе кая киткән? *(Каенлыкка, җиләккә).* Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. Балалар, кызның әнисе нәрсә җыйган? *(Җиләк).* Әнисе җиләкне кемгә дип җыйган? *(Кызыбызга бүләккә).* (Индивидуаль һәм бергә кабатлаулар). Күрсәтегез әле, ул җиләкне ничек җыйган? (Җиләк җыю һәм кәрзингә салу хәрәкәтен күрсәтәләр). Җыйган җиләкләрегезне менә бу кәрзингә салыгыз.

– Балалар, әбисе кызына менә нинди матур татар халык юаткычы өйрәткән. Кыз да елаудан туктаган. Әнисе күп итеп кызга бүләккә җиләк алып кайткан. Алар бергәләп сыйланганнар. Балалар, әниләр каядыр киткәндә, еларга кирәкми. Алар сезне бик яраталар. Эшләре беткәч, әниләр һәрвакытта да тизрәк сезнең янга кайтырга ашыгалар.

### Тема. З. ТУФАЙЛОВНЫҢ «ӘНИ СҮЗЕ» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны шигырь белән таныштыру; истә калдыру максатыннан, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирүгә тарту;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, аларда уңай эмоцияләр тудыру;

3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** шигырь эчтәлеге буенча рәсем.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, һәрбер кешенең әнисе бар. Әниләр безнең иң яраткан, иң кадерле кешеләр. Сезнең дә һәрберегезнең әнисе бар. Әйдәгез, әниләрегезнең исемнәрен искә төшерегез әле.

Балалар әниләренең исемнәрен атыйлар.

– Булдырдыгыз, балалар! Әниләрегезнең исемнәре бигрәк матур икән. Тиздән әниләр бәйрәме җитә. Әйдәгез әле, әниләр



турында шигырьне игътибар белән тыңлыйк. Шигырь «Әни сүзе» дип атала.

Тәрбияче шигырьне сөйли.

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.
*З.Туфайлова*

– Балалар, бу шигырь ничек атала? («*Әни сүзе*»). Шигырьдә кем турында сүз бара? (*Әни турында*). Бала «Әни» диеп кайда язып куйган? (*Ак карга*) Нинди карга язып куйган? (*Яңа яуган ак карга*) Әйдәгез әле, бергәләп кабатлыйк әле: Яңа яуган ак карга. Карга язылган «Әни» сүзен таптарга ярыймы? (*Юк*). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле: «Таптамагыз! Һич ярамый «Әни» сүзен таптарга!» (Күмәк һәм индивидуаль кабатлаулар) Балалар, хәзер шигырьне тагын бер тапкыр тыңлагыз һәм истә калдырырга тырышыгыз. Шигырьне үзегез яттан сөйләрсез.

Тәрбияче шигырьне тагын бер тапкыр сөйли. Аннан соң хәтере яхшы булган баланы чакырып, шигырьне сөйләвен үтенә.

**Тәрбияче.** Айдар, әйдә әле, шигырьне сөйләп кара.

Ярдәм кирәк булса, тәрбияче сүзләрне әйтеп җибәрә.

– Булдырдың, Айдар! Әни турында сәнгатьле итеп сөйли алдың.

Берничә бала шигырьне сөйли.

Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар.

– Балалар, сез һәрберегез ярата беләсез. Бигрәк тә әниләрегезне яратасыз. Яратасызмы әниләрегезне? Хәзер куллардан «Ярату пирамидасы» ясыйк. Минем дә әнием бар. Мин дә аны бик яратам. Мин әнием турында бер матур сүз әйтәм: *Минем әнием ягымлы*. Өстәлгә кулымны куям. Хәзер һәрберегез әниегез турында бер матур сүз уйлагыз һәм кулыгызны минем кул өстенә куегыз.

– Күрәсезме, нинди зур пирамида барлыкка килде! Балалар, пирамида җылымы? (*Җылы*). Әйе, әниләр турында әйтелгән сүзләрдән куллар җылынды. Сез аны тоясызмы? Пирамида зур һәм биек килеп чыкты. Чөнки без әниләребезне бик нык яратабыз, алар да безне яраталар. Булдырдыгыз, балалар. (Кул чабалар).

### Тема. Г. НӘБИУЛЛИНАНЫҢ «ӘНИГӘ БУЛЫШАМ» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) балаларны Г.Нәбиуллинаның шигыре белән таныштыру, бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү;

2) аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, диалогик сөйләмнәрен, кулларының вак моторикасын үстерү;

3) әниләргә ярдәм итү теләге, тырышлык, пөхтәлек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** малай курчак; балаларга җитәрлек санда уенчык күлмәкләр һәм ботинкалар моделе; энә белән җепләр.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, безгә кунакка Әмир килде. Әмир бик тырыш, инде зур үскән. Карагыз әле аңа. Пөхтә итеп киенгән, аяк киемнәрен үзе кигән, Әмир уенчыкларын да үзе җыештыра.

Тәрбияче курчакны урындыкка утырта.



– Хәзер мин сезгә акыллы, тырыш бала турында «Әнигә булышам» дигән шигырь укыйм.

Тәрбияче шигырьне укый.

Әнигә булышам

Бик зур үстем инде мин,
Әнигә булышам.
Үз ботинкамны үзем
Кияргә тырышам.
Башка-башка эштә дә
Файдам бар әнигә.
Уйнап кайткач, пальтомны
Үзем эләм чөйгә.
Әниемнең эше күп.
Бәйли миңа оек.
Бүген бөтен уенчыкны
Үзем куйдым җыеп.
Әнием китә эшенә,
Ә мин чебеш карыйм,
Ипи турап ашатам.
Мин дә эшкә ярыйм.
*Г. Нәбиуллина*

– Балалар, шигырь ничек атала? («*Әнигә булышам*»). Бала әнисенә ничек булыша? (*Ботинкаларын үзе кия, пальтосын үзе элә, уенчыкларын үзе җыя, чебиләргә ипи ашата*). Балалар, карагыз әле Әмиргә. Менә ул пальтосын чөйгә элә. (Тәрбияче чөй кагылган такта кисәген күрсәтә). Шигырьдә дә бала пальтосын чөйгә яисә элгечкә элә. Әйтегез әле, бала пальтосын кая элә? (*Чөйгә*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Малайның әнисе нәрсә эшли? (*Оек бәйли*). Менә карагыз әле, мин дә энә-

җеп алып килдем. Җептән энәләр белән бияләйләр, оеклар, оекбашлар, шарфлар бәйләргә була. Әйтегез әле, кемнең әнисе оекбашлар бәйли? (Балаларны активлаштыру). Әниләр бәйләгән оеклар, бияләйләр бик җылы, шуңа күрә без урамга чыккач һич тә туңмыйбыз. Балалар, Әмир сезгә күлмәкләр, ботинкалар алып килгән.

Тәрбияче кемгә күлмәк, кемгә ботинкалар тарата.

– Сезгә ботинкаларның шнурларын бәйләргә, күлмәктәге сәдәфләрне төймәләргә кирәк булыр.

Балаларның ничек эшләгәннәрен тәрбияче күзәтеп тора.
Кирәк булса, ярдәм итә.

**Тәрбияче.** Менә, булдырдыгыз. Күлмәкләрнең сәдәфләрен дөрес итеп төймәләдегез, ботинкаларның бауларын да дөрес итеп бәйләдегез. Әмир сезгә рәхмәт әйтә.

## *Тугызынчы бүлек.* ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

### Тема. Л. ТОЛСТОЙНЫҢ «ӨЧ АЮ» ӘКИЯТЕН УКУ

**Бурычлар**:

1) балалар өчен зур күләмле булган әкиятне игътибар белән тыңлауларына һәм аңлауларына ирешү; сәнгатьле сөйләм аша балаларда әдәби персонажларның эш-гамәлләренә бәя бирү, үз кичерешләрен чагылдыра белү күнекмәләре формалаштыра башлау; сүзлекне активлаштыру, балаларның сәнгатьле сөйләмен үстерү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;

3) әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар**: фланелеграф, әкият персонажларының (кыз, өч аю), өйнең, урманның, өч савыт, өч кашык, өч караватның контурлы рәсемнәре; аш бүлмәсенең, йокы бүлмәсенең рәсемнәре.



**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, матур итеп утырыгыз әле, мин сезгә «Өч аю» дигән әкият укыйм.

Тәрбияче әкиятне укыганда персонажларны һәм аларның гамәлләрен, хәрәкәтләрен күрсәтә торган контурлы рәсемнәрне фланелеграфка куеп бара.

**Тәрбияче.** Балалар, әкият нәрсә турында? (*Аюлар турында*). Әкият сезгә ошадымы? (Балаларның җаваплары). Бу әкияттә кыз сезгә ошадымы? Ни өчен? (Балаларның җаваплары). Балалар, мин сезнең белән килешәм. Кыз югалып калмаган, аюларга тоттырмаган, тәрәзәдән сикереп төшкән дә, йөгергән. Менә, балалар, кыз бик җитез булган. Җитез булыр өчен, безгә иртәнге гимнастика ясарга, күп йөгерергә, уйнарга, хәрәкәтләнергә кирәк. Әйдәгез, сезнең белән аю һәм балалар булып уйнап алабыз.

Балалар белән «Аю урманында» уены уйнала.

### Тема. Л. ТОЛСТОЙНЫҢ « ӨЧ АЮ» ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) әсәрне кабаттан игътибар белән эчтәлеген аңлап тыңлауларына ирешү, башкаларның эмоциональ халәтен аңлый белергә өйрәтү;

2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;

3) әйләнә-тирәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; җиһазга карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф, өч аюның контурлы сурәте.

## Эшчәнлек барышы

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунаклар килгән. (Тәрбияче фланелеграфка өч аюның контурлы сурәтен куя). Балалар, нинди кунаклар килгән? *(Аюлар*). Аюларның исемнәрен искә төшерегез әле. (*Михаил Иванович, Настасия Петровна, Мишутка*). Алар безгә кайсы әкияттән килгәннәр? *(Өч аю)*. Ә хәзер мин сезгә «Өч аю» әкиятен яңадан сөйлим. (Тәрбияче әкият сөйли). Балалар, әйтегез әле, бу әкият нәрсә турында? (Балаларның җаваплары). Әйе, балалар, бу әкият бер кыз һәм өч аю турында. Кыз кая киткән? (*Урманга*). Урманда ул нәрсә күргән? (*Бер өй күргән*).). Өйдә нәрсәләр яши? (*Аюлар яши*). Аюларның исемнәре ничек? (Балаларның җаваплары). Әйе, балалар, иң олы аюның исеме Михаил Иванович булган. Ул - әти аю. Икенчесе - әниләре. Аның исеме Настасия Петровна икән. Балалар, ә аю баласының исеме ничек? (*Мишутка*). Аюларның өендә нинди бүлмәләр булган? (Балаларның җаваплары). Әйе, бер бүлмәдә ашханә булган. Ашханә ул ни өчен? (Җаваплар). Әйе, балалар, аюлар ашханәдә ашаганнар. Өйдә тагын нинди бүлмә булган? (Балаларның җаваплары). Дөрес, тагын йокы бүлмәсе булган. Балалар, кыз ашханәдә нинди савытлар күргән? (Балаларның җаваплары). Аш савытлары нинди зурлыкта булган? (Балаларның җаваплары). Дөрес, Михаил Ивановичның савыты бик зур, Настасия Петровнаның савыты кечерәк, Мишутканың савыты иң кечкенәсе булган.

– Балалар, кашыклар нинди зурлыкта булган? (*Зур, уртача, кечкенә*). Зур кашык кайсы аюныкы дип уйлыйсыз? (*Әти аюныкы, Михаил Ивановичныкы, зур аюныкы*). Уртача кашык кайсы аюныкы? (*Әни аюныкы, Настасия Петровнаныкы*). (Балаларны активлаштыру). Балалар, ә кечкенә кашык кайсы аюныкы? (*Мишутканыкы, кечкенә аюныкы, аю баласыныкы*).

– Балалар, өстәл янында нәрсәләр булган? (*Урындыклар).* Урындыклар нинди зурлыкта булган? (*Зур, кечерәк, кечкенә*). Зур урындык кайсы аюныкы? (Балаларның җаваплары). Кечерәк урындык кайсы аюныкы? (Җаваплар). Кечкенә урындык кайсы аюныкы? (Җаваплар). Балалар, кызга кайсы урындыкта утыру уңайлырак булган? (Җаваплар). Ни өчен ул утырган урындык ватылган? (Балаларның җаваплары).

– Дөрес, балалар, урындыкта тирбәлеп, селкенеп утырырга ярамый. Урындык - утыра торган әйбер. Йорт җиһазларын ватарга ярамый, аларны сакларга кирәк. Балалар, кыз кайсы аюның караватында йоклап киткән? (Балаларның җаваплары). Аюлар, өйләренә кайткач, нәрсә күргәннәр? (Балаларның җаваплары). Алар ни өчен кычкырганнар? (Җаваплар). Зур аю, үз савытын күргәч, нинди тавыш белән үкереп җибәргән? (*Куркыныч тавыш белән*). Ул нәрсә дип сораган? («*Минем савыттан кем ашаган?»*) Балалар, кайсыгыз зур аю кебек әйтә ала? (Балаларны активлаштыру). Настасия Петровна нинди тавыш белән кычкырып җибәргән? (*Йомшаграк тавыш белән кычкырган).* Ул нәрсә дип кычкырган? («*Минем савытымнан кем ашаган*?») Кем әни аю кебек сорый ала? (Балаларны активлаштыру). Мишутка нинди тавыш белән чинаган? *(Нечкә*). Мишутка кебек кем чинап күрсәтә ала? (Балаларны активлаштыру).

– Балалар, Михаил Иванович, урындыгына утыргач, нәрсә дип үкергән? («*Минем урындыкка кем утырган, аны урыныннан кем кузгаткан?»*) Кем Михаил Иванович кебек әйтә ала? (Балаларны активлаштыру). Настасия Петровна нәрсә дип кычкырган? (Балаларның җаваплары). Кем Настасия Петровна кебек әйтә ала? (Балаларны активлаштыру). Мишутка нәрсә дип кычкырган? (Җаваплар). Балалар, барыбыз да бергә Мишутка кебек әйтеп карыйк.

– Йокы бүлмәсендә кемне күргәннәр? *(Кызны*). Кечкенә аю, кызны күргәч, ни эшләргә теләгән? (*Тешләргә теләгән*). Балалар, аю кызны тешли алганмы? (*Юк*). Ни өчен тешли алмаган? (*Кыз качып өлгергән*). Балалар, ничек уйлыйсыз, кызга куркыныч булганмы? (*Бик куркыныч булган*). Курыкса да, ул җитез булган, аюлардан качып өлгергән.

– Аюларның өйләренә кереп, кыз дөрес эшләгәнме? Әйе, дөрес әйтәсез, кеше өенә рөхсәтсез керергә ярамый. Рөхсәтсез кеше әйберләренә кагылырга да ярамый. Балалар, әкият шуның белән тәмам. Сез бик игътибарлы булдыгыз. Сорауларга дөрес җавап бирдегез. Булдырдыгыз! (Кул чабалар).

### Тема. «ТӨЛКЕ, КУЯН ҺӘМ ӘТӘЧ»
### ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ

**Бурычлар:**

1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү; сюжетның үсеше артыннан күзәтергә, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;

3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлек, кайгыртучанлык, ярдәмчеллек, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** өстәл театры өчен персонажлар: әтәч, куян, төлке, үгез, аю, эт.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә табышмаклар әйтәм, әгәр дә сез аларның җавапларын дөрес әйтсәгез, ул җаваплар минем өстәлдә барлыкка килер.

Урманда яши,
Тавыклар урлый.
Көлтә койрыклы
Хәйләкәр (төлке).

– Дөрес, балалар, төлке. (Тәрбияче өстәлгә төлке персонажын куя). Әле безнең тагын бер герой бар. Аның турындагы



табышмакны игътибар белән тыңлагыз әле.

Урманда яши
Бу озын колак.
Кишер ярата,
Үзе бик куркак.
*(Куян)*

– Дөрес, балалар, куян. (Тәрбияче өстәлгә куян персонажын куя). Ә хәзер өченче табышмакны тыңлагыз.

Иртән иртүк тора,

– Кикрикүк-үк, – дип кычкыра.

– Бу нәрсә икән? (*Әтәч*). Бик дөрес, балалар, бу әтәч. (Тәрбияче әтәч персонажын өстәлгә куя). Балалар, хәзер төлке, куян, әтәч турында мин сезгә әкият күрсәтәм.

Өстәл театрын кулланып, тәрбияче әкиятне сөйли. Берничә урында кабатлана торган бер үк фразаларны, аваз ияртемнәрен балалардан кабатлаттыра. Тәрбияче, әкият тәмамлангач, персонажларны алып куя һәм аларның хәрәкәтләрен, тавышларын балаларга кабатларга тәкъдим итә

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар! Әкият геройлары – әтәч, төлке, куянны бик дөрес итеп күрсәтә алдыгыз. (Кул чабалар).

### Тема. «ТӨЛКЕ, КУЯН ҺӘМ ӘТӘЧ» ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ

**Бурычлар:**

1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү, сюжетның үсеше артыннан күзәтү, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирерә өйрәтү;

2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;

3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлек, кайгыртучанлык,

ярдәм итүчәнлек, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** әкият персонажларының курчаклары, балалар санынча әтәч битлекләре, бер төлке битлеге.

### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче әкият персонажларын өстәлгә куя

**Тәрбияче.** Балалар, бу геройлар безгә кайсы әкияттән килгән? (Балаларның җаваплары). Хәзер мин сезгә төлке, куян һәм әтәч турында әкиятне кабаттан сөйлим.

Тәрбияче ашыкмыйча гына, сәнгатьле итеп әкиятне сөйли.

– Балалар, төлке өен нәрсәдән салган? (*Боздан*). Ә куянның өе нәрсәдән булган? (*Кайрыдан*). Яз җиткәч, төлкенең өе нишләгән? (*Эрегән дә аккан*). Балалар, куян ни өчен елаган? (*Аны төлке өеннән куып чыгарган).* (Активлаштыру). Елап барганда аңа беренче булып нәрсә очраган? (*Эт)*. Әйе, куянга эт очраган һәм куяннан:«Һау-һау-һау, Куян, нигә елыйсың?»- дип сораган. Әйдәгез әле, бергәләп кабатлыйк. Куян аңа нәрсә дип җавап биргән? (Балаларның җаваплары).

Тәрбияче куянның сүзләрен әйтә, ә балалар аның артыннан кабатлыйлар.

– Нигә еламаска? Минем өем кайрыдан, Төлкенең өе боздан салынган иде. Төлке миннән кунып чыгарга гына рөхсәт сораган иде, соңыннан үземне куып чыгарды.

– Балалар, эт төлкене ничек итеп куган? *(Һау-һау-һау, Төлке, чык, бар, кит)*. Төлке эткә нәрсә дип җавап биргән? (*Балта кайрыйм, пычак кайрыйм, сикереп төшәрмен дә, өзгәләп ташлармын*). (Активлаштыру). Балалар, Эт куянга ярдәм итә алганмы? (Балаларның җаваплары). Әйе, Эт курыккан да чыгып киткән.

– Балалар, Куянга тагын нәрсә очраган? (Аю). Аю куяннан нәрсә дип сораган? (*Нигә елыйсың, Куян?)* Алсу, кил әле, син Куян булып аюга җавап бир әле. Булдырдың, Алсу, син дөрес итеп җавап бирдең. Балалар, Аю Куянны ничек итеп тынычландырган? (*Елама, Куян. Мин аны куып чыгарырмын.*) Аю Төлкегә нәрсә дип кычкырган? (*Төлке, бар чыгып кит!)*. Төлке Аюдан курыкканмы? (*Юк*). Төлке Аюга нәрсә дип әйткән? Кил әле, Айдар, Төлке булып җавап бир әле. (Балаларны активлаштыру). Балалар, Аю Куянга ярдәм итә алганмы? (*Юк*).

– Балалар, Аюдан соң Куянга нәрсә очраган? (*Үгез*). (Балаларга сорау бирү шул рәвешле дәвам итә). Куянга нәрсә ярдәм иткән? (*Әтәч*). Бу турыда мин сезгә тагын бер тапкыр укыйм, тыңлагыз әле. (Тәрбияче әкиятнең ахырын укый). Менә әкият ничек яхшы тәмамланган. Әтәч батыр, кыю, курку белмәс. Ул кечкенә генә булса да, Төлкене Куянның өеннән куып чыгара алган. Хәзер без сезнең белән уйнап алабыз. Сез әтәчләр булырсыз, ә мин – төлке.

Тәрбияче балаларга әтәч битлекләре тарата.
Әтәчләр ярма «чүплиләр», чирәмдә уйныйлар. «Төлке» дигәч, барлык әтәчләр дә «өйләренә» качалар - урындыкларга утыралар.

– Булдырдыгыз! Төлке бер генә әтәчне дә тота алмады.

## *Унынчы бүлек.* ЯЗ

### Тема. Д. ГАРИФУЛЛИННЫҢ « ТАВЫКЛАР ҺӘМ ТАҺИР» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәр белән таныштыру; йорт кошлары турындагы белемнәрен тирәнәйтү; сорауларга аңлап, дөрес җавап бирүләренә ирешү; аваз ияртемнәре әйтелешен, *бер* һәм *күп*

төшенчәләрен ныгыту;

2) балаларның аңга алуларын, күзаллауларын, игътибарын, кул хәрәкәтләрен, иҗади сәләтләрен үстерү; фантазияләрен баету;

3) балаларда йорт кошларына карата кайгыртучанлык, үзләре башкарган эшкә шатлана белү хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** шигырь эчтәлеге буенча рәсем, балалар санынча кечкенә ак шарлар яки әстерхан чикләвекләре, алтын төсендәге фольга кисәкләре, кәрзин.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, ә сез аның нинди йорт кошы турында икәнен белергә тырышыгыз:

Чирәм өстендә йөри,
– Кыт-кыт-кыт,-диеп җырлый.
– Яшел чирәм тәмле, – диеп,
Ул чебешләрен сыйлый.

– Балалар, бу нәрсә? (*Тавык)*. Әйе, бу тавык. Тавык безгә бер рәсем җибәргән. Әйдәгез, карыйк әле. (Тәрбияче чирәм өстендә йөгереп йөрүче тавыклар, аларны ашатучы малай сурәтләнгән рәсем күрсәтә). Балалар, рәсемне игътибар белән карагыз әле. Монда нәрсә сурәтләнгән? (*Тавыклар*). Тавыклар нишлиләр? (*Җим чүплиләр*). Тавыкларга кем җим бирә? (*Малай*). Әйе, балалар, ә аның исеме Таһир. Хәзер тавыклар һәм Таһир турында бер шигырь тыңлагыз.

Тавыклар һәм Таһир

Тавыклар йөри:
– Кыт-кыт та кыт-кыт!
Син, Таһир, безнең
Тамакны тук тот!
Таһир җим бирә:
Сүзсез дә аңлый -



Алар бит җимсез
Бер күкәй салмый.
*Д. Гарифуллин*

– Балалар, шигырьдә нәрсә турында сөйләнә? (*Тавыклар турында*). Тавыкларга кем җим бирә? (*Таһир җим бирә*). Әйдәгез, балалар, бергәләп кабатлагыз әле: Таһир җим бирә. Җим ашагач, тавыклар нәрсә салалар? (*Күкәй*). Әйе, балалар, тавыклар ач килеш бер күкәй дә салмыйлар. Тамаклары тук булса, тавыклар җырлыйлар. Ничек җырлыйлар алар? (*Кыт-кыт, кыт-кыт)*.

Тәрбияче шигырьне икенче кат укыганда, балалар кайбер сүзләрне аның белән бергә кабатлыйлар

**Тәрбияче.** Балалар, ә сезгә тавыклар һәм Таһир турындагы шигырь ошадымы? (Балаларның җаваплары). Бигрәк тә сезгә нәрсә ошады? (Индивидуаль җаваплар). Балалар, күрдегезме, Таһир ничек акыллы, кайгыртучан малай. Ул тавыкларны ярата, аларга җим ашата. Сез дә Таһир кебек булырга тырышыгыз. Авылга кайткач, тавыкларны рәнҗетмәгез! Балалар, әйдәгез, бармаклар белән уйнап алыйк әле. Бармаклар ярдәмендә тавык ясыйк.

Ике кулның да учлары, горизонталь итеп, бер-берсенә каратып куела. Баш һәм имән бармак бер-берсе белән тоташып, «күз» ясыйлар. Калган бармаклар ярым бөгелеп, берсе өстенә берсе ятарлык итеп терәп куела.

**Тәрбияче.** Балалар, әйдәгез, тавык салган йомыркалардан алтын йомыркалар ясыйк әле.

*Балаларга кечкенә ак шарлар яки әстерхан чикләвекләре һәм алтын төсендәге фольга таратыла.*

– Балалар, шарларны фольгага төрегез. Күрәсезме, нинди матур «алтын» йомыркалар килеп чыкты. Булдырдыгыз! Кәрзиндә ничә йомырка бар? (*Берәү дә юк*). Ә хәзер Алсу үзенең йомыркасын кәрзингә сала. Алсу, кәрзингә ничә йомырка салдың? (*Бер*). Әйдәгез, йомыркаларны кәрзиннәргә салыйк.

Шулай итеп, башка балалар да йомыркаларын кәрзингә салалар. Барысын да салып бетергәч, тәрбияче балаларга мөрәҗәгать итә.

**Тәрбияче.** Кәрзиндә ничә йомырка булды? (*Күп*). Балалар, бүген сез бик тырышып эшләдегез. Мин сездән канәгать. Исәнсау булыгыз!

### Тема. Р. БАТУЛЛАНЫҢ « ЕЛАК ӘТӘЧ» ӘСӘРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүләренә ирешү; төрле орлыкларны (*бодай, дөге*) аера белергә өйрәтү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, кул чукларының вак мускулларын үстерү; яңа сүзләрне сөйләмдә активлаштыру;

3) тешләрне саклау, алар турында кайгырту кирәклеген аңлауларына ирешү; культура-гигиена кагыйдәләре формалаштыру.

**Җиһазлар:** томшыгы бәйләнгән уенчык әтәч; бодай, дөге салынган савыт һәм һәр балага икешәр тәлинкә (берсенә бодай һәм дөге бөртекләре салынган, ә икенчесе аларны аерып салу өчен)

#### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче башын да кертеп томшыгын бәйләгән уенчык әтәч алып керә

**Тәрбияче.** Балалар, безгә бүген кунак килгән. Нинди кунак килгән? (*Әтәч*). Бүген әтәчнең бер дә кәефе юк. Ул башын,



томшыгын бәйләп куйган. Мескен әтәчкә нәрсә булды икән? Әйдәгез, балалар, сорыйк әле. Әтәч, нәрсә булды сиңа? Әллә елыйсың да инде? (Тәрбияче әтәчне үзенә якын китерә). Балалар, әтәчнең теше авырта, шуңа елый икән. Әйдәгез, әтәчне юатыйк әле.

Тәрбияче балаларга якын килә, әтәчне сыйпарга, яратырга, юату сүзләре әйтергә куша.

– Балалар, әтәч бераз тынычланды. Ул утырып торсын, ә мин сезгә елак әтәч турында әкият сөйлим.

Тәрбияче « Елак әтәч»әкиятен сөйли.

– Балалар, әкияттә нәрсә турында сүз бара? (*Әтәч турында*). Нинди әтәч турында сүз бара? (*Елак әтәч турында*). Әтәч ни өчен елаган? (*Аның тешләре коелып беткән*). Әтәчнең тешләре ни өчен коелган? (*Конфет, шоколад күп ашаган*). Әтәчтән нәрсәләр көлгән? (*Тавыклар көлгән*). Әйе, балалар, әтәчтән тавыклар көлгәннәр. Алар әтәч турында нәрсә чыгарганнар? (*Җыр чыгарганнар*). Әйдәгез, ул җырны бергәләп кабатлыйк әле.

Тәрбияче җырлый, балалар, булдыра алганча, аның артыннан кабатлыйлар.

Елак, елак, елтын колак
Кара таяк, карт әтәч.
Гарьлек, хурлык,
Бер түбәтәй орлык.

–Балалар, әтәч хәленә калмас өчен, нәрсә эшләргә кирәк? (*Конфет, шоколад күп ашарга ярамый)*. Ни өчен конфет күп ашарга ярамый? (*Теш авырта, йоклап булмый, тешсез каласың*). Тагын нишләргә

кирәк? (*Тешләрне чистартырга*). Әйе, балалар, тешләр таза булсын өчен тешләрне чистартып торырга кирәк. Сез тешләрегезне чистартасызмы соң? (Балаларның җаваплары). Менә әтәчнең дә кәефе күтәрелде. Хәзер инде аның ашыйсы да килгәндер. Ул нәрсә ярата? (*Бодай бөртекләре*). Менә бу савытта бодай бөртекләре бар. Ләкин алар дөге ярмалары белән кушылган. Әйдәгез, бодай бөртекләрен дөге ярмасыннан аерып, әтәчкә бирик әле.

Тәрбияче һәм бала алдына тәлинкәгә салып бодай һәм дөге бирә. Балалар бодай бөртекләрен аерып алалар һәм буш савытка салалар

**Тәрбияче.** Балалар, булдырдыгыз! Менә күрәсезме, әтәчкә никадәр күп бодай әзерләдегез. Әтәч рәхәтләнеп ашар һәм тешләре дә авыртмас. Балалар, сезгә дә тешләрегезне карарга, иртә-кич чистартырга, сакларга кирәк. Баллы әйберләр күп ашарга ярамый, шул вакытта тешләрегез матур һәм сәламәт булыр. Әйдәгез, тешләрегезне күрсәтеп, матур итеп елмаегыз әле. Булдырдыгыз! (Бергәләп кул чабалар)

## Тема. Б. РӘХМӘТНЕҢ «ЯЗ» ШИГЫРЕН ЯТЛАУ

**Бурычлар**:

1) балаларны Б. Рәхмәтнең «Яз» шигырен укып таныштыру, истә калдырырга ярдәм итү; эчтәлегенә туры китереп, сорауларга җавап бирергә өйрәтү, яз турында белемнәрен баету;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, сөйләмнәренең сәнгатьлелеген үстерү;

3) шигырьдә сурәтләнгән язгы табигатькә карата кызыксыну, соклану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** сыерчык рәсеме, күчмә кошларның туган якка кайтып килүе сурәтләнгән рәсем; кош битлекләре.



### Эшчәнлек барышы

Тәрбияче балаларны тәрәзә янына чакыра.

– Балалар, карагыз әле урамга, хәзер елның кайсы вакыты? (*Яз*). Яз көне табигатьтә нинди үзгәрешләр була? (*Тамчы тама, кояш җирне җылыта, кар эри, җылы яктан кошлар кайта*). (Балаларны активлаштыру). Балалар, әйе, язын безгә сыерчыклар кайта. Карагыз әле бу рәсемгә. (Тәрбияче сыерчык сурәтләнгән рәсем күрсәтә). Балалар, бу нинди кош? (*Сыерчык*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Сыерчыклар гына түгел, башка кошлар да җылы яктан кайталар: тургайлар, кара каргалар. (Тәрбияче кошларның рәсемен күрсәтә). Кошлар туган якка кайтканга сөенәләр, гөрләшәләр, сайрашалар. Әйдәгез, шул турында мин сезгә шигырь укыйм. Шигырь «Яз» дип атала.

Яз килә! Яз килә!
Сыерчыклар килә,
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.
*Б. Рәхмәт*

– Балалар, шигырь ничек дип атала? *(«Яз»).* Шигырьдә нинди ел вакыты турында сүз бара? (*Яз турында*). Язын безнең якларга нинди кошлар кайта? (*Сыерчыклар, тургайлар*). Балалар, нигә аларны җырчы кошлар дип атыйлар? (Балаларның җаваплары). Матур итеп сайраша торган кошларны җырчы кошлар дип атыйлар. Матур сайрый торган кошларны матур җырлаучы кешеләр кебек җырчылар дип атый. Шигырьне мин тагын бер тапкыр укыйм, ә сез истә калдырырга тырышыгыз. Соңынан үзегез сөйләп күрсәтерсез.

Тәрбияче шигырьне икенче тапкыр укый. Аннан соң хәтере яхшы булган 2-3 баланы чакырып, шигырьне сөйләргә тәкъдим итә, яисә балалар тәрбияче белән бергә сөйлиләр.

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар. Матур итеп шигырьне сөйләдегез. (Тәрбияче балаларның шигырь сөйләүләрен бәяли). Хәзер без кошлар булып уйнарбыз.

Тәрбияче балаларга кош битлекләре тарата.

– Сез кулларыгызны җилпеп, бүлмә буйлап кошлар кебек очарсыз (йөгерерсез). Менә нинди җитез кошлар! Мин бубенга суккач, кошлар чүгәлиләр һәм бармаклары белән идәнгә шакыйлар (кошлар ярма чүплиләр). Менә шулай. Кошлар тагын очып китәләр. Хәзер кыңгырау челтери, «кошлар» чүгәлиләр, кулларын артка җибәрәләр. Алар шулай итеп ял итәләр. Булдырдыгыз.

Уен берничә тапкыр кабатлана.

## Тема Х.ВАХИТНЫҢ «УҢГАН СЫЕРЧЫК» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларына шигырь сүзләре белән җавап бирә белүләрен ныгыту; музыка астында түгәрәктә бер-берсенә комачауламый йөри белүләрен формалаштыру; кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;

3) балаларда туган якка мәхәббәт, җылы яктан кайткан кошларга карата кызыксыну, мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф; чыпчык, карга, күгәрчен, сыерчыкның контурлы сурәтләре; сыерчык битлеге; «Кошлар килде» җырының (Г. Латыйпов сүзләре, Ш. Мәҗитов көе) аудиоязмасы.



**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче.** Балалар, без инде урамда кошларның күп булуына игътибар иттек. Җылы яклардан безгә кошлар кайталар. Алар кояшлы көнгә, туган якларына кайтуларына сөенеп, матур итеп сайрыйлар. Без сезнең белән нинди кошларны күзәткән идек? (Балаларның җаваплары).

Тәрбияче балалар әйткән кошларның контурлы сурәтләрен фланелеграфка куя бара.

**Тәрбияче.** Бик яхшы, балалар! Ә хәзер мин сезгә бу кошлар турында түгел, ә матур җырлый торган кош турында шигырь сөйлим. (Тәрбияче фланелеграфка сыерчыкның сурәтен куя). Балалар, бу кош сыерчык дип атала. Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Шигырь «Уңган сыерчык» дип атала, игътибар белән тыңлагыз.

### Уңган сыерчык

Ак буяулы бер оя бар
Бакчада зур агачта,
Очып килә шул ояга
Сыерчык яз булгач та.
Шунда тора, шунда йоклый,
Шунда бала үстерә,
Матур итеп сузып сайрый
Басып оя өстенә.

*Х.Вахит*

– Балалар, сезгә шигырь ошадымы? (Балаларның җаваплары). Шигырь ничек атала? (Балаларның җаваплары). Сыерчыкның оясы кайда урнашкан? (*Бакчада зур агачта*). (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Сыерчык бу ояга кайчан очып килә?

(*Яз булгач*). Балалар, оясында сыерчык нишли? (*Шунда тора, шунда йоклый, шунда бала үстерә*). Тагын нәрсә эшли? (*Матур итеп сузып сайрый*). Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле. Ә хәзер шигырьне тагын бер кат укыйм.

Тәрбияче шигырьне икенче кат укыганда, балаларның аерым фразаларны кабатлауларын сорый.

**Тәрбияче.** Ә хәзер без сезнең белән әйлән-бәйлән уены уйнап алырбыз. (Тәрбияче бер балага сыерчык битлеге киертә һәм уртага бастыра). Балалар, әйдәгез кул тотышып түгәрәккә басыгыз.

«Кошлар килде» җырының (Г.Латыйпов сүзләре, Ш.Мәҗитов көе) аудиоязмасын куя.

| | |
|---|---|
| Кояш кыздыра, | |
| Пар күтәрелә | *Балалар җырлап әйләнәләр.* |
| Күңел шатлана | |
| Язның ямена. | |
| Кошлар да килә | |
| Ерак – ерактан, | *Урында басып* |
| Яз аларны да | *хәрәкәтләр ясыйлар.* |
| Иртә уяткан. | |
| Сыерчык куна | *Уң куллары белән* |
| Оя башына. | «*сыерчыкка*» *күрсәтәләр.* |
| Сайрап җибәрә, | *«Сыерчык» җырлый, балалар* |
| Басып каршына. | *түгәрәктә әйләнәләр.* |
| – Сагындым, – ди ул | |
| Туган илемне, | |
| Канат үстергән | |
| Изге җиремне. | |

– Булдырдыгыз, балалар! Сыерчыклар туган якка кайткан-



нарына сөенәләр. Чөнки туган җир бик кадерле. Сез дә туган җирне яратыгыз!

## *Унберенче бүлек.* ҖӘЙ.
### Тема. «ТИЛГӘН» ЭНДӘШЕН УКУ

**Бурычлар:**

1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белүләренә ирешү; шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзлекләрен баету, шигырь сүзләрен истә калдыруларына ирешү; кошлар (тилгән) турындагы белемнәрен тирәнәйтү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, конкрет–образлы фикерләвен үстерү;

3) балаларның шигырьне дөрес интонация белән сөйләүләренә ирешү**.**

**Җиһазлар:** тилгән рәсеме, балалар санынча уенчык чебиләр салынган тартма, тавык битлеге, уенчык тавык.

**Эшчәнлек барышы.**

Ишек шакыйлар. Тәрбияче ишекне ачып, тылсымлы тартма алып керә.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? (Тартманы күрсәтә). *(Тылсымлы тартма).* Тартма эчендә нәрсәдер бар. Ачмыйча гына тартма эчендә нәрсә барлыгын белеп буламы? *(Юк).* Тартма эчендә нәрсә барлыгын беләсегез киләме*? (Әйе).* Мин сезгә табышмак әйтәм. Табышмакка җавап тапсагыз, тартма эчендә нәрсә бар икәнен бик тиз белерсез.

Йомры, йомшак,
Сары йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.
*(Чеби*).

– Бу нәрсә, балалар? *(Чеби).* Димәк, тартма эчендә нәрсәләр бар? (*Чебиләр)*. Чынлап та чебиләрме икән, әйдәгез, тартманы ачып карыйк әле.

Тартманы ачалар. Тәрбияче тартма эчендәге чебиләрне балаларга күрсәтә.

– Чебиләр күпме? *(Күп).* Чебиләр нинди төстә? *(Сары).* Чебиләр зурмы, әллә кечкенәме? *(Кечкенә).* Чебиләрне бер кош куркыткан, шуңа күрә алар тартма эченә качканнар. Сез ул кошның исемен беләсезме? *(Тилгән).* (Белмәсәләр, тәрбияче үзе әйтеп бирә). Менә ул тилгән! (Рәсем күрсәтә). Хәзер тилгән турында шигырь укырбыз. Игътибар белән тыңлагыз. (Тәрбияче эндәшне укый).

Тилгән, тилгән!
Чеби урларга килгән.
Бер аягы камырдан,
Бер аягы тимердән.
Көш, карак, көш карак,
Торабыз һәрчак карап.

– Балалар, тилгән ни өчен килгән? (*Чеби урларга килгән*). (Балалар әйтә алмасалар, тәрбияче үзе әйтә). Урларга килгән тилгәнгә карак дип әйтәләр. Бергәләп кабатлагыз әле: тилгән – карак. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Әйдәгез, чебиләрне коткарыйк. Карак тилгәнне куабыз: көш-ш-ш, карак, көш-ш-ш, карак. (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар). Балалар, тилгәнне куып җибәрдек. Әйдәгез, хәзер чебиләр белән уйнап алабыз.

Һәр бала тартмадан уенчык чеби ала. Тәрбияче тавык битлеге кия.

– Балалар, мин тавык булам, ә сез чебиләр буласыз. Мин



чеп-чеп дип сезне чакыргач, сез минем яныма җыелыгыз. Менә нинди матур минем сары чебиләрем! Мин аларның берсен дә тилгән-каракка бирмим. Булдырдыгыз, балалар. Менә монда тавык чирәм ашый, чебиләрне дә аның янына җибәрегез. Без сезнең белән бүген нинди матур эндәш укыдык. Ул нәрсә турында булды? *(Тилгән һәм чебиләр турында*). Сез тилгән-каракны ничек итеп кудыгыз? *(Көш-ш-ш, карак, көш-ш-ш, карак!)*

– Булдырдыгыз, балалар! Чебиләрне тилгән-карактан коткардыгыз. Рәхмәт сезгә!

## Тема. АЮ БЕЛӘН ХАТЫН ӘКИЯТЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирү осталыгын камилләштерү, сүзлекне киңәйтү, активлаштыру. [З] авазын ачык әйтүдә күнектерү;

2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, фикерләүләрен, чикләнгән пространствода йөгерә белүләрен үстерү;

3) халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белүчәнлек тәрбияләү.

**Җиһазлар:** бал кортлары, аю битлекләре; аягы бәйләнгән уенчык аю; урак рәсеме.

### Эшчәнлек барышы.

Ишек шакыйлар. Тәрбияче ишекне ачып, уенчык аю алып керә.

**Тәрбияче.** Балалар, бездә бүген кунак бар. Нинди кунак? Бу нәрсә? *(Аю).* Балалар, аю ни өчендер күңелсезләнгән, борчылган. Ни өчен икән? *(Аягы авырткан. Аягы бәйләнгән).* Әйе, балалар, аю аягын бәйләгән. Ни өчен бәйләгән икән? Хәзер шул турыда әкият тыңлагыз. Аю, син утырып тор. (Аюны утырта. Тәрбияче әкиятне укый).

– Балалар, әкият геройларын атагыз әле. *(Хатын, аю).* Хатын кая барган? *(Урак урырга).*

Балалар әйтә алмасалар,тәрбияче урак яки урак рәсеме күрсәтә.

– Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: урак. (Күмәк кабатлаулар). Балалар, урак белән элек бодай урганнар.(Тәрбияче урак уру хәрәкәте күрсәтә). Хатын янына нәрсә килгән? *(Аю)*. Балалар, ничә аю килгән? *(Бер).* Аюның аягына нәрсә булган? *(Шырпы кадалган)*. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: шырпы кадалган. Аю аягын кемгә күрсәткән? *(Хатынга)*. Хатын аюга ярдәм иткәнме? *(Әйе).* Ничек итеп ярдәм иткән? *(Шырпысын алган)*. Хатын дөрес эшләгәнме? *(Әйе)*. Ни өчен шулай уйлыйсыз? *(Ярдәм иткән)*. Аю ни өчен хатынга бал китереп биргән? *(Хатын аюга яхшылык эшләгән. Ярдәм иткән. Шырпысын алган)*. Дөрес, балалар, хатын яхшы күңелле, ярдәмчел булган. Аю моны аңлаган. Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирәләр. Аюның да аягы төзәлгән. Ул бәйләгән аягын чишәргә куша. Ул бал кортларын, алар белән уйнарга ярата. Сезнең белән дә уйныйсы килә. Әйдәгез, сез бал кортлары булырсыз. (Балаларга бал кортлары битлекләре кидерә). Балалар, Марат аю булсын. (Тәрбияче Маратка аю битлеге кидерә). Аю өнендә йоклый, ял итә, арыган. Ә бал кортлары бал җыялар, безелдиләр: без-без-без. (Балаларны активлаштыру). Аю уянгач, бал кортлары умарта оясына качалар (урындыкларга утыралар). Бал кортлары очалар, без- без киләләр. Бал кортлары җитезләр, уңганнар. Шатланышып очалар, бал җыялар, тырышалар. Менә аю уянды. Бал кортлары умарта оясына качалар. Аю бер генә бал кортын да тота алмады. Булдырдыгыз! (Кул чабалар).



## Тема. Җ. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ « КИКРИКҮК» ШИГЫРЕН УКУ.

**Бурычлар:**

1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; тема буенча сүзлекләрен баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатларга һәм аваз ияртемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү;

2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен, бармак хәрәкәтләрен үстерү; вакыт буенча (иртәкич) ориентлашырга өйрәтә башлау;

3) балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлар:** кычкыра торган әтәч уенчыгы, казлар, үрдәкләр, тавыклар, әтәч төшерелгән рәсем.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, минем кулымда нәрсә бар? *(Тылсымлы капчык)*. Тылсымлы капчык эченә бер уенчык яшерелгән. Нәрсә икән ул? Карамыйча әйтеп буламы? *(Юк)*. Капчыкта нинди уенчык яшерелгәнен белү өчен нәрсә эшләргә кирәк? *(Ачып карарга кирәк)*. Алсу, кил әле, капчыкка кулыңны тыгып кара әле, капчыкта нәрсә яшеренгәнен бәлки әйтә алырсың. (Алсу әйтә алмаса, тәрбияче әтәч турында табышмак әйтә). Ул - йорт кошы, кызыл кикрикле, канатлы, иртән иртүк тора, барысын да уята. Нәрсә бу? *(Әтәч).* Бик дөрес. Менә нинди матур әтәч яшеренгән икән тылсымлы капчык эченә. (Тәрбияче капчык эченнән әтәчне алгач, аны кычкырта). Ничек кычкыра? *(Кикрикүк)*. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. (Активлаштыру). Балалар, мин сезгә хәзер әтәч турында шигырь укыйм. Игътибар белән тыңлагыз!

Кикрикүк

Күктә сүнде йолдызлар,
Уянды үрдәк – казлар.
Торсын малайлар, кызлар!
Кик-ри-кү – үк!
Кик-ри-кү – үк!
*Җ. Тәрҗеманов*

Тәрбияче үрдәк – казлар, тавыклар, әтәч сурәтләнгән рәсем күрсәтә һәм балаларга сораулар бирә:

**Тәрбияче.** Балалар, шигырьдә тәүлекнең кайсы өлеше турында сүз бара? *(Иртә).* (Балаларны активлаштыру). (Әгәр дә балалар әйтә алмасалар, тәрбияче иртәме – кичме, әллә көн яки төн турындамы дип сорый). Күктә нәрсәләр сүнде? *(Йолдызлар).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз: күктә сүнде йолдызлар. (Активлаштыру). Нәрсәләр уянган? *(Үрдәкләр, казлар).* Иртән кайсы йорт кошы беренче булып кычкыра? *(Әтәч).* Әтәч малайларга, кызларга нәрсә ди? *(Торсын малайлар, кызлар).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле. *(Торсын малайлар, кызлар! Кикри- күк, кикри- күк).* (Активлаштыру). Балалар, булдырдыгыз! Сорауларга бик матур итеп җавап бирдегез. Хәзер, әйдәгез, бармаклар белән уйнап алыйк. Бармаклар ярдәмендә әтәч ясап күрсәтегез әле. Сез инде аны беләсез. Исегезгә генә төшерергә кирәк. Менә шулай. Балалар, мин шигырьне икенче кат укыйм. Сез дә минем белән кабатлагыз.

Күктә сүнде *(йолдызлар)*,
Уянды *(үрдәк – казлар).*
Торсын (*малайлар, кызлар)*!
*(Кик-ри-кү – үк)!*
*(Кик-ри-кү – үк)!*



Булдырдыгыз! (Кул чабалар). Иртәләрегез һәрвакыт якты һәм матур булсын!

### Тема. М. МАЗУНОВНЫҢ «КӘҖӘ» ШИГЫРЕН УКУ

**Бурычлар:**
1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирергә, аваз иялтемен дөрес әйтергә өйрәтү;
2) балаларның аңга алуларнын, игътибарын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;
3) йорт хайваннары белән кызыксыну, алар турында кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Җиһазлар:** фланелеграф, кәҗә белән кәбестәнең контурлы сурәтләре.

**Эшчәнлек барышы**

Тәрбияче фланелеграфка кәбестәнең контурлы сурәтен куя.

**Тәрбияче.** Балалар, бу нәрсә? *(Кәбестә).* (Балаларны активлаштыру). Балалар, исегезгә төшерегез әле, кәбестәне кайсы хайван яратып ашый? *(Кәҗә).* (Балаларны активлаштыру). (Тәрбияче кәҗәнең контурлы сурәтен фланелеграфка кәбестә янына куя). Балалар, кәҗә нәрсә ярата? *(Кәҗә кәбестә ярата).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Кәҗә кәбестә ярата.» Булдырдыгыз, балалар. Хәзер кәҗә турында шигырь тыңлагыз.

Кәҗә

Кәҗә безгә йон бирә,
Кәҗә безгә сөт бирә.
Тик шунысын яратмыйм –
Җәен бакчага керә.
*М.Мазунов*

– Балалар, шигырьдә нинди хайван турында сүз бара? *(Кәҗә турында).* (Балаларны активлаштыру). Кәҗә безгә нәрсә бирә? *(Йон бирә).* Әйе, кәҗә безгә йон бирә. Балалар, бергәләп кабатлагыз әле: «Кәҗә безгә йон бирә.» Булдырдыгыз, балалар! Менә ул йон. (Тәрбияче йон күрсәтә). Кәҗә безгә тагын нәрсә бирә? *(Сөт бирә).* Әйе, кәҗә безгә сөт бирә. Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Кәҗә безгә сөт бирә.» Бик яхшы, балалар. Кәҗә – файдалы хайван. Аны рәнҗетергә ярамый. Аны яратырга, ашатырга кирәк. Сез инде хәзер кәҗәнең нәрсә ашаганын беләсез. Балалар, кәҗәнең бер начар гадәте бар. Ул бакчага керә, түтәлдәге кәбестәләрне ашый, бакчаны таптый. Балалар, кәҗәнең нинди начар гадәте бар? *(Бакчага керә).* Әйдәгез, бергәләп кабатлагыз әле: «Кәҗә җәен бакчага керә.» (Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар).

Тәрбияче шигырьне икенче кат укый.

– Балалар, сезгә шигырь ошадымы? Әйдәгез, кулларыбыз белән кәҗә ясыйк әле. Уң кулыгызны күрсәтегез. Бик яхшы. Уң кулның уч төбе аска карый. Имән һәм чәнти бармаклар алга сузыла. Урта һәм атсыз бармак уч төбенә бөкләнә, ә баш бармак алар өстенә куела.

Мөгезе бар кәҗәнең,
Сөзә күрмәсен тагын.

– Кәҗә ничек кычкыра әле? *(Мэ-э-э).* Бик яхшы, балалар! Булдырдыгыз!



# Кушымта

## ШИГЫРЬЛӘР

### Беренче рәхмәт

Алсу хәзер зур кыз инде –
Аңа өч тулган.
Алсу бүген абыйсының
Яулыгын юган.

Сабынлаган да яулыкны
Чиләккә тыгып,
Чайкаган да элеп куйган
Тормыйча сыгып.

Шатлыктан нәни Алсуның
Күзләре яна:
Рәхмәт әйткән моның өчен
Абыйсы аңа.

Мөмкин түгел шатланмаска:
Бит шундый рәхәт
Чын күңелдән эшләп алган
Беренче рәхмәт.

*Әхмәт Исхак*

### Ләлә чана шуа

Ләлә чана шуа,
Шуа, шуа, шуа,
Егылып чанасыннан
Төшеп кала шунда.

Шуып китә чана
Тау астына таба.
Йөгереп төшеп Ләлә,
Эләктереп ала.

Чана тауга менми,
«Әйдә, тартып мен», – ди.
Ләлә: «Менә кызык!
Ничек тартыйм мин?» – ди.

Тауга таба, Ләлә,
Тартып булмый мәллә?
Шуа белгәч, өйрән
Тартып менәргә дә.

*Бари Рәхмәт*

## Кыш бабай

Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай;
Сакал –мыек ап-актан,
Килгән безгәерактан.

Бүләкләр алып килгән,
Бүреген кыңгыр кигән.
Әйлән-бәйлән уйната,
Биетә һәм җырлата.

*Әхмәт Рәшит*

## Тышта яз

Тышта яз әле
Яңа башлана:
Тамчылар тып-тып
Түбәдән тама.

*Әхмәт Ерикәй*

## Уңган сыерчык

Ак буяулы бер оя бар
Бакчада зур агачта,
Очып килә шул ояга
Сыерчык яз булгач та.

Шунда тора, шунда йоклый,
Шунда бала үстерә,
Матур итеп сузып сайрый
Басып оя өстенә.

*Хәй Вахит*



## Минем бүләк

Сигезенче март –
Әни бәйрәме.
Бүләк итәрмен
Чәчәк бәйләме.

Ничек табарга,
Кайда чәчәк бар?
Кая карама –
Каплаган ак кар.

Әнигә шигырь
Бирдем бүләккә.
«Гомергә, - ди ул, -
Калыр йөрәктә».

*Заһирә Гомәрова*

## Куянкай

Әй, куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.

Ике колагы
Озынкай гына.
Аягы җиңел –
Мамыктай гына.

*Нәкый Исәнбәт*

## Түз инде

Куянымның бер колагын
Белмим, кайсы өзгәндер.
Бик тә авырткандыр инде.
Белмим, ничек түзгәндер

Түзүен дә түзгәндер ул,
Инде менә моннан соң
Мин сөйләгән шигырьләрне
Ничек итеп тыңлар соң?

Әни эштән кайтсын инде,
Түз, куяным, түз генә,
Әниемнән яңа колак
Тектерермен үзеңә!

*Рафис Корбан*

## Чишмә

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

*Әхмәт Исхак*

## Минем бакчам

Иркен һәм матур да
Безнең Туган илебез.
Урманга бай, суга бай
Гөлбакчалы җиребез.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Ботка

Газлы зәп-зәңгәр утта
әни пешерә ботка.
Юган ярмасы – сары,
исеме була – тары.
Ярманы суга салды,
суны кайнатып алды.
Сөт өстәде аннары,
тоз өстәде аннары,
май өстәде аннары,
һәм ботка булды тары.

*Ренат Харис*



## Минем сеңелем

Һап, һап, һап кына,
Очар коштай талпына.
– Үчти-үчти итәм, – ди, –
Тәпи атлап китәм, – ди.

Тәпи-тәпи, тәпи-тәпи...
Минем сеңелем бик тәти.
Бер утыра, бер баса,
Биетим лә, булмаса.

Тып-тып килә ул,
Ничек кенә белә ул!
Бәләкәч кулларын җәеп,
Чарык-чарык көлә ул.

Тыпыр-тыпыр биесен,
Тик куансын, тик көлсен.
Көлсә көләр эше бар,
Ике бөртек теше бар...
Һап, һап, һап!

*Резеда Вәлиева*

## Энесенә ул апа

Җырлый-җырлый кыз бала
Энекәшен йоклата.
Биштә генә булса да,
Энесенә ул – апа.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Йоклатканга энемне,
Әнкәй мине пәп итә.

Кошлар кунган тирәккә,
Аларны җил тибрәтә
Тышта җилләр искәндә,
Бәби йоклый мендәрдә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә,
Энем йокыга киткәч,
Әнкәй бераз ял итә.

Йоклый бала, төш күрә,
Көлә, күккә сикерә,
Имеш, аны әтисе
Үсти-үсти иттерә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Әнкәй, мәми пешереп,
Әткәйне эштән көтә.

*Мөнир Мазунов*

## Зиләнең курчагы

Зиләнең бер курчагы бар,
Сузып кына: “Ән-нә”, – ди.
Сеңелем аңа: “Әттәбезне
Яратмыйсың мәллә?” – ди.

Сөеп кенә тора безне,
Беләсең бит әтине...
Йә үпкәләр, аңа да бер
«Әт-тә», диеп әйт инде.

*Хәкимҗан Халиков*

## Йокла инде, курчагым

Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле,
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле.

Аргансың инде, җаным,
Йокла, минем матурым,
Мин дә синең янына
Ял итәргә ятармын.

Йокла инде, курчагым,
Йомылмаса да күзең,
Сине йоклата торгач,
Йоклап китәм бит үзем.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Ап-ак иткән

Чисталыкны бик ярата
Гөлгенә.
Битен-күзен юып тора
Гел генә.
Өс-башына тузан-туфрак
Тидерми.
Курчакка да керле күлмәк
Кидерми.

Ә беркөн ул артыграк
Тырышкан:
Мех бүреген суга салган
Бер очтан.
Кара киез итеген дә
Юган ул.
Бар әйберен “ап-ак” итеп
Куйган ул.

*Фәнис Яруллин*



## Башмак кигәндә

Менә безнең уң башмак,
менә безнең сул башмак.
Уңын киябез башта,
аннан киябез сулын…

Уңын алдан кигәннең
уңа икән, ди, юлы.
Уң аяк безнең әзер.
Сулын киябез хәзер.

*Ренат Харис*

## Курчак

Кичә Ләйлә көйсезләнеп
Атып бәрде курчагын.
Уйныйсы килгәч, ул аны
Эзли башлады тагын.

Әнисе әйтә аңарга:
– Курчагың синең бизгән,
Ләйлә мине гел кыйный дип,
Ул чыгып киткән бездән.

Өстәл асларын карады,
Шкаф артын капшады,
Сандык яннары калмады,
Тик курчагын тапмады.

*Әнәс Кари*

## Тәти кул

Уң кул була, сул кул була,
Ә уң кул була тәти.
Тәти кул белән ашарга
Өйрәтте мине әти.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Ике кыз

Ай, начар кыз Әнвәрә,
Көн дә елый: «Вә-вә-вә!»
Кичен елый куркудан,
Елап тора йокыдан.

Уенчыкларын вата,
Энесен дә елата.
Шуңа аны сөймиләр –
«Елак Әнвәрә» диләр…

Күрше кызы Әминә
Шундый акыллы менә:
Егылса да еламый,
Сеңлесен дә кыйнамый.

Елаганда юата,
Курчак биреп уйната.

*Әнәс Кари*

## Әни белән сөйләшү

Улы дәшә: уа, уа! –
Кил яныма, янәсе.
– Килә алмыйм, савыт юам, –
Ди улына әннәсе.

Үрсәләнә, ярсулана:
– Уа, уа! – ди улы.
– Киләм, җаным, ачуланма! –
Ди әнкәсе бу юлы.

*А. Барто*



# Икенче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика

**Диагностик биремнәр (5-14 ноябрь)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1) *Дидактик уен «Бу нәрсә?»*

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). *Дидактик уен «Кем нәрсә эшли?»*

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли? (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный? (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый? (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячетең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый.



**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячетең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячетең сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячетең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1) *Дидактик уен «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?»*

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә:

-Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха).

- Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е).
- Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт).
- Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка).
- Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1) *Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә*

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

– Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кем ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?

2) *«Камыр малай» әкиятен сәхнәләштерү.*

Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларга сәхнәләштерүдә катнашырга тәкъдим ясый.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый.

Тәрбияче: Балалар, әби белән бабай Камыр малай...

Бала: пешергәннәр.

Тәрбияче: Камыр малайны тәрәзә төбенә...

Бала: куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч, тәрәзәдән...

Бала: сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә урманга...

Бала: җитә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә, таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.

Тәрбияче: Балалар, камыр малайны әби белән...

Бала: бабай пешергәннәр.

Тәрбияче: Камыр малайны...

Бала: тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,...

Бала: тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә...

Бала: урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбиясененең үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне



сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

## Диагностик биремнәр (21-31 март)

**1. Баланың сүзлек запасы**

1) *Дидактик уен «Бу нәрсә?»*

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

*Диагностик биремнең эчтәлеге*:

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба). Чәйнекнең борынын күрсәт. Хәзер чәйнекнең капкачын күрсәт. Чынаякның тоткасын күрсәт.

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары). Өстәлнең аякларын күрсәт. Урындыкның аркасын күрсәт. Шкафның ишеген күрсәт.

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары). Этнең колакларын күрсәт. Песинең койрыгын күрсәт. Сыерның мөгезен күрсәт. Кәҗәнең сакалын күрсәт.

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар). – Куянның тәпиләрен күрсәт. – Төлкенең борынын күрсәт. – Аюның гәүдәсен күрсәт.

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: – Бу нәрсә? – Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр). – Күлмәкнең җиңен (якасын, кесәләрен, сәдәфләрен) күрсәт.



**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен атаганда һәм күрсәткәндә авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, мөһим детальләрен, өлешләрен күрсәткәндә, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен дөрес атый һәм күрсәтә, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**«Бу кайчан була?» үстерешле уены**

Балаларга тәүлек өлешләре сурәтләнгән карточкалар күрсәтелә. Тәрбияче тәүлек өлешенә туры килгән күренешләрне атый һәм сорау бирә, балалар тиешле карточканы табалар.

1. Кояш чыга, әтәчләр кычкыра, балалар бакчага барырга җыена, әти-әниләр эшкә китәләр. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

2. Кояш яктырак карый, күзләрен киңрәк ача, балалар урамда уйный, төшке аш ашыйлар. - Бу кайчан була? Шушы тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

3. Кояш күзләрен йома, балалар бакчадан, әти-әниләр эштән өйләренә кайта, кичке аш ашыйлар, балалар «Тыныч йокы, нәниләр» тапшыруын карыйлар. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

4. Кояш йоклый, ай яктырта, күк йөзендә йолдызлар яна, бар кешеләр дә йоклый. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – тәүлек өлешләрен аера белми.

**2 балл** – өстәмә сораулар биргәндә генә тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**3 балл** – тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1) *Дидактик уен «Кем нәрсә эшли?»*

Материал: уенчык песи (Йомшаккай), төрле кошлар һәм җәнлекләр сурәтләнгән картинкалар.

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

Тәрбияче балаларга Йомшаккай турында сөйли: *«Безнең Йомшаккайның дуслары бик күп. Дусларының кем икәнен белергә телисезме? Ул аларның фотографияләрен алып килгән.* (Тәрбияче бер һәм күп куяннар, үрдәкләр, колыннар, чебиләр, көчекләр, сыерлар, бәрәннәр сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм сораулар бирә: *Бу нәрсә?* (Бер куян сурәтләнгән картинка күрсәтә). (*Куян*). *Бу нәрсә?* (Куяннар сурәтләнгән картинка күрсәтә). (*Куяннар*). Башка картинкалар белән эш шушы рәвешле алып барыла.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: *«Йомшаккай кошлар һәм җәнлекләр белән качышлы уйнарга ярата. Сез күзләрегезне йомыгыз. Йомшаккай кача.»* (Тәрбияче Йомшаккайны шкаф артына (эченә, өстенә, астына, янына) качыра. Балалар күзләрен ачалар, Йомшаккайны эзлиләр һәм аның кайда качканын әйтәләр. Мәсәлән: *«Йомшаккай шкаф артына качкан».*

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: *«Җәнлекләр һәм кошларны әниләре эзләп килгән. Әйдәгез, әниләренә аларны табарга булышыйк».* (Тавык сурәтләнгән картинка куела). *Тавык (сыер, эт, ат, сарык, куян) нәрсәне алырга килгән?* (Тавык чебине алырга килгән.) (Шул рәвешле куян куян баласын, сыер бозавын, эт көчеген, сарык бәрәнен, ат колынын таба).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячененң сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячененң сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячененң сорауларына җавап биргәндә, берлек һәм күплек сандагы исемнәрне, бәйлек сүзләрне (эченә, өстенә, астына, янына), кошлар һәм җәнлекләр, аларның балалары атамаларын сөйләмдә дөрес куллана, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячененң сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1) *Дидактик уен «Минем кебек әйт».*

*Диагностик биремнең эчтәлеге:*

Тәрбияче балага үзе әйткән сүзләрне игътибар белән тыңлап, нәкъ шулай итеп кабатларга куша һәм сорау бирә. Тәрбияче, әле бер, әле икенче авазны аерып, сүзләрне я кычкырып, я тыныч тавыш белән, я пышылдап әйтә. Мәсәлән: «Минем кебек әйт».

А: Аааалсу, ааат, aааз, боткааа.

Ә: Әәәәмир, мәәәк, кәәәҗәәә.

О: ооон, йооорт, ооонык, кооолын.

Ө: өөөй, өөөстәл, көөөзге, көөөймә.

У: ууурман, ууенчык, куууян, кууурчак.

Ү: үүүлән, үүүрдәк, күүүбәләк, үүүрмәкүүүч.

И: Иииинсаф, иииплии, тииием, машииина, әнииии.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала кирәкле авазны ишетми, күп сүзләрне дөрес интонация белән әйтми, хаталар ясый.

**2 балл** – бала күп сүзләрне дөрес кабатлый, дөрес интонация белән әйтә, тәрбияче ярдәме белән кирәкле авазны әйтә.

**3 балл** – бала кирәкле авазны ишетә, кабатлый, аны мөстәкыйль рәвештә дөрес интонация белән әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1) *Сораулар буенча әңгәмә*. – Синең өйдә нинди уенчыкларың

бар? Син алар белән ничек уйныйсың? Кем белән уйныйсың? Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала бер уенчыкны гына атый.

**2 балл** – бала уенчыкларны санап кына чыга.

**3 балл** – бала үзенең шәхси тәҗрибәсенә нигезләнеп. 3-4 җөмләдән торган хикәя төзи.

2) *Тәрбияче балага Л.Толстойның «Өч аю» әкиятен сөйләргә тәкъдим итә*. – Син «Өч аю» әкиятен беләсеңме? Аны сөйлә әле.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала әкият эчтәлегенә кагылышлы кайбер сүзләрне генә әйтә ала.

**2 балл** – бала тәрбияче биргән сораулар ярдәмендә генә әкиятнең эчтәлеген сөйли.

**3 балл** – бала әкиятнең эчтәлеген мөстәкыйль сөйли ала.

**Югары дәрәҗә** - 15-18 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 11-14 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 7-10 балл



**«Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү» буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме, фамилиясе | Баланың сүзлек запасы | Сөйләмнең грамматик ягы | Сөйләмнең аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

## Кулланылган әдәбият исемлеге

1. *Агнабаева Ф.Г.* Гөлбостан: Балалар бакчасында телләр үстерү өчен методик кулланма / Ф.Г. Агнабаева, Г.Р. Елкыбаева, А.З. Нарынбаева, М.Р. Харисова, Р.И. Әминева. – Өфе: Китап, 2010. – 416 с.

2. *Алексеева М.М.* Методика развития речи и обучения родному языку дошкольников / М.М.Алексеева, В.И.Яшина. – М.:2000. – 400 с.

3. *Алексеева М.М.* Речевое развитие дошкольников /М.М.Алексеева, В.И.Яшина. – М.: 1998. .

4. *Алешина Н.В.* Ознакомление дошкольников с окружающим и социальной действительностью. Младшая группа. Конспекты занятий. Изд. 4-е / Н.В. Алешина – М.: УЦ. ПЕРСПЕКТИВА, 2008. – 96 с.

5. *Арушанова А.Г.* Речь и речевое общение детей: Развитие диалогического общения: Методическое пособие для воспитателей. – 2-е изд. испр. и доп. /А.Г. Арушанова – М.: Мозаика-Синтез, 2005. – 128 с.

6. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Төзүчеләр К.В.Закирова, Р.А.Борһанова. - Казан, «Хәтер», 2000.

7. *Бородич А.М.* Развитие речи дошкольников / А.М.Бородич. – М.: 1969.

8. *Вагыйзов С.Г.* Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы / С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова. – Казан: Мәгариф, 2001.

9. *Венгер Л.А.* Восприятие и обучение / Л.А.Венгер. – М.: 1969.

10. *Виноградова Н.Ф.* Умственное воспитание детей в процессе ознакомления с природой / Н.Ф.Виноградова. – М.: 1982.

11. *Выготский Л.С.* Мышление и речь / Л.С.Выготский. Соч., т. 2 – М.: 1973.

12. *Гвоздев А.Н.* Вопросы изучения детской речи /А.Н.Гвоздев. – М.: 1961.



13. *Гербова В.В.* Занятия по развитию речи во второй младшей группе детского сада. Планы занятий. – 2-е изд. испр. и доп. / В.В. Гербова. – М.: Мозаика-Синтез, 2008. – 112 с.

14. *Гербова В.В.* Развитие речи в детском саду. Программа и методические рекомендации /В.В. Гербова. - М.: Мозаика-Синтез, 2006. – 56 с.

15. Гөлбакча (Балалар бакчалары өчен хрестоматия): Балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

16. Диагностика уровней освоения программы: вторая младшая и средняя группы / авт.–сост. Н.Б.Вершинина. – Волгоград: Учитель, 2010. – С. 5-23; 76-84.

17. *Давыдов В.В.* Проблемы развивающего обучения / В.В.Давыдов. – М.: 1988.

18. Затулина Г.Я. Конспекты комплексных занятий по развитию речи (вторая младшая группа) /Г.Я. Затулина. – Учебное пособие. – М.: Центр педагогического образования, 2009. – 144 с.

19. *Зубарева Н.М.* Дети и изобразительное искусство /Н.М.Зубарева. – М.: 1968.

20. *Козлова С.А.* Дошкольная педагогика /С.А.Козлова, Т.А.Куликова. – М.: 2005.

21. *Короткова Э.П.* Обучение рассказыванию в детском саду / Э.П.Короткова. – М.: 1982.

22. Кроха: метод. рекомендации к программе воспитания и развития детей раннего возраста в условиях дошкольных учреждений / Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева и др. – М.: Просвещение, 2007. – 207 с.

23. *Лифиц Е.А.* Развитие речи, движения и мелкой моторики. Комплексные занятия. Практическое пособие / Е.А. Лифиц, И.В. Лифиц. – М.: Айрис-пресс, 2010. – 160 с.

24. *Лурия А.Р.* Речь и мышление / А.Р.Лурия. – М.: 1976.

25. *Люблинская А.А.* Воспитателю о развитии ребенка / А.А.Люблинская.– М.: 1972.

26. *Мелик-Пашаев А.* Общение и речь: развитие речи у детей в общении со взрослыми / А.Мелик-Пашаев, З.Новлянская. – М.: 1985.

27. Методические рекомендации к «Программе воспитания и обучения в детском саду» // сост. Л.В. Русскова. – М.: 1986.

28. Модели комплексно-интегрированных занятий с детьми 1,5-7 лет / сост. С.С. Дреер, А.М. Потыкан. – Волгоград: Учитель, 2011. – 137 с.

29. *Мөбәрәкшина Р.М.* Балалар бакчасында җырлар, уеннар. Методик кулланма / Р.М. Мөбәрәкшина, В.К. Вәлиева. – Яр Чаллы, 1997. – 68 б.

30. *Мухина В.С.* Детская психология / В.С.Мухина. – М.: 1985.

31. *Немов Р.С.* Психология / Р.С.Немов. – М.: 1995.

32. От рождения до школы. Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования / Под ред. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой. – М.: Мозаика-Синтез, 2010. – 304 с.

33. *Пиаже Ж.* Речь и мышление ребенка / Ж.Пиаже. – М.: 1978

34. *Поддьяков Н.Н.* Мышление дошкольника / Н.Н. Поддьяков. – М.: 1977.

35. Развитие речи дошкольников // под ред. Ф.А. Сохина – М.: 1984.

36. Раушан көзге: Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия: Педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 1993. – 255б.

37. *Родари Джанни*. Грамматика фантазии. Введение в искусство придумывания историй: /Дж.Родари. Пер. с итал./- М.: 1978.

38. *Рубинштейн С.Л.* К психологии речи / С.Л.Рубинштейн. // Проблемы общей психологии - М.: 1973.

39. *Рубинштейн С.Л.* Основы общей психологии / С.Л.Рубинштейн. – М.: 1989, т.1.

40. *Смирнова Е.А.* Использование наглядности в формировании повествовательной речи дошкольников /Е.А.Смирнова, О.С.Ушакова // Развитие речи детей в обучении языку. Тезисы выступлений на научном совещании. – М.: 1989.

41. Содержание и методы умственного воспитания дошкольников // под ред. Н.Н. Поддьякова. – М.: 1980.

42. Социально-эмоциональное развитие детей 3-7 лет: совместная деятельность, развивающие занятия /авт.-сост. Т.Д.Пашкевич. – Волгоград: Учитель, 2012. – 123 с.

43. *Стародубова Н.А.* Теория и методика развития речи дошкольников / Н.А.Стародубова. – М.: Изд. центр «Академия», 2006. - 256 с.

44. *Сухомлинский В.А.* Йөрәгемне балаларга бирәм /В.А.Сухомлинский. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976.

45. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан, «Матбугат йорты» нәшрияты, 2005. 848 б.

46. *Тихеева Е.И.* Развитие речи детей (раннего и дошкольного возраста) / Е.И.Тихеева. – М.: 1981.

47. *Тумакова Г.А.* Ознакомление дошкольника со звучащим словом / Г.А.Тумакова. – М.: 1981. – 128 с.

48. *Ушакова О.С.* Методика развития речи детей дошкольного возраста: Учеб. метод. пособие для воспитателей ДОУ / О.С. Ушакова, Е.М. Струнина. – М.: Гуманит. изд. Центр ВЛАДОС, 2003. – 288 с.

49. *Ушинский К.Д.* Родное слово / К.Д.Ушинский // Соч. т. 2. – М., Л., 1948.

50. *Федоренко Л.П.* Методика развития речи детей дошкольного возраста / Л.П.Федоренко. - М.: 1984. -240 с.

51. *Флерина Е.А.* Эстетическое воспитание в детском саду / Е.А.Флёрина. – М.: 1961.

52. *Фонарев А.М.* Развитие ориентировочных реакций у детей / А.М.Фонарёв. – М.: 1977.

53. *Чуковский К.И.* От двух до пяти /К.И.Чуковский. – М.: 1966

54. *Шанский Н.М.* Лексикология современного русского языка / Н.М.Шанский. – М.: 1972.

55. *Шәрәфетдинова З.Г.* Хәзерге татар телендә ияртемнәр: монография / З.Г. Шәрәфетдинова. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2007. – 208 б.

56. *Эльконин Д.Б.* Развитие речи детей / Д.Б.Эльконин. – М.: 1958



## Эчтәлек

**Аңлатма язуы..........................................................................3**

**Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешебуенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре...............................8**

Танып белү өлкәсе.......................................................................8

Сөйләм үстерү (коммуникация) өлкәсе.................................63

Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе............................106

**Кушымта.................................................................................199**

Шигырьләр...............................................................................199

Икенче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика......................207

Кулланылган әдәбият исемлеге...........................................218

# Туган телдә сөйләшәбез

Методик кулланма

Тышлык рәссамы: *В.В.Семенова*
Компьютерда биткә салучы: *А.С.Рубцов*
Мөхәррир: *Р.Ә.Кадырова*
Корректоры: *Р.Ә.Кадырова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.01.2013.
Форматы 60×90 $^{1}/_{16}$
Шартлы басма табагы 14,0
Тиражы 3000 д.
Заказ № 3/2013

«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды.
420111 Казан, Профсоюз урамы, 17в.
Тел./факс: (843) 292-27-25.



9 785905 576201